Габдулла Әдһәмов

# Гакыйдә

## Уку әсбабы

«Хузур» нәшрият йорты

УДК 28
ББК 86.38 (2 Рос. Тат.)

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе
**Габдулла Әдһәмов**

Китап Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең 14-37 нче номерлы карары белән басарга хупланган.

Ә32 Габдулла Әдһәмов: Гакыйдә (Иман нигезләре), уку әсбабы. – Казан: Хузур, 2014.– 160 б.

Гакыйдәгә кереш буларак кулланыла торган, фәннең терминнары һәм төшенчәләре белән танышу мөмкинлеген бирүче әлеге уку әсбабын тәкъдим итәбез. Әлеге фән өлкәсенә тирәнрәк төшенү өчен, фән чыганакларын һәм аңа булган аңлатмаларны өйрәнергә кирәк.

ISBN 978-5-85247-627-2

ББК 86.38
УДК 28
**© ҮДО – ТР МДН, 2014**
**© Әдһәмов Г., 2014**

www.darul-kutub.com

# КЕРЕШ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең бер хәдисендә әйтелгән: көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам һәм аның сахабалары янына бәдәви кыяфәтендә Җәбраил фәрештә килгән дә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам каршына утырып, аңа сораулар бирә башлаган. Шулар арасыннан иң әһәмиятлеләре: Нәрсә ул ислам? Нәрсә ул иман? Нәрсә ул ихсан? дигән сораулар булган. Әлеге сораулар Исламның фикх, гакыйдә һәм тәсәууф дип аталган иң мөһим фәннәренең нигезе булып тора. Икенче сорау исә әлеге уку әсбабының эчтәлеген тәшкил итә, ягъни иман мәсьәләләренә багышланган.

Гакыйдә – иманны өйрәнүче фән. Октябрь инкыйлабына кадәр басылган күп кенә татар китапларында иманның алты баганасы искә алына.

«Мин Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның илчеләренә, Кыямәт көненә, яхшының да, яманның да Бөек Аллаһ тарафыннан бирелүенә, үлгәннән соң тереләчәгебезгә ышанам».

Боларның соңгысы Кыямәт көне билгесе булганга күрә, без һәрвакытта да иманның алты баганасы турында сүз алып барабыз. Гакыйдә нәкъ менә шуларны өйрәнү белән шөгыльләнә.

Гакыйдәнең, фикһ фәне кебек үк, шәригатьнең төп һәм иң мөһим фәннәреннән берсе булуын ассызыклап узарга кирәк. Шул ук вакытта, әлеге фәннәр бары теоретик дисциплина гына булалар. Шуңа күрә дә, камиллеккә ирешү өчен, иманлы кешеләргә шушы фәннәрнең рухи якларына аеруча игътибар итәргә кирәк. Бу юнәлешне әхлак яки тәсәууф, яисә сулүк

www.darul-kutub.com

дип аталган мөселман этикасы ачыклый. Мөселман этикасы төрле гыйбадәтләрне, туклану кагыйдәләрен һ. б. ш. өйрәнү белән бергә, беренче чиратта, кеше белән Аллаһы Тәгалә арасындагы мөнәсәбәтләрне, ихласлылык, тугры ният, мәрхәмәтлелек, нәфесне тыя алу һәм башкаларны өйрәнә. Югарыда искә алынган өч фәнне үзендә берләштергән очракта гына кеше камил иманлы бәндәгә әверелергә мөмкин. Гакыйдә акыл белән тиңләштерелә. Ләкин акыл гәүдәдән башка гына, ягъни фикһтан башка яши алмый. Жаны, ягъни әхлагы булмаса, әлеге акыллы гәүдә үле булачак.

## ИСЛАМ ФӘННӘРЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ

Мәгълүм булганча, бүгенге көндә безгә билгеле ислам фәннәренең берсе дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам заманында булмаган. Әлеге фәннәрнең барысын да яңалык (бидгать) дип атый алабыз. Шәригать буенча яңалык ике төрле: хупланылган (рөхсәт ителгән) һәм тыелган була. Әлеге фәннәр безгә динебезне өйрәнүдә нык ярдәм иткәнгә күрә, без аларны рөхсәт ителгән яңалыкларга кертеп карыйбыз. «Ни өчен соң бу фәннәр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам заманнарында булмаган?» – дигән сорау туарга мөмкин. Жавабы бик гади: «Ул вакытларда әлеге фәннәрдә ихтыяҗ булмаган». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең замандашлары теләсә кайсы сорауларына җавапны аның үзеннән сорап белә алганнар. Җавапны белгән кеше Илаһи кануннарны бозмыйча алга таба яшәвен дәвам иткән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам вафатыннан соң хәл үзгәргән: вәхи иңү тукталган һәм мөселманнар **Коръән** белән **Сөннәттә** тупланган зур мирастан үзләре мөстәкыйль файдаланырга мәҗбүр булганнар.

Мөселманнарга Коръән белән Сөннәт кенә җитмәгәнмени? Әлеге фәннәр ни өчен кирәк булган соң? Гакыйдә, фикх, сира, тәфсир, хәдис, үсул әл-фикх, үсул әл-Коръән, үлүм әл-хәдис һәм башкалар ни өчен барлыкка килгән? Әлеге процесс тарихи яктан ничек дәвам иткән?

Югарыда искә алынган фәннәрнең барлыкка килүе билгеле факторларга бәйле. Менә аларның берничәсе:

1. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең мирасын саклап калу мәҗбүрияте.

2. Исламның гарәп булмаган халыклар арасында таралуы.

3. Исламның таныш булмаган идеологияләр, диннәр, гореф-гадәтләр, культураларга юлыгуы.

4. Аерым дин галимнәренең шәхси сыйфатлары тәэсире.

5. Исламның үзендә төрле секталар һәм юнәлешләр барлыкка килү.

Алга таба шушы катлаулы тарихи процессны күзәтеп узарга тәкъдим итәм.

Ислам фәннәренең барлыкка килүе, системалаштырылуы һәм үсешенең барышы, әлбәттә, Коръәннән башланган. Мәгълүм булганча, Әбү Бәкер, Аллаһ аннан разый булсын, идарә итә башлаган чорда хәлифәттәге эчке сәяси вәзгыять тотрыксызланган. Бу хәл ялган пәйгамбәрләрнең барлыкка килүе, кайбер кабиләләрнең зәкәт түләүдән баш тартулары һәм хәтта диннән чыгулары белән бәйле булган. Шушы катлаулы сәяси вәзгыятьтә Әбү Бәкер, Аллаһ аннан разый булсын, барлык фетнәчеләр белән көрәшергә карар кылган. Сугышлар вакытында, беренче чиратта, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең сахабалары үлгән. Алар

www.darul-kutub.com

арасында Коръән хафизлары күп булган. Мисал өчен, Ямам сугышы барышында җитмешкә якын Коръән белгече һәлак ителгән. Бу хәл Гомәр ибн әл-Хаттабны борчуга салган һәм ул Коръәнне язма рәвештә бер бөтен китап рәвешендә туплау мәҗбүрияте мәсьәләсен күтәреп чыккан. Әбү Бәкер, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам заманында андый китап булмаган дип, башта бу фикерне кире каккан. Ләкин соңрак, Гомәр ибн әл-Хаттабның үҗәтлеге аркасында, ул ризалашкан. Нәтиҗәдә, Коръән тексты беренче тапкыр тулысынча язма рәвештә тупланган.

Соңрак, Госман ибн Гаффан чорында Коръәнне тагын бер тапкыр туплаганнар. Моның сәбәбе: беренче тапкыр Коръән корәйш укылышында гына тупланган. Мәгълүм булганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам заманында гарәп теле җиде шивәдән (харф) торган. Аллаһы Тәгалә, Коръән гарәпләрнең барысына да аңлаешлы булсын өчен, Изге Китапны әлеге җиде шивәдә иңдергән. Сахабалар, Коръәнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнән отып алып, шәкертләренә үзләре сөйләшкән шивәдә тапшыра торган булганнар. Госман ибн Гаффан заманында, сахабаларның күп кенә шәкертләре гаскәр туплап, бүгенге Азәрбайҗан җирләренә сугыш белән чыкканнар. Шул вакытта алар арасында Коръәнне дөрес укуга кагылышлы каршылыклар туа башлаган. Мөселманнар арасында фетнә чыгудан куркып, Хузәйфә ибн әл-Ямән ашыгыч рәвештә Мәдинәгә юнәлгән һәм хәлифкә барысын да сөйләп биргән. «Өммәтеңә дөрес укылышны билгелә», – дип үтенгән ул хәлифәдән. Нәтиҗәдә, Госман ибн Гаффан Коръәнне бары корәйш укылышында гына саклап калырга, дигән карар чыгарган. Башка шивәләрдәге язмалар исә юкка чыгарылырга

www.darul-kutub.com

кушылган. Алга таба Коръән язмасының камилләштерелүе дәвам иттерелгән: нокталар һәм хәрәкәләр барлыкка килгән, тәҗвид фәне формалашкан.

Шуннан соң Сөннәтне саклап калу юнәлешендә эшләр башкарылган, беренче хәдис җыентыклары барлыкка килгән. Ин беренче хәдис җыентыкларын сахабалар туплый башлаган була. Алар арасында иң танылганнары – Габдулла ибн Әмра ибн әл-Аса һәм Гали ибн Әбу Талиб җыентыклары. Әмма бу юнәлештәге систематик эш хәлифә Гомәр ибн Габдул-Газиз кушуыннан соң гына башланган. Алар арасында Ибн Шихаб Әз-Зухри, имам Мәлик, Әбу Мөхәммәд Габдул-Мәлик ибн Габдул-Газиз ибн Җурайҗ, Әбу Әмра Габдуррахман әл-Авзаи, Әбу Габдулла Суфьян ибн Сәид Әс-Саури, Әбу Сәлма Хаммәд ибн Сәлма ибн Динар бар. Ә инде хәдисләрнең иң тулы һәм иң күләмле җыентыклары бары һиҗри белән III гасырда гына барлыкка килгән.

I гасыр ахырына таба ислам галимнәре арасында белгечлекләр барлыкка килә башлаган. Махсус шушы темага караган иң беренче хезмәт Ибн Исхакның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам тормышы турында сөйләүче китап булган. Кызганычка каршы, бу хезмәт бүгенге көнгә кадәр сакланып кала алмаган. Безгә аның Ибн Хишам тапшыруындагы нөсхәсе генә мәгълүм һәм ул хезмәт сира фәненең нигезен тәшкил итә. Алга таба гакыйдә, фикх, үсул әл-фикх, тәфсир, тарих һ. б. фәннәр буенча махсус хезмәтләр язылган.

Гакыйдә фәненең барлыкка килүе һәм үсешенә аерым тукталасы килә. Гакыйдәнең барлыкка килүенә төрле секталар килеп чыгу этәргеч булуны ассызыклап узарга кирәк. Беренче секталар дүртенче хәлифә Гали, Аллаһ аннан раз-

ый булсын, идарә иткән чорда барлыкка килгән. Алар харижилар һәм шигыйлар дип аталган. Башта алар сәяси хәрәкәт буларак танылганнар. Ләкин соңрак аларның үз идеологияләре дә барлыкка килгән. Шуңа бәйле рәвештә мөселман дин галимнәре сектачыларның карашларын кире кагучы дәлилләр китерергә мәҗбүр булганнар. Бу уңайдан үз өйрәтмәләрен барлыкка китерүдә грек фәлсәфәчеләренең хезмәтләреннән нык файдаланган мутазилийларны аерым әйтеп узарга кирәк. Мутазилийларның төп хатасы – акылны Коръән белән Сөннәттән бөегрәк итеп күрсәтүдә. Ахыр чиктә, алар Коръәннең барлыкка килүе, кабердә җәзалануның мөмкин түгеллеге, зур гөнаһлар кылучыны иманлы буларак та, динсез буларак та атап булмау кебек һ. б. ш. нәтиҗәләргә килгәннәр. Әлбәттә, сөнни галимнәре мутазилийларның идеологиясен кире кагарга мәҗбүр булган. Әбу Хәнифә чорында мутазилийлар белән дини бәхәсләр үткәрелгән. Ә инде Әхмәд ибн Ханбәл заманында вәзгыять кискенләшкән. Бу мутазилийларның хакимияткә килүләре белән бәйле. Дәүләт башында торуларыннан файдаланып, алар барлык ислам дөньясына үзләренең өйрәтмәләрен көчләп такмакчы булганнар. Шушы чорның күп кенә галимнәре җәзалап үтерелгән, зинданнарга ябылган. Ләкин хәлифәнең алмашынуы белән мутазилийлар көчләрен югалтканнар һәм сөнни галимнәре ислам дөньясын мутазилийлар идеологиясеннән арындыра башлаганнар. Шушы вакыттан алып Әхлү-с-Сөннә вәлҗәмәгать терминының барлыкка килүе хакында сөйли алабыз. Шушы чорда ислам дин гыйлемендә ике мәктәп: ашари һәм матуриди мәктәпләре барлыкка килгән. Беренчесенең башында – Багдадның дин галиме Әбу әл-Хәсән әл-Ашари, икенчесенең башлангычында Урта Азиянең дин галиме Әбу Мансур әл-Матуриди торган. Алар ислам дин гыйлеменең

www.darul-kutub.com

нигезен формалаштырганнар. Башка галимнәр исә әлеге фәннең алга таба үсеше белән генә шөгыльләнгәннәр. Әл-Ашари һәм әл-Матуриди хезмәтләре белән танышканда, алар Исламның беренче гасырларындагы дин галимнәре хезмәтләреннән берни белән дә аерылмый, дигән нәтиҗәгә киләсең. Төрле тарихи процесслар барышында әл-Ашари мәктәбенең тәгълиматлары күбесенчә ислам дөньясының көнбатышында, ә әл-Матуриди мәктәбенең өйрәтмәләре – көнчыгышта таралыш алган. Әл-Матуридигә иярүчеләрнең барысы да диярлек – хәнәфиләр, ә менә әл-Ашарига иярүчеләр исә калган өч мәзхәб вәкилләре була.

Безнең Идел-Урал регионына әл-Матуридинең хәнәфи тәгълиматлары Урта Азиядән килеп кергән. Мәгълүм булганча, баштарак – болгарлар, соңрак аларның дәвамчылары – татарлар Бохара, Сәмәрканд, Кабул һ. б. мәдрәсәләрендә белем алган. Аннан кайткан остазлар шәкертләрен дә үзләре укыган программалар буенча өйрәткән. Әбу Мансур әл-Матуриди хезмәтләре шактый катлаулы дини тел белән язылган. Аларны гарәп телен камил белгән яхшы әзерлекле кеше генә укый ала. Без исә шәкертләребезгә шушы уку әсбабын тәкъдим итәбез. Ул гакыйдәгә кереш булып тора, фәннең терминологиясе һәм төшенчәләре белән танышырга ярдәм итә. Фәннәрнең әлеге өлкәсен тирәнтен үзләштерү өчен чыганакларны һәм аларга кагылышлы аңлатмаларны өйрәнергә кирәк.

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 1 БҮЛЕК

# АЛЛАҺКА ЫШАНУ

Аллаһка ышану дөньяның барлыкка китерелүенә ышану дигән сүз. Материалистлар Галәмне һәм андагы барлык нәрсәләрне һәрвакытта да булган, алар бары тик бер төрдән икенче төргә үзгәреш кичергән, дип саныйлар. Без – мөселманнар исә – дөньяның барлыкка килүенә ышанабыз. Дөнья нинди дә булса матдәдән түгел, ә юклыктан бар ителгән. Дөньяны Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән. Аллаһ һәрвакытта да булган һәм дөньяны юктан яраткан. Ул үзе яраткан төрле җан ияләрен кирәкле рәхәтлекләр белән бүләкләгән. Кояш, планеталар, һава, су, ризык, кием-салым, тән, җан һәм болардан тыш тагын бик күп нәрсәләр безгә һәм башка җан ияләренә Аның бүләге. Димәк, без Аңа рәхмәтле булырга тиеш. Моның өчен безгә, беренче чиратта, Аны танып белергә кирәк. Бу максаттан без Аллаһның күркәм һәм камил исемнәре белән сыйфатларын өйрәнербез.

### 1.1. Аллаһның исемнәре

АЛЛАҺ – Аның иң бөек исемнәреннән берсе. Ул үзенә башка исем һәм сыйфатларның мәгънәсен сыйдырган. Ул

www.darul-kutub.com

ялгызлык исем, нинди дә булса башка тамырдан килеп чыкмаган.

ӘР-РАХМӘН, ӘР-РАХИМ (һәркемгә һәм һәрнәрсәгә мәрхәмәтле, шәфкатьле[1].

Әлеге ике исем дә «әр-рахмә» (мәрхәмәт, шәфкать) нигезеннән килеп чыккан. Ләкин «әр-Рахмән» сүзенең мәгънәсе киңрәк. «Әр-Рахмән», ышануларына һәм тугрылыкларына карамастан, барлык кешеләргә кагылышлы илаһи мәрхәмәтне аңлата. Күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә бу дөньядагы Үзе барлыкка китергән барлык мәхлукларына да шәфкатьле. Ул аларның барысының да ихтыяҗларын тәэмин итә. «Әр-Рахим» сүзе Аллаһның иман китергәннәргә Кыямәт көнендәге мәрхәмәтен күздә тота. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә, иманлы бәндәләрнең гөнаһларын кичереп, аларны җәннәткә кертәчәк. Мәрхәмәтлелек чаткыларының кешеләрдә дә булуына карамастан, аларны Аллаһның мәрхәмәт-шәфкате белән чагыштырып булмый. Әлеге хис кеше күңелендә булып та, аның тормышка ашырылу мөмкинлеге булмый. Яисә мөмкинлеге булуга да карамастан, кемгәдер мәрхәмәтлелеген күрсәтү нияте яки теләге тумый. Кешенең шәфкатьлелеге шул кешенең мөмкинлекләренә һәм асылына бәйле.

ӘЛ-МӘЛИК (бар нәрсәнең Хуҗасы, Иясе).

Бөек Аллаһы Тәгалә дөньядагы бар нәрсәнең тулы хокуклы һәм чикләнмәгән хуҗасы, иясе. Бу сыйфат кешегә дә хас, ләкин ул бик нык чикләнгән. Бу дөньяда кеше ирешергә мөмкин булган иң югары хакимият һәм зур милек – ул дөнья

[1] Әлеге һәм башка исемнәрнең тәрҗемәләре белән аңлатмаларын тәфсилләбрәк Абу Хамид Мухаммад ибн Мухаммад аль-Газали ат-Туси. Высочайшее из устремлений в раскрытии смыслов прекрасных имен Аллаха (гарәпчәдән Саяхов Р.Л. тәрҗемәсе. – Уфа, 2007. – 232 с.) дигән китаптан карарга мөмкин.

белән идарә итү. Тик боларның барысына да ул ялгызы гына ирешә алмый. Моның өчен кешегә киңәшчеләре, дуслары, компаньоннары, гаскәр, техника һ. б. ярдәм итә. Ләкин әлеге хакимлек шушы кешенең гомере озынлыгына бәйле. Җаны тәненнән аерылгач та ул барлык байлыклары белән хакимиятен, үзе яшәгән йортын, үзе утырып йөргән машинасын, кигән киемнәрен һәм хәтта бары тик үзенеке дип санаган тәнен дә югалтачак. Аллаһның хакимиятенә килгәндә, Ул кемнең дә булса ярдәменә яки булышлыгына мохтаҗ түгел, аны чикләп тә, тартып алып та булмый. Аллаһ дөньядагы бар нәрсәнең дә бердәм хуҗасы булган, бар һәм алга таба да булачак.

ӘЛ-МӨТӘКАББИР (чын бөеклеккә Ия Булучы).

Кешедә әлеге илаһи сыйфатның бөртек кадәр генә дә чагылышы юк. Бу сүз кешегә карата кулланылганда тискәре мәгънәгә ия була башлый, ягъни «тәкәббер» дигәнне аңлата. Аллаһ кешедәге әлеге сыйфатны хупламый һәм хәдисләрнең берсендә шушы сыйфатка ия булучы кеше җәннәткә кертелмәячәк дип кисәтә. Чөнки бу дөньядагы дәрәҗә-уңышларга, рәхәтлекләрнең барысына да кеше үзе ирешмәгән. Аллаһы Тәгалә сәламәтлек, акыл, вакыт, танышбелешлек һ. б. белән бүләкләмәгән булса, дәүләт президенты да, иң бай эшкуар да, бөек галим һәм танылган спортчы да шушы дәрәҗәләренә ирешә алмаган булырлар иде. Шуңа күрә дә әлеге дәрәҗәләр Илаһи мәрхәмәтлелек нәтиҗәсе була.

ӘЛ-ХАЛИК (билгеле рәвештә Барлыкка Китерүче).

Дөньядагы барлык нәрсәләрне бары тик Аллаһ гына барлыкка китерә алган.



www.darul-kutub.com

ӘЛ-БӘРИ (юклыктан соң Яшәеш Бирүче).

Бары тик Аллаһы Тәгалә генә юклыктан соң яшәеш бирергә мөмкин.

ӘЛ-МҮСАУУИР (бар нәрсәгә Калып, Рәвеш бирүче).

«Әл-Халик», «әл-Бәри», «әл-Мүсауuир» исемнәре синоним булып тоелырга мөмкин. Чөнки аларның мәгънәләре барлыкка китерү, ярату дигәнне аңлата. Ләкин бу алай түгел. Юктан бар ителгән һәр нәрсә, беренчедән, нияткә бәйле. Икенчедән, нияткә нигезләнеп яшәешне булдыруга һәм, өченчедән, тиешле форма бирүгә бәйле. Шуңа күрә дә Аллаһ нәрсәнедер бар итәргә ниятләгән Халик була, барлыкка китерүче һәм яратучы Бәри була, Үзенең мәхлукларына иң яхшы рәвеш, калып бирүче Мүсауuир була.

ӘЛ-ГАФФӘР (гөнаһларны Яшерүче һәм Гафу кылучы).

«Әл-Гаффәр» – физик һәм рухи мәгънәдә күркәм нәрсәләрне күрсәтеп, яманлыкларны яшерүче. Аллаһ кешедән яшергән беренче нәрсә – аның ямьсез эчке әгъзалары. Ул аларны тышкы матурлык белән бизәгән. Ләкин эчтәге белән тыштагының аермасы шулкадәр зур. Икенчесе – яман уйлар һәм хупланмаган теләкләрне яшерү өчен Ул кеше күзенә күренмәс җан белән йөрәкне булдырган. Кайвакыт башка килә торган уйларның яки җандагы икейөзлелек, хыянәт, мәкернең башка кешеләргә күренә алуын күз алдына китерсәк, аларның бу күренешләргә, һичшиксез, ачулары чыгар иде. Алай гына да түгел. Низаглар чыгып, сугыш, кан коеш, үтерешләр булырга мөмкин. Боларны булдырмас өчен, Аллаһы Тәгалә чит серләрне бездән яшергән.

Кешеләрнең гөнаһлары әшәке, начар нәрсә исәпләнә. Аллаһ аларны бу дөньяда яшерә һәм киләсе тормышыбызда да алар өчен безне җәзаламый. Ул безне гафу итә. Гафу итү яманлыкларны яшерү була инде ул.

ӘР-РАЗЗӘК (Бәрәкәт һәм Ризык бирүче).

«Әр-Раззәк» туклану чыганакларын булдыручы, кешеләргә алардан файдалану мөмкинлеген тудыручы һәм алардан ләззәтләнү сәбәпләрен барлыкка китерүче, дигәнне аңлата.

«Ризк» сүзе Аллаһы Тәгалә бирүче барлык рәхәтлекләр, игелекләр, дигән мәгънәдә килә. Боларга тән, һава, су, ризык, торак, транспорт, китаплар һәм шулай ук рухи азык та керә. Әлеге сыйфатның аз гына чагылышы кешедә дә булуга карамастан, аны берничек тә Илаһи сыйфат белән чагыштырырга ярамый. Беренчедән, кешегә кемнедер тукландыру өчен күп көч һәм энергия сарыф итәргә: язын җирне эшкәртеп, чәчәргә, җәен карап үстерергә, көзен уңышны җыеп алырга кирәк. Аллаһка исә «бул» дип әйтү генә дә җитә («Күн фә якүн» – Аның «бул» дип әйтүеннән кирәк нәрсәләр барлыкка килә). Гайсә пәйгамбәрнең, Аллаһ аннан разый булсын, сахабалары үтенеченә нигъмәтләр белән тутырылган өстәл, Мәрьям анага җибәрелгән җиләк-җимешләр моңа дәлил булып тора.

Кешенең кемнедер ризыкландыру сәләте аның мөмкинлекләре белән чикләнгән. Кеше планетабызда яшәүче җиде миллиард бәндәне тукландыра алмый. Шулкадәр халыкка тагын җирдә яшәүче барлык хайванннарны, бөҗәкләрне, микроорганизмнарны һәм җеннәрне кушсаң, кешенең мөмкинлекләре бөтенләй дә вак тоела. Аллаһы Тәгаләгә исә боларның барысын да тукландыру берни дә түгел. Моннан тыш, Ул һәр регион һәм һәр төр өчен төрледән-төрле ризыклар булдырган.

ӘЛ-ХАФИД, ӘР-РАФИГЪ (хурлауга лаеклыларны Түбәнсетүче, зурлауга лаеклыларны Дәрәҗәләр Бирүче).



www.darul-kutub.com

Лаеклы булмаганнарны түбәнсетүче, аларны бәхетсез итүче, иманлы кешеләрне дәрәҗәләргә ирештерүче, аларны бәхетле итүче. Тәкъваларны Үзенә якынайту белән биегәйтүче һәм Үзенең дошманнарын (мәрхәмәтеннән ерагайтуы белән) түбәнсетүче. Моңа бары тик Бөек Аллаһ гына сәләтле, чөнки Ул әл-Хафид һәм әр-Рафигъ.

ӘЛ-ХАФИЗ (Саклаучы, яшәешнең сәбәпләрен дәвам иттерүче).

«Әл-Хафиз» хакыйкый саклаучы. «Саклау» сүзенең чын асыл мәгънәсен аңлау өчен ике нәрсәгә төшенергә кирәк.

Беренчедән, дөньядагы барлык нәрсәләрнең яшәешен дәвам иттерүче һәм озайтучы, ягъни яшәешне бетерү белән юк итүгә капма-каршы нәрсә. Бу мәгънәдә Аллаһы Тәгалә күкләрне, җирне, фәрештәләрне (аларның яшәеш вакыты шактый озайтылган), шулай ук хайваннар белән үсемлекләрне (аларның яшәеш вакытлары бик үк озын түгел) саклаучы. Ул һәр кешенең, хайванның, бөҗәкнең һ. б. яшәешен һәр мизгелдә тәэмин итеп тора. Аллаһ кемнедер сакламый башлагач, ул теге дөньяга күчә, үлә.

ӘЛ-МҮХЙИЙ, ӘЛ-МҮМИТ (Гомер һәм Үлем бирүче).

Әлеге исемнәрнең мәгънәсе дә турыдан-туры барлыкка китерү барышына бәйле. Барлыкка китерелгән нәрсәгә яшәеш бирү терелтү дип атала. Үлемгә бәйле процесслар гомерне кисү, үтерү дип атала. Аллаһтан башка берәү дә яшәеш һәм үлемне барлыкка китерергә мөмкин түгел.

ӘС-САМӘД (Барлык омтылышларның һәм тырышлыкларның чиге).

«Әс-Самәд» – Аллаһка мохтаҗлыклары булганнар үтенеч белән ялваралар, теләк һәм омтылышлары белән Аңа

мөрәҗәгать итәләр (чөнки бары Ул гына барлык нәрсәнең хакиме). Аллаһы Тәгалә генә тулы мәгънәсендә «әс-Самәд», чөнки нәкъ менә барысы да хаҗәтләре белән Аңа гына омтылалар.

ӘЛ-ГАНИ, ӘЛ-МҮГНИ (бернинди үз хаҗәтләре булмаган, барлык Хаҗәтләрдән Коткаручы).

«Әл-Гани» – асылы һәм сыйфатлары белән бернигә дә мохтаҗлыгы булмаган Зат. Алай гына да түгел, Ул кем белән булса да элемтәдә булудан өстен Зат.

Аллаһ шулай ук әл-Мүгни дә. Әмма Ул баеткан (башкаларга мохтаҗлыгын калдырмаган) кеше әле абсолют бай һәм тышкы факторлардан ирекле була алмый. Ул барыбер Илаһыга мохтаҗ булып кала.

Югарыда санап кителгәннәрдән тыш Аллаһы Тәгаләнең камил һәм затлы исемнәре тагын күп әле. Без алда китергәннәре генә дә, иманлы кешенең күңелендә Аңа карата илтифат һәм рәхмәт хисләре барлыкка китерү, таң калу һәм үзенең бик кечкенә кеше икәнен аңлау өчен җитәрлек. Аллаһтан тыш берәүдә дә хакимлек, көч-куәт, бөеклек юк. Аллаһ бөекләрдән Бөек. Барча мактау Аңа гына.

## 1.2. Аллаһның сыйфатлары (атрибутлары)

Безнең мөселман галимнәре үз китапларында түбәндәге сыйфатларны (атрибутларны) карап үтәләр:

1. Әл-Вөҗүд (һәрвакыт Бар булуы).
2. Әл-Кыйдәм (Башлангычы булмау).
3. Әл-Бәка (Ахыры булмау, Мәңгелек).

www.darulkutub.com

4. Әл-Мүхаләфәт лил-хәвәдис (Үзенең барлыкка китергәннәреннән аерылып тору).
5. Әл-Кыям би нәфсиһи (Мөстәкыйль яшәешь).
6. Әл-Вәһданийә (Бердәнберлек).
7. Әл-Хәят (Тормыш).
8. Әл-Гыйлем (Белем).
9. Әл-Ирадә (Ихтыяр).
10. Әл-Кудрат (Көч-Куәт).
11. Әл-Каләм (Сөйләм).
12. Әт-Тәквин (Юкта бар итү).
13. Әс-Сәмг (Ишетү).
14. Әл-Бәсар (Күрү).

Болардан тыш, Аллаһы Тәгаләгә Аның исемнәреннән барлыкка килгән башка бик күп сыйфатлар да хас.

## Шәхси Сыйфаты — һәрвакыт Бар булуы (әл-Вөҗүд)

Һәрвакыт Бар булуы даими яшәеш дигәнне белдерә. Аллаһ яши, ләкин Аның яшәеше башкаларныкыннан аерылып тора. Аллаһның һәрвакыт Бар булуы Илаһи мәҗбүрилек ул, ә аның капма-каршысы, ягъни булмавы – кабул ителми, ул мөмкин түгел. Һәрвакыт Бар булуы – Илаһилыкны билгеләүче мәңгелек, башлангычсыз сыйфат. Һәрвакыт Бар булу сыйфаты – барлык калган сыйфатларның нигезе һәм асылы ул[1].

Безнең сөнни дин галимнәре Аллаһның һәрвакыт Бар булуына бик күп дәлилләр таптылар. Әлбәттә, беренче чиратта,

[1] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 66.



www.darulkutub.com

ул – Коръән аятьләре. Аларның эчтәлекләрен анализлап карасак, Аллаһның сыйфат-билгеләрен тану өчен әйләнә-тирә дөньяны өйрәнергә өндәүләрнең күплеген билгеләп була. Мәсәлән, шундыйларның берсендә әйтелә:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَالْفُلْكِ الَّتِي تَجْرِي فِي الْبَحْرِ بِمَا يَنفَعُ النَّاسَ وَمَا أَنزَلَ اللَّهُ مِنْ السَّمَاءِ مِنْ مَاءٍ فَأَحْيَا بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا وَبَثَّ فِيهَا مِنَ كُلِّ دَابَّةٍ وَتَصْرِيفِ الرِّيَاحِ وَالسَّحَابِ الْمُسَخَّرِ بَيْنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ لَآيَاتٍ لِقَوْمٍ يَعْقِلُونَ

«Чынлыкта исә, җир һәм күкләрне барлыкка китерүдә, төн белән көннең алмашынуында, кешеләргә файдалы товарлар белән диңгездә йөзүче кораблар барлыкка китерүдә, Аллаһ күктән яварга дучар иткән яңгырда, ә аннан соң корыган җирне (су белән) терелтүдә һәм анда төрле җанварларны урнаштыруда, җилнең алмашынып исүендә, җир белән күк арасында [Аллаһ кодрәтенә] буйсынган болытларда, – боларның барысында да аңлы кешеләр өчен махсус билгеләр бар» (2:164).

Бу аять анда искә алынган барлык вакыйгаларны Аллаһның Барлыгына махсус билге – дәлил итеп бирә. Башка аятьләр төркемендә болай диелә:

أَفَلَا يَنْظُرُونَ إِلَى الْإِبِلِ كَيْفَ خُلِقَتْ (17) وَإِلَى السَّمَاءِ كَيْفَ رُفِعَتْ (18) وَإِلَى الْجِبَالِ كَيْفَ نُصِبَتْ (19) وَإِلَى الْأَرْضِ كَيْفَ سُطِحَتْ (20)

«Әллә чынлап та, алар дөяләрнең барлыкка китерелүе, күкнең ничек гөмбәз ителүе, тауларның калкып чыгуы, җирнең ничек җәелеп торуы турында уйлап карамыйлармы?» (88:17-20)



www.darul-kutub.com

Бу аять Аллаһ барлыкка китергән нәрсәләр турында уйланырга чакыра. Шушы уйланулар кешене һичшиксез Аның Барлыгына инану турындагы фикергә этәрәчәк.

Аллаһның Барлыгын раслауның икенче төре булып кешенең асылына нигезләнгән раслау тора (фитр). Һәр кеше тумыштан Аллаһка инанып туа һәм яши. Бу инану беркайчан да юкка чыкмый, һәрдаим кешедә саклана. Аның рухи үсешенә бәйле рәвештә ул көчәеп китәргә яисә рухи чигенеше аркасында бөтенләй сүнәргә мөмкин. Кешеләрнең иң авыр вакытларында бары тик Аллаһка мөрәҗәгать итүе тумыштан килгән инануны раслый. Коръәндә әйтелә:

وَإِذَا مَسَّ الْإِنْسَانَ الضُّرُّ دَعَانَا لِجَنْبِهِ أَوْ قَاعِدًا أَوْ قَائِمًا فَلَمَّا كَشَفْنَا عَنْهُ ضُرَّهُ مَرَّ كَأَنْ لَمْ يَدْعُنَا إِلَى ضُرٍّ مَسَّهُ كَذَلِكَ زُيِّنَ لِلْمُسْرِفِينَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

«Кешене кайгы басканда, ул яткан, утырган, баскан килеш тә Безгә мөрәҗәгать итә. Без аны хәсрәтеннән коткаргач, ул Безгә мөрәҗәгать итмәгән кебек читләшә, китеп бара» (10:12).

Шушы раслауга бер мисал: Җәгъфәр әс-Садыйк, Аллаһ аңа мәрхәмәтен ирештерсен, бер имансыз белән сөйләшкәндә сорый: «Синең кайчан да булса диңгездә йөзгәнең бармы?» Теге: «Әйе», – ди. Һәм Җәгъфәр дәвам итә: «Ә куркыныч вакыйгаларга эләккәнең булдымы?» Теге сөйли башлый: «Бервакыт без давылга эләктек, безнең кораб җимерелде. Мин такта кисәгенә ябыштым, ләкин ул минем кулымнан ычкынды. Бераз вакыттан соң дулкын мине ярга чыгарып ташлады». Җәгъфәр тыңлап бетерә дә, әйтә: «Сәяхәт башында

www.darul-kutub.com

син корабка һәм командага ышангансың. Кораб җимерелгәч, син тактага ышангансың. Такта да кулыңнан ычкынгач, син үлем белән килештеңме яисә котылуга өметләндеңме?» Теге җавап бирә: «Мин котылырмын, дип өмет иттем». Җәгъфәр сорый: «Кемнән котылу көттең соң?» Имансыз дәшмәгән һәм Җәгъфәр үзе җавап биргән: «Син котылуны сине Барлыкка китергән Аллаһтан көткәнсең».

Суфиларның да бу турыда фикерләре шактый кызыклы. Алар фикеренчә, кешеләргә билгеле булган яшәешнең иң бәхәссезе Аллаһның Бар булуы. Кешегә Аллаһның Барлыгын белүдән дә ачыграк һәм һичшиксез билгеле булган башка белем бирелмәгән. Бөек Илаһның Барлыгын раслауда хаҗәт юк. Чөнки ачыктан-ачык билгеле булган нәрсәне раслау – мәгънәсезгә көч түгү ул[1].

Дин галимнәре, гадәт буенча, бүгенгә кадәр үзләрен Барлыкка Китерүченең Барлыгын раслаучы дәлилләр эзләү белән мәшгуль. Шулай да яңа дәлилләр еш кына заманча фәнни ачышлар һәм теорияләр белән бәйле. Шундый дәлилләргә берничә мисал китерик:

1. Галәмнең үзеннән-үзе юктан бар булу мөмкинлеге чиктән тыш аз. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте кануны буенча һәр нәтиҗәнең үз сәбәбе, һәр әсәрнең үз авторы, һәр нәрсәнең Барлыкка Китерүчесе булырга тиеш. Димәк, Галәм бар икән, аның мөмкин булган яшәешен Тәэмин итүче дә булырга тиеш. Галәмнең үзен-үзе барлыкка китерүе турындагы фараз, искиткеч картинаның рәссам катнашыннан башка гына ясалуы, реактив очкычның идарә итүчедән башка гына очуы яки диңгез корабының капитаннан башка һәлакәткә юлык-

[1] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 55.

мыйча гына йөзүе кебек мәгънәсез һәм мантыйк кануннарына туры килми торган фикер[1].

Әлеге дәлил Исламның беренче гасырларында ук туган. Аны еш кына имамыбыз Әбү Хәнифә, Аллаһ аңа мәрхәмәтен ирештерсен, исеме белән бәйләп карыйлар. Әбу Хәнифә хокук белеме галиме буларак танылса да, яшьлегендә, фикх гыйлеме белән тирәнтен шөгыльләнә башлаганчы, ул заманының динсезләре белән бәхәсләр алып бара торган булган.

Шулай бервакыт Әбу Хәнифә янына кылыч күтәргән бер төркем динсезләр килеп кергән. Алар аны үтерергә дип килгәннәр икән. Аларны күргән Әбу Хәнифә: «Сезгә бер сорау бирим әле, аннан соң теләсә нишләгез», – дигән. Тегеләр риза булган. Әбу Хәнифә болай дигән: «Давыллы диңгездән үзенең курсы буенча йөзеп баручы командасыз һәм капитансыз корабны күз алдына китерегез әле. Бу мөмкин хәлме?» Динсезләр: «Юк», – дип җавап биргән. Әбу Хәнифә тагын сораган: «Шушы корабтан бик күпкә катлаулырак булган дөньябыз үзеннән-үзе барлыкка килгән дип ничек раслый аласыз соң сез алайса?»

2. Аксым барлык тере организмнарның төп субстанцияләреннән берсе була. Мәгълүм булганча, аксым матдәсе биш элементтан: углерод, водород, азот, кислород һәм күкерттән гыйбарәт. Бер аксым күзәнәгендә кырык меңгә якын молекула бар. Бүгенге көндә табигатьтә ирекле бәйләнештә булган йөздән артык химик элемент барлыгы билгеле. Ә хәзер үзендә биш элементны берләштергән бары бер протеин күзәнәге барлыкка килү мөмкинлегенең процентлы нисбәте күпме булуын уйлап карыйк. Һәм моның өчен күпме вакыт һәм матдә сарыф ителәчәк?[2]

[1] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 56.

[2] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 58.



www.darul-kutub.com

3. Тагын бер мисал китерик. Җир шары үзенең күчәре тирәсендә сәгатенә 1000 миль тизлектә әйләнә. Әгәр дә җир шары башка тизлектә, әйтик, сәгатенә 100 миль тизлектә әйләнә торган булса, көннәр һәм төннәр хәзергедән шактый озынрак булыр иде. Нәтиҗәдә, озайтылган көн дәвамында барлык үсемлекләр көеп, ә озайтылган төн дәвамында калган үсемлекләр өшеп бетәр иде[1].

## Башлангычы булмау (әл-Кыйдәм)

Башлангычы булмаган яшәеш. Аллаһы Тәгалә дөньяда бар нәрсәне, шул исәптән вакытны да барлыкка китергән. Шул рәвешле, вакыт барлыкка килгәнгә кадәр Аллаһ булмаган дип уйлау мәгънәсез. Аллаһы Тәгалә һәрвакытта да булган, Аңа туу яки барлыкка килү кебек күренешләр хас түгел. Гомумән алганда, Аның барлыгы вакытка бәйле түгел. Башлангычы булмау «мәҗбүри яшәешнең» аерылгысыз атрибуты санала. Башлангычы булмауның капма-каршысы – барлыкка китерелгәннәр өчен хас туу. Аллаһы Тәгалә барлыкка килмәгән, барлыкка китерелмәгән һәм тумаган.

## Ахыры булмау, Мәңгелек (әл-Бәка)

Мәңгелек, ахырның булмавы. Аллаһ яшәешенең ахыры юк, Ул юкка чыкмаячак, бетерелмәячәк, үлмәячәк. Ахыры булмау «мәҗбүри яшәешнең» бер атрибуты ул. Башлангычы булмаганның ахыры да булмый. Ахыры булмаганның капма-каршысы – юкка чыгу. Аллаһы Тәгаләнең кайчан да булса юкка чыгуын фараз кылу буш, мәгънәсезлек. Аятьләрнең берсендә болай диелә:

[1] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 58.



www.darul-kutub.com

هُوَ الْأَوَّلُ وَالْآخِرُ

«Ул беренче дә, ахыргы да» (57:3).

## Барлыкка китергәннәреннән аерылып торуы (әл-Мүхаләфәт лил-хәвәдис)

Аллаһ Үзе барлыкка китергән нәрсәләреннән аерылып тора. Аллаһтан башка барлык нәрсәләр дә барлыкка китерелгән һәм алар пространство, вакыт, материя кысаларында тереклек итә. Аллаһы Тәгалә материаль дөнья объектларыннан аерыла. Аллаһ кеше күзаллавы кысаларына сыешмый. Барлыкка китерелгәннәрнең тән, төс, ис, үлчәм, форма, вакыт, пространство, зурлык, организм һәм әгъзалар кебек сыйфатлары Аңа хас түгел. Ул өлешләргә бүленми һәм өлешләрдән гыйбарәт түгел. Безнең әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәләр атом һәм молекулалардан тора. Аллаһы Тәгалә әлеге кисәкләрдән гыйбарәт түгел. Коръәндә болай диелгән:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ

«Аңа охшаш берни дә юк» (42:11).

Бөек Аллаһның Коръәндә искә алынган исем һәм сыйфатларының асылы дөньябыздагы әйберләрнең сыйфатларыннан аерыла. Шуңа күрә Аллаһның сыйфатлары нәрсәгә дә булса охшашландырусыз һәм чагыштыруларсыз, Аны гәүдәсез (шул рәвешле билгеле бер урынсыз) аңлатыла. Аллаһы Тәгаләгә Асылда да, сыйфатларында да, эш-гамәлләрендә дә охшашлар юк[1].

Әйе, Коръәннең кайбер аятьләрендә һәм хәдисләрдә сүзгә-сүз тәрҗемәдә мәгънәсе Аллаһны кешегә охшаш-

[1] Кара.: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 68.

ландыруга тиң гыйбарәләр очрый. Әмма андагы сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең чын мәгънәсе бары тик Аллаһка гына мәгълүм булганга күрә, безгә әлеге аятьләрне аңлатырга тырышып караудан баш тартырга кирәк.

Аллаһы Тәгалә сыйфатларын аңлатуның кыенлыклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Беренче сәбәп – кеше акылының чикләнгәнлеге.

2. Икенче сәбәп – кешеләр лексикасының ярлы булуы. Кешеләр теленең байлыгы турында никадәр генә сөйләмәсеннәр, теләсә-кайсы телдә хәтта хис-кичерешләрне, тойгыларны белдерү өчен дә сүзләр җитәрлек түгел. Мисал өчен, кешенең түбәндәге халәтен аңлатуны алыйк: аның йөрәге шашынып типте, йөзе кызарынды, ул еш-еш сулый иде. Бу тасвирлау ачуы чыккан, дулкынланган, гашыйк булган, курыккан һ. б. халәттәге кешеләргә туры килә. Ягъни өстәмә тасвирлама бирмичә, сүзнең нинди хис-кичереш турында барганлыгы аңлашылмый. Тагын бер мисалны карап китик. Тумыштан сукыр булган кешегә без «зәңгәр», «кызыл» яки башка төсләрне, гомерендә беркайчан да алма ашап карамаган кешегә алманың тәмен сүз белән аңлатып бирә алмыйбыз. Безнең телебез хис-кичерешләребезне тулысынча, тәфсилләп аңлату өчен гаять ярлы. Без беркайчан да күрмәгән Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын тасвирлау, аңлату өчен телебез бигрәк тә ярлы булып чыга.

3. Өченче сәбәп – телдә полисемия дигән күренешнең, ягъни бер сүзнең берничә мәгънәгә ия булуы, кайвакыт хәтта капма-каршы төшенчәләр белдерүенә бәйле. Мәсәлән, Коръәннең бер аятендә әйтелгән (сүзгә-сүз мәгънәсе): «Аллаһның куллары аларның куллары өстендә» (48:10). Кайбер галимнәр бу очракта «кул» сүзенең туры мәгънәсе,



www.darul-kutub.com

ягъни гәүдә әгъзасы буларак кулланылган, диләр. Ләкин бу Аллаһны Үзе барлыкка китергән бәндәләргә охшату була бит. Башка галимнәр исә сүз күчерелмә мәгънәдә кулланылган һәм «көч»не аңлата, дигән фикерне раслый. Бу телнең лексикасы күзлегеннән караганда кабул ителә. «Коръәндә «йад» дип язылганны кабул итәбез, әмма әлеге сүзнең кайсы мәгънәдә бирелүе бары Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм», диюче галимнәр төркеме дә бар. Бу караш Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең сахабалары фикеренә күбрәк туры килә.

Тагын бер мисал китерик. Аллаһ Коръәндә әйткән: «Чыннан да, Аллаһ алты көн эчендә күкләрне һәм җирне барлыкка китергән сезнең Хуҗагыз. Аннан соң Ул тәхеткә урнашкан» (7:54). Аятьтә «истава» фигыле кулланылган. Ул «күтәрелгән», «урнашкан», «биләгән» кебек берничә мәгънәне белдерә. Урта гасырларның һәм заманыбызның кайбер галимнәре, әлеге фигыль «утырган» мәгънәсендә файдаланылган, дигән фикер белдерәләр. Шуның белән алар Аллаһны кеше белән тиңләштерәләр. Сөнни галимнәре «биләгән» дигән мәгънә күздә тотыла, диләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хатыны Умм Саләмә, Аллаһ аннан разый булсын, бу хакта болай дигән: «“Истива” булуы мәгълүм, ләкин аның нәрсә белдерүен кеше акылы белән төшенү һич мөмкин түгел». Имам Мәлик тә үз фикерен әйтеп калдырган: «“Истива” булуы мәгълүм, әмма аның ничек булуы билгесез. Аңа ышану кирәк. Бу хакта уйлану, бәхәсләшү яңалык, ягъни бидгать санала». Күргәнебезчә, Исламны кабул иткән беренче гасырларда сахабалар һәм дин галимнәре моңа охшаш аятьләргә нинди дә булса аңлатма бирүдән баш тартканнар.

## Мөстәкыйль яшәешь (әл-Кыям би нәфсиһи)

Бу дөньяда барлыкка китерелгән барлык нәрсәләр һәм җан ияләре нәрсәгәдер бәйле һәм ниндидер мохтаҗлык кичерәләр. Кешегә, мәсәлән, яшәеше өчен, беренче чиратта, пространство, вакыт, гәүдә кирәк, аннан соң һава, су, ризык, тиешле температура, үзе кебек үк кешеләр кирәк. Аллаһы Тәгаләнең Барлыгы гына һичнәрсәгә дә бәйләнмәгән. Ул хәтта Үзе барлыкка китергән нәрсәләрнең барлыгына да мохтаҗ түгел. Коръәндә әйтелгән:

اللَّهُ الصَّمَدُ (2)

«Бернигә дә мохтаҗлыгы булмаган Аллаһ» (112/2).

## Бердәнберлек (әл-Вәһданийә)

Аллаһның Бердәнберлегенә динебездә зур игътибар ителә. Аллаһка тиңнәр дә, охшашлар да юк. Ул Үзенең Яшәешендә, Сыйфатларында һәм Гамәлләрендә Бердәнбер. Аллаһ математик күзлектән караганда сан буларак түгел, Үзенең уникальлеге белән Бердәнбер. Барлыкка китереп һәм барлыкка китерелгәннәр белән идарә итә алган Аңа охшаш башкалар юк. Коръәндә Аллаһның Бердәнберлеге түбәндәгечә раслана:

لَوْ كَانَ فِيهِمَا آلِهَةٌ إِلَّا اللَّهُ لَفَسَدَتَا

«(И, Мөхәммәд!) әйт: Аллаһтан башка илаһлар булса, җир белән күкләр юкка чыккан булыр иде»[1] (21:22).

[1] Ягъни Аллаһыдан башка илаһларның хакимияте яки идарәсе күздә тотыла.



www.darulkutub.com

## Тормыш (әл-Хәят)

Аллаһның «Тормыш» дигән атрибуты бар. Аллаһы Тәгалә тере һәм Ул барлык нәрсәләргә дә тормыш бирә. Аның тормышы мәңгелек. Ул тормышның башы да юк, ахыры да юк. Тормыш – Аллаһның камиллеген раслаучы атрибут, чөнки камил яшәешь шушы сыйфат барлыгында гына мөмкин. Үле нәрсә тере нәрсәне барлыкка китерү түгел, үзен дә терелтә алмый. Шушы дөнья бар икән һәм андагы күп нәрсә тере булганга, аны Барлыкка Китерүче дә тере булырга тиеш. Тормыш, яшәүнең капма-каршысы – үлем. Бу төшенчәне Аллаһның сыйфатларына кертеп карау ахмак-лык. Коръән аятьләренең берсендә Тормыш атрибуты турында болай диелгән:

وَتَوَكَّلْ عَلَى الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ وَسَبِّحْ بِحَمْدِهِ

«Үлми торган Терегә өмет багла һәм Аны мактап, Аңа шөкер ит» (25:58).

## Белем (әл-Гыйлем)

Аллаһның тагын бер сыйфаты – Белем. Аллаһы Тәгаләгә бар нәрсә дә мәгълүм. Ул үткән һәм булачак, яшерен һәм ачык нәрсәләр турында да белә. Шул ук вакытта Аллаһның белемнәре Ул барлыкка китергәннәрнең белемнәреннән нык аерыла. Ул белем артмый да, кимеми дә. Нәрсәдәндер хәбәрдар булу өчен Аның тырышлык куясы да юк, чөнки Ул бар нәрсә турында белә инде. Аллаһның белемнәре мәңгелек. Ләкин шул ук вакытта Ул кешенең нинди дә булса гамәлләр кылуына берничек тә тәэсир итми. Аллаһның әлеге сыйфаты мәҗбүри рәвештә булырга тиеш. Чөнки кешегә гади генә нәрсәләр эшләү өчен дә белем кирәк. Димәк,

дөньяны Барлыкка Китерүче аның төзелеше, яшәеше һәм үзенчәлекләре турында да белергә тиеш. Алай гына да түгел, боларның барысын да Ул Үзе үк барлыкка китерә. Коръәндә Илаһи Белем турында болай диелгән:

وَعِنْدَهُ مَفَاتِحُ الْغَيْبِ لَا يَعْلَمُهَا إِلَّا هُوَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ وَمَا تَسْقُطُ مِنْ وَرَقَةٍ إِلَّا يَعْلَمُهَا

«Анда барлык серле (яшерен) нәрсәләрнең ачкычы! Алар турында бары Ул гына белә. Ул җирдәге һәм диңгездәге нәрсәләрне дә белә. (Агачтан) яфрак та төшмәс Ул белмичә» (6:59).

### Ихтыяр (әл-Ирадә, әл-Машийга)

Алдагы илаһи сыйфат – Ихтыяр. Бөек Аллаһка теләк белдерү хас. Ул нәрсәләргә булырга, кайсыларына булмаска икәнен билгели, аларның урынын һәм вакытын сайлый: кайда һәм кайчан булырга яки кайда һәм кайчан булмаска икәнен ачыклый. Аллаһ теләгән нәрсәләр була, Ул теләмәгән нәрсәләр булмый. «Машийга» сүзе «ирадә» сүзенең мәгънәсе белән охшаш. «Ихтыяр» сыйфаты Барлыкка Китерүчегә һичшиксез хас булырга тиеш. Югыйсә, дөнья үзеннән-үзе барлыкка килгән булып чыгар иде. Коръәндә Аллаһның Ихтыяры турында әйтелгән:

لِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ يَهَبُ لِمَنْ يَشَاءُ إِنَاثًا وَيَهَبُ لِمَنْ يَشَاءُ الذُّكُورَ (49) أَوْ يُزَوِّجُهُمْ ذُكْرَانًا وَإِنَاثًا وَيَجْعَلُ مَنْ يَشَاءُ عَقِيمًا إِنَّهُ عَلِيمٌ قَدِيرٌ



www.darul-kutub.com

«Аллаһ күкләрнең һәм җирнең Хуҗасы. Ул Үзе теләгәннәрне булдыра, Үзе теләгәннәргә кыз бала насыйп итә, Үзе теләгән башкаларга ир бала бирә. Яисә Ул ир белән хатыннарны никахландыра да, Үзе теләмәсә, аларның балалары тумый» (42:49-50).

## Көч-Куәт (әл-Кудрат)

Аллаһның Көч-Куәте һәм Кодрәте чиксез. Шушы сыйфаты ярдәмендә Ул Галәм белән идарә итә, барлык булган нәрсәләргә йогынты ясый, барлыкка китерә, үзгәртә, саклый, юк итә һ. б. Галәмдә Аллаһның Кодрәте ирешмәгән берни дә юк. Кодрәт сыйфатының капма-каршысы – көчсезлек. Аллаһның көчсез булуы һич мөмкин түгел. Чөнки көчсез зат үзен-үзе дә карый алмый һәм, нәрсәнедер барлыкка китереп, аның белән идарә дә итә алмый. Аллаһның Кодрәтен берни белән дә чагыштырып булмый. Мәсәлән, Аллаһ атом электр станциясеннән миллион тапкырга көчлерәк дип әйтергә ярамый. Аның Көче белән Кодрәте чиксез һәм абсолют. Коръәндә Илаһи Кодрәт турында әйтелгән:

أَلَمْ تَرَى أَنَّ اللَّهَ يُزْجِي سَحَابًا ثُمَّ يُؤَلِّفُ بَيْنَهُ ثُمَّ يَجْعَلُهُ رُكَامًا فَتَرَى الْوَدْقَ
يَخْرُجُ مِنْ خِلَالِهِ وَيُنَزِّلُ مِنْ السَّمَاءِ مِنْ جِبَالٍ فِيهَا مِنْ بَرَدٍ فَيُصِيبُ بِهِ
مَنْ يَشَاءُ وَيَصْرِفُهُ عَنْ مَنْ يَشَاءُ يَكَادُ سَنَا بَرْقِهِ يَذْهَبُ بِالْأَبْصَارِ(43) يُقَلِّبُ
اللَّهُ اللَّيْلَ وَالنَّهَارَ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَعِبْرَةً لِأُولِي الْأَبْصَارِ (44) وَاللَّهُ خَلَقَ كُلَّ
دَابَّةٍ مِنْ مَاءٍ فَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى بَطْنِهِ وَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى رِجْلَيْنِ
وَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى أَرْبَعٍ يَخْلُقُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ إِنَّ اللَّهَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ
قَدِيرٌ(45)

www.darul-kutub.com

«Аллаһның болытларны таратып, аннары яңадан бергә куып китереп, зур куе болытларга әверелдереп, алардан коеп яңгырлар яудыруын күрмисеңмени син? Бозлар яудыручы кара болытларны да күктә Ул йөздертә, теләгән затларына боз яудырта, теләгәнен – саклап кала. Аның яшеннәренең яшьнәве (кешеләрне) сукырайтырга мөмкин. Аллаһ көн белән төнне чиратлаштыра. Күзе күргән кешеләр өчен бу чын гыйбрәт. Аллаһ барлык хайваннарны да судан яраткан. Алар арасында үрмәләүчеләр дә, ике аякта йөрүчеләр дә, дүрт аяклылар да бар. Аллаһ Үзе теләгәнен булдыра һәм Аның мөмкинлекләре көчле» (24:43-45).

## Сөйләм (әл-Каләм)

Аллаһның Сөйләм дигән сыйфаты да бар. Үзенең сөйләме белән Аллаһ пәйгамбәрләргә Изге Китапларны иңдергән, аларның кайберләре белән Ул хәтта сөйләшкән дә. Сөйләм дигән Илаһи сыйфат мәңгелек, аның башлангычы булмаган кебек, ахыры да юк. Аллаһы Тәгаләнең камиллеген ассызыклаганга күрә, әлеге сыйфат Илаһи Затка тәгаен хас. Сөйләмнең капма-каршысы булган сөйләшмәү һәм телсезлек Аллаһның Асылына туры килми. Шуңа күрә дә аларны Аллаһка карата куллану дөрес түгел. Кеше Аллаһы Тәгалә Сөйләменең асылына төшенә алмый. Әмма Аллаһ Сөйләменең авазлар яки хәрефләрдән гыйбарәт булмавын әйтә алабыз, чөнки алар барлыкка китерелгән нәрсәләр. Коръәндә Илаһи Сөйләм турында болай дип әйтелгән:

قُلْ لَوْ كَانَ الْبَحْرُ مِدَادًا لِكَلِمَاتِ رَبِّي لَنَفِدَ الْبَحْرُ قَبْلَ أَنْ تَنفَدَ كَلِمَاتُ رَبِّي وَلَوْ جِئْنَا بِمِثْلِهِ مَدَدًا



www.darul-kutub.com

«Әйт, [Мөхәммәд]: Хуҗамның сүзләрен язу өчен диңгез кадәр кара да җитмәс. Бер кара диңгезенә тагын бер кара диңгезе өстәсәләр дә, алар Хуҗамның сүзләре төгәлләнгәнче бетәр иде» (18:109).

## Юктан бар итү (әт-Тәквин)

Аллаһның Иҗат итү сыйфаты бар. Бу ниндидер бер нәрсәне юклыктан барлыкка китерү дигәнне аңлата. Булган материаллардан ниндидер әйберләр барлыкка китергән, сәнгать әсәрләре иҗат иткән кешедән аермалы буларак Аллаһы Тәгалә юктан бар итә. Бу күзлектән караганда, кеше иҗат итүче түгел, ә материяне бер формадан икенчесенә үзгәртеп коручы була. «Хальк», «Тахлик», «Иҗад», «Ихдас», «Ихтирагъ» «Тәквин» сүзенең синонимнары була. Аллаһы Тәгалә бердәнбер Иҗат итүче һәм Барлыкка Китерүче ул. Галәмдә Аллаһтан башка барлыкка китерелгән берни дә юк. Коръәндә бу сыйфат турында түбәндәгечә әйтелгән:

هُوَ اللَّهُ الْخَالِقُ الْبَارِئُ الْمُصَوِّرُ لَهُ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى يُسَبِّحُ لَهُ مَا فِي
السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ

«Ул – Аллаһ, Иҗат итүче, Барлыкка Китерүче, рәвеш бирүче» (59:24).

Әлеге бүлектә Аллаһы Тәгаләнең еш искә алына торган кайбер сыйфатлары гына атап узылды. Чынлыкта исә ул сыйфатларның саны күпкә артык һәм аларның бер өлеше Аллаһның исемнәреннән ясалган. Аллаһка шөкер, Мәңгелек, Көчле-Куәтле, Бердәнбер, Гыйлемле, Ишетүче, Күрүче, дөньяларның Хакыйкый Хуҗасына шөкер. Аллаһ бөекләрдән Бөек.

www.darulkutub.com

## Ишетү (әс-Сәмг)

Аллаһ барын да ишетә. Ул пышылдап һәм кычкырып әйткәнне дә ишетә, ачыктан-ачык һәм сер итеп әйткәнне дә ишетә. Нәрсә генә әйтелмәсен, ни генә сөйләнмәсен – Аллаһ һәрвакыт барысын да ишетә. Бер мизгелдә сөйләнгән сүзләрне ишетү өчен Аллаһка бернинди киртәләр дә юк. Ишетү өчен Аллаһка бернинди ишетү әгъзасы кирәкми. Кеше, ишетү өчен, колаклар, һава, киртәләр булмауга, әйбернең билгеле ераклыкта торуына мохтаҗ булса, Аллаһка боларның берсе дә кирәкми. Аның мөмкинлекләре киртәләр белән дә, ераклык яки спектр белән дә чикләнмәгән. Коръәндә Илаһи Ишетү турында болай диелгән:

قَدْ سَمِعَ اللَّهُ قَوْلَ الَّتِي تُجَادِلُكَ فِي زَوْجِهَا وَتَشْتَكِي إِلَى اللَّهِ وَاللَّهُ يَسْمَعُ تَحَاوُرَكُمَا إِنَّ اللَّهَ سَمِيعٌ بَصِيرٌ

«Аллаһ үзенең ире хакында синең [Мөхәммәд] белән бәхәсләшкән һәм Аллаһка ялварган хатынның сүзләрен ишетте. Аллаһ сезнең сөйләшүегезне дә ишетте, чөнки Аллаһ Ишетүче дә, Күрүче дә» (58:1).

## Күрү (әл-Бәсар)

Аллаһ барысын да Күрүче. Аллаһның Күрүеннән бернәрсәне дә яшереп булмый. Яшерен һәм ачыктан-ачык, яктылык һәм караңгылык – Аллаһы Тәгалә дөньядагы бар нәрсәне дә күрә. Кешегә күрү өчен күз, яктылык, киртәләрнең булмавы, әйбернең билгеле бер ераклыкта булуы кирәк. Кешенең күрүе төсләр спектрына, әйбернең зурлыгына һ. б. бәйле. Аллаһы Тәгалә әлеге кимчелекләрдән ирекле. Изге Коръәндә Аллаһның барысын да күрүе һәм барысын да ишетүе турында аятьләр күп. Шуларның берсендә әйтелгән:



www.darul-kutub.com

يَعْلَمُ خَائِنَةَ الْأَعْيُنِ وَمَا تُخْفِي الصُّدُورُ (19) وَاللَّهُ يَقْضِي بِالْحَقِّ وَالَّذِينَ
يَدْعُونَ مِنْ دُونِهِ لَا يَقْضُونَ بِشَيْءٍ إِنَّ اللَّهَ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ (20)

«[Аллаһка] ялган карашлар да, калебләргә яшеренгән хисләр дә күренә. Аллаһ һәркайсын гадел хөкем итә. Аннан башкаларга табынучылар өчен ул башкалар берни дә хәл итми. Аллаһ чыннан да Ишетүче һәм Күрүче» (40:19-20).

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

3. Абу Хамид Мухаммад ибн Мухаммад аль-Газали ат-Туси. Высочайшее из устремлений в раскрытии смыслов прекрасных имен Аллаха/ перевод с арабского Саяхова Р.Л. – Уфа, 2007. – 232 с.

4. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

5. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда).– М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

6. Валиуллин К. Гакыйда. – Казань: Иман, 1999. – 87 с.

7. Габдрахман Абу аль-Хасан аль-Джавзи. Борьба с сомнениями антропоморфистов. – Казань: Иман, 2006. – 72 с.

8. Габдулла аль-Кахтани. Кто они неохариджиты? / перев. с араб. – Казань: Иман, 2006. – 362 с.

www.darul-kutub.com

9. Ибн-Касир И. Тафсир аль-Кур’ан аль-‘азим. – Дамаск: Изд-во Дар аль-файха’, 1994. – Т.1–4.

10. Ибрагим Т. Антропоморфные описания Бога в Коране// Минарет, №3 (006), 2005. – С. 2–9.

11. Крачковский И. Ю. Коран (перевод). – Минск, 1990.

12. Курсави Г. Тафсир байан. – Казань: Типография Домбровского, 1915. – 192 с.

13. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (аль-Хикма аль-балига), предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: ТКИ, 2008. – 479 с.

14. Ульрих Р. Аль-Матуриди и суннитская теология в Самарканде. – Алматы: Фонд «XXI век», 1999. – 286 с.

15. Хасан бин Гали ас-Саккаф. Наставление высоким умам о достоверных и недостоверных аспектах «Хадиса о рабыне». – Казань: Иман, 2006. – 78 с.

## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Аллаһка ышануның мәгънәсен аңлатыгыз?

2. Аллаһның 99 исеме мөселманнар өчен нинди әһәмияткә ия? Алардан ничек файдаланалар?

3. Аллаһы Тәгаләнең Аллаһ, әр-Рахмән, әр-Рахим, әл-Мөтәкаббир, әл-Гаффәр, әр-Раззәк, әл-Хафиз дигән исемнәренең мәгънәсен кыскача аңлатыгыз.

4. Түбәндәге Илаһи сыйфатларны аңлатыгыз: әл-Вөҗүд, әл-Кыйдәм, әл-Бәка, әл-Мүхаләфәт лил-хәвәдис, әл-Кыям би нәфсиһи, әл-Вәһданийә, әл-Хәят, әл-Гыйлем, әл-Ирадә, әл-Кудрат, әл-Каләм, әт-Тәквин, әс-Сәмиг, әл-Бәсар. Коръәндә алар турында әйтелгән аятьләрне сөйләгез.

www.darul-kutub.com

5. Аллаһның барлыгын раслаучы нигезле дәлилләр китерегез.

6. Аллаһның Бердәнберлеген раслаучы дәлилләр китерегез.

7. Аллаһка карата кулланылганда «күктә», «Тәхеттә», «кул» сүзләрен ничек аңлатырга кирәк?

* * *

www.darul-kutub.com

## 2 БҮЛЕК

# ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ ЫШАНУ

«Мәләк/мәлә’икә» төшенчәсенең терминологик яктан килеп чыгышын тел белгечләре «‘аләка» һәм «лә‘ака» фигыльләренә бәйләп карыйлар. Аларның мәгънәсе илчелек, нинди дә булса мәгълүматны җиткерү, тапшыру дигәнне аңлата. Тикшеренүчеләрнең бер өлеше (мүхаккыйкын) «мәләк»нең нигезен «мәлик» («хөкемдар») сүзе тәшкил итә, дигән фаразны куәтли. Алар идарәче вазыйфаларын башкаручы фәрештәләр «мәләк», ә идарә итүче кешеләр «мәлик» («король, патша, хөкемдар») дип атала, дигән фикердә торалар.

Һәр мөселман фәрештәләрнең барлыгына, аларның нурдан яратылганлыгына һәм Аллаһы Тәгаләнең аларга вазыйфалар йөкләвенә ышанырга тиеш. Коръәндә фәрештәләргә ышану турында болай диелгән:

آمَنَ الرَّسُولُ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْهِ مِنْ رَبِّهِ وَالْمُؤْمِنُونَ كُلٌّ آمَنَ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ

www.darulkutub.com

«Илче һәм иманлылар Аллаһ иңдергәннәргә ышандылар. Барысы да Аллаһка, Аның фәрештәләренә… ышанды» (2:285). Икенче бер аятьтә әйтелгән:

يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا آمِنُوا بِاللَّه وَرَسُولِه وَالْكِتَابِ الَّذِي نَزَّلَ عَلَى رَسُولِهِ وَالْكِتَابِ الَّذِي أَنزَلَ مِنْ قَبْلُ وَمَنْ يَكْفُرْ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ فَقَدْ ضَلَّ ضَلاَلاً بَعِيدًا

«Аллаһка һәм Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның Илчеләренә, Ахирәт көненә ышанмаучылар бик нык ялгыша» (4:136). Фәрештәләр Аллаһның гүзәл, тәкъва, пакь, эчкерсез саф коллары саналалар.

Фәрештәләрне күз белән күреп булмый. Әмма бу хәл аларның барлыгын кире какмый. Фәрештәләрнең барлыгына акыл белән төшенү өчен күзгә күренмәс ультрамиләүшә һәм инфракызыл нурларның барлыгын искә төшерү җитә.

## 2.1. Фәрештәләрнең сыйфатлары

Фәрештәләр беренче кеше һәм пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламгә кадәр үк барлыкка китерелгәннәр. Бу хактагы аять:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلاَئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً

«Әйтте Аллаһ фәрештәләргә: ‘‘Җирдә башлык булдырам’’, – дип» (2:30). Башлык дигәндә кеше күз алдында тотыла. Кешене барлыкка китерү турында әйтелгәндә фәрештәләр инде булган, күрәсең.

Фәрештәләр армый-талмый һәм бертуктаусыз Аллаһка табыну өчен барлыкка китерелгәннәр. Коръәндә бу хакта болай диелгән:

يُسَبِّحُونَ اللَّيْلَ وَالنَّهَارَ لَا يَفْتُرُونَ

«Алар [Аллаһны] көндез дә, төнлә дә армыйча мактыйлар» (21:20). Икенче бер аятьтә әйтелгән:

فَالَّذِينَ عِنْدَ رَبِّكَ يُسَبِّحُونَ لَهُ بِاللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَهُمْ لَا يَسْأَمُونَ

«…синең Хуҗаң каршында булучылар Аны төнлә дә, көндез дә армый-талмый мактыйлар» (41:38).

Шул рәвешле хезмәт итсеннәр өчен Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне үзенчәлекле сыйфатлар һәм мөмкинлекләр белән бүләкләгән. Фәрештәләр, мәсәлән, нурдан яратылганнар. Гаишә, Аллаһ аннан разый булсын, сөйләп калдырган хәдистә әйтелгән: «Фәрештәләр нурдан яратылган…»[1] Шуңа күрә аларның кешеләрнеке кебек гәүдәләре юк.

Гәүдәләре булмаганга күрә, физиологик ихтыяҗлары да юк, ягъни алар ашамый да, эчми дә, йокламый да, үрчемиләр дә. Моны бер вакыйга раслый. Берзаман пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәлам янына кеше рәвешендә фәрештәләр килгәч, ул аларның ризыкка кагылмауларыннан хафага калган булган[2].

Гәүдәләре булмаган фәрештәләрнең җенесләре дә юк. Фәрештәләрне Аллаһның кызлары дип атаган мәҗүсиләрне Аллаһы Тәгалә шелтәләгән бер аятьтә түбәндәгеләр сөйләнелә:

وَجَعَلُوا الْمَلَائِكَةَ الَّذِينَ هُمْ عِبَادُ الرَّحْمَٰنِ إِنَاثًا أَشَهِدُوا خَلْقَهُمْ سَتُكْتَبُ شَهَادَتُهُمْ وَيُسْأَلُونَ

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-мала’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – С. 9.

[2] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-мала’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – С. 17.



www.darul-kutub.com

«Рахимленең коллары булган фәрештәләрне алар хатын-кызлардан санаган. Фәрештәләрне барлыкка китергәндә алар бар идемени? Аларның бу сүзләре язып куелды һәм моның өчен алардан сорау алыначак» (43:19).

Матди ихтыяҗлары булмау сәбәпле, фәрештәләр гөнаһ кылмый һәм тулысынча Аллаһка буйсынганнар. Бу хакта Коръәндә болай диелгән:

وَلَهُ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَمَنْ عِنْدَهُ لَا يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِهِ وَلَا يَسْتَحْسِرُونَ

«Аның янында булганнар табынудан туктамыйлар һәм авырыксынмыйлар» (21:19). Башка бер аятьтә әйтелә:

لَا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ

«…Аллаһ кушканнарны карышусыз үтиләр һәм Аңа итагать белән буйсыналар» (66:6).

Фәрештәләр акыллы затлар. Дин белгечләре моңа дәлил итеп, Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә кешене барлыкка китерәчәге турында әйткәч, аларның биргән җавабын китерәләр. Коръәндә фәрештәләр Аллаһтан болай дип сораганнар диелә:

أَتَجْعَلُ فِيهَا مَنْ يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ

«Җирдә бозыклык кылучы һәм кан түгүчеләрне барлыкка китерәсеңмени?» (2:30) Риваятьләрнең берсендә әйтелгәнчә, кешелек цивилизациясенә кадәр җирдә җеннәр цивилизациясе хөкем сөргән булган. Гөнаһларга батканнары аркасында алар юк ителгән. Фәрештәләр шуларны күздә тотып, Аллаһка шундый сорау биргәннәр.

www.darul-kutub.com

Акыллары булгач, фәрештәләрнең аларга Аллаһы Тәгалә биргән берникадәр белемнәре дә бар. Ләкин алар барысын да белә алмыйлар. Фәрештәләр Аллаһтан кешене барлыкка китерү турында: «Җирдә бозыклык кылучы һәм кан түгүчеләрне барлыкка китерәсеңмени?» – дип сорагач, Аллаһы Тәгалә аларга болай дип җавап кайтарган:

إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ

«Чынлыкта Мин сез белмәгәннәрне беләм!» (2:30) Шул ук вакытта Аллаһ аларны үзлектән, мөстәкыйль белем туплау мөмкинлегеннән дә мәхрүм иткән. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

وَعَلَّمَ آدَمَ الْأَسْمَاءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى الْمَلَائِكَةِ فَقَالَ أَنْبِئُونِي بِأَسْمَاءِ هَؤُلَاءِ إِنْ كُنتُمْ صَادِقِينَ (31) قَالُوا سُبْحَانَكَ لَا عِلْمَ لَنَا إِلَّا مَا عَلَّمْتَنَا إِنَّكَ أَنْتَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ (32)

«Аллаһ Адәмгә барлык исемнәрне өйрәткәннән соң, фәрештәләрдән шул исемнәрне аңлатып күрсәтергә кушып сораган: "Ә хәзер, ихлас булсагыз, әлеге исемнәрнең [асылын] аңлатып бирегез", – дигән. Фәрештәләр: "Синә шөкер итәбез! Без Син өйрәткәннәрне генә беләбез. Чыннан да, Син барысын да Белүче, Гыйлем иясе"» (2:31-32).

Аллаһ кушканнарны үтәү өчен, Ул аларны үзенчәлекле сәләтләр белән дә бүләкләгән.

Беренчедән, алар төрле кыяфәтләргә керә алалар. Коръәндә әйтелгәнчә, Җәбраил фәрештә Мәрьям каршысына чибәр ир-ат рәвешендә килә торган булган. Аятьләрнең берсендә әйтелә:



www.darul-kutub.com

فَاتَّخَذَتْ مِنْ دُونِهِمْ حِجَابًا فَأَرْسَلْنَا إِلَيْهَا رُوحَنَا فَتَمَثَّلَ لَهَا بَشَرًا سَوِيًّا

«Без аның янына Безнең рухыбызны җибәрдек һәм ул кеше рәвешенә керде» (17:19). Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам сахабалары каршына Җәбраил фәрештә ап-ак киемнәр кигән, чем-кара чәчле кеше кыяфәтендә килеп баскан[1].

Икенчедән, фәрештәләр бик зур тизлек белән хәрәкәт итәләр. Мәгълүм булганча, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам янына сахабалары төрле сораулары һәм мөрәҗәгатьләре белән еш килгәләгәннәр. Кайвакыт Җәбраил фәрештә әзер җавап белән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә сахабалар сорауларын әйтеп бетергәнче килеп җитә торган булган. Андый тизлек белән хәрәкәт итү өчен Аллаһы Тәгалә аларга канатлар биргән. Коръәндә бу хакта болай диелә:

الْحَمْدُ لِلَّهِ فَاطِرِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ جَاعِلِ الْمَلَائِكَةِ رُسُلًا أُولِي أَجْنِحَةٍ مَثْنَى وَثُلَاثَ وَرُبَاعَ

«Күкләрне һәм җирне барлыкка китерүче, вәкил итеп икешәр, өчәр, дүртәр канатлары булган фәрештәләрне билгеләгән Аллаһка шөкер» (35:1). Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам Җәбраил фәрештәнең алты йөз канаты барлыгы турында сөйләгән булган[2].

Өченчедән, фәрештәләр зур көчкә һәм мөмкинлекләргә ия. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам

[1] Кара.: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-мала’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – С. 26.

[2] Кара.: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-мала’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – С. 14.



www.darul-kutub.com

Мәккәдән ерак булмаган Таиф шәһәре халкына вәгазь сөйләргә дип килгәндә, мәҗүсиләр аны ташлар атып куганнар. Шулвакыт Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам янына Җәбраил фәрештәне хәбәр белән җибәргән: «Сине мәсхәрәләгән кешеләр хакында син әмер бирсен өчен [1], Аллаһ мине синең яныңа җибәрде»[2].

Әмма фәрештәләр дә, барлык җан ияләре кебек үк, мәңгелек түгел, ягъни алар да үләчәк. Мондый нәтиҗәне дин галимнәре түбәндәге аятькә нигезләнеп ясаган:

كُلُّ شَيْءٍ هَالِكٌ إِلَّا وَجْهَهُ

«Аннан[3] башка барлык нәрсәләр дә, затлар да фани (мәңгелек түгел)» (28:88).

## 2.2. Фәрештәләрнең вазыйфалары

Аллаһ фәрештәләргә алар карышмыйча башкара торган аерым вазыйфалар бүлеп биргән. Дин галимнәре күп санлы фәрештәләр арасыннан дүрт бөек фәрештәне аерып карыйлар.

1. Җәбраил фәрештәнең төп вазыйфасы – Аллаһның вәхиләрен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә җиткерү. Ул баш фәрештә санала. Шуңа күрә аны «Сәйид әл-мәлә’икә» («Фәрештәләрнең башлыгы») дип тә атыйлар. Җәбраил дигән исеменнән башка, аять һәм хәдисләрдән билгеле булганча, аның тагын Рух, Рух әл-әмин, Рух әл-куддус, Расүл кәрим, Намус Әкбәр, Габдулла, Җәбралла, Җәбәруталла дигән исемнәре дә бар.

---

[1] Шушы кабиләне юк итү турында сүз бара.

[2] Мухаммад аль-Худри. Нур аль-йакын. – б. м.: Мавераннахр, 1992. – С. 53.

[3] Аллаһыдан.



www.darul-kutub.com

2. Микаил фәрештә табигать күренешләре, һава торышы һәм Аллаһның мәхлуклары арасында ризыкны тарату өчен җаваплы санала. Җәбраил һәм Микаил фәрештәләр Коръәндә дә исемнәре белән искә алыналар:

مَنْ كَانَ عَدُوًّا لِلَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَرُسُلِهِ وَجِبْرِيلَ وَمِيكَالَ فَإِنَّ اللَّهَ عَدُوٌّ لِلْكَافِرِينَ

«Аллаһка һәм Аның фәрештәләренә, илчеләренә, Җәбраилгә, Микаилгә дошман булганнар [белсеннәр]: Аллаһ Үзе дә имансызларның дошманы Ул» (2:98). Бу исә аларның Аллаһка якын булуларын күрсәтә.

3. Исрафил фәрештәнең вазыйфасы – Сур мөгезенә ике тапкыр өрү. Сур мөгезенә беренче тапкыр өрү Кыямәт көне башлануын белдерә һәм шуннан соң барлык җан ияләре үлеп бетәчәк. Сур мөгезенә икенче тапкыр өргәч, җир йөзендә аның башлангычыннан алып яшәгән барлык җан ияләре терелеп чыгачак. Хәдисләрдән мәгълүм булганча, Исрафил фәрештә Сур мөгезенә өререргә кушканны көтеп кенә тора икән.

4. Газраил фәрештә җанны тәннән аерып алып китүче фәрештәләрнең башлыгы. Бу фәрештәнең Газраил дигән исеме шикле чыганаклардан алынган, дигән фикер бар. Аның чын исеме – «Мәләк әл-мәүт» («Үлем фәрештәсе»). Аның кеше җаннарын алучы ярдәмчеләре дә бар.

Югарыда атап кителгән бөек фәрештәләрдән тыш аять һәм хәдисләрдә шулай ук башка фәрештәләр дә искә алына.

Кирамән катибин («Намуслы язмачылар»). Гомере буе кешенең янында йөреп, аның гамәлләрен язып баручы ике

www.darulkutub.com

фәрештә. Аларның уң як иң башы янында торучысы – яхшы гамәлләрне, ә икенчесе – сул як иң башы янында торучысы – гөнаһларны язып бара. Коръәндә алар турында түбәндәгеләр әйтелгән:

وَإِنَّ عَلَيْكُمْ لَحَافِظِينَ (10)كِرَامًا كَاتِبِينَ (11)يَعْلَمُونَ مَا تَفْعَلُونَ (12)

«Чыннан да сезнең яныгызда һәрвакытта да күзәтчеләр бар: намуслы язмачылар сезнең һәр гамәлегезне белеп тора» (82:10-12). Кыямәт көнендә әлеге фәрештәләр кешене яклап чыгачаклар, яисә аңа каршы шаһитлык кылачаклар [1].

Мөнкир һәм Нәнкир – кешеләр үлгәннән соң, алардан каберләрендә сорау алучы ике фәрештә. Үлгән кешеләргә күз күрмәгән, колак ишетмәгән кыяфәттә күренгәнлекләре аркасында аларга шундый исемнәр биргәннәр. Алар үлгән кешедән «Син кемгә табынасың? Пәйгамбәрең кем синең?» дип сорарлар. Кешенең гамәлләренә һәм җавапларына карап алар аңа яхшы яки тискәре мөнәсәбәттә булырлар.

Хамәләт әл-Гарш («Утыргычны тотып торучылар») Утыргычны (әл-Гарш) тотып торучы сигез фәрештә. Алар турында Коръәндә әйтелгән:

وَالْمَلَكُ عَلَى أَرْجَائِهَا وَيَحْمِلُ عَرْشَ رَبِّكَ فَوْقَهُمْ يَوْمَئِذٍ ثَمَانِيَةٌ

«Фәрештәләр күкләргә күтәрелер һәм [фәрештәләрнең] сигезе Аллаһның Утыргычын өсләренә күтәреп алып барырлар» (69:17).

Хазанәт җәннәт вә җәһәннәм («Җәннәт белән Җәһәннәмне саклаучылар») – Җәннәт белән Җәһәннәмдә булган гамәлләр

[1] Монда һәм алга таба кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 159–162.



www.darulkutub.com

өчен җаваплы фәрештәләр. Җәннәт фәрештәләре бик күп санлы, алар тәкъва мөселманнарга хезмәт итәләр.

Зобаный – Җәһәннәмне саклаучы фәрештәләр. Коръәндә язылганча, аларның саны унтугыз.

Мәлик – Җәһәннәмне саклаучы фәрештәләрнең башлыгы.

Ридван – Җәннәтне саклаучы фәрештәләрнең башлыгы.

Югарыда искә алынган фәрештәләрдән тыш күп кенә бүтән төрле вазыйфаларны һәм гамәлләрне башкаручы фәрештәләр дә бар. Мәсәлән:

Аллаһның Утыргычы тирәсендә булучы фәрештәләр.

Кешегә җан өрүче фәрештәләр.

Кешене саклаучы фәрештәләр.

Кайбер фәрештәләр кешеләрне илһамландыралар һәм аларга гаделлек белән хакыйкать төшенчәләрен аңларга ярдәм итәләр.

Фәрештәләрнең бер өлеше хак мөселманнар өчен дога кыла.

«Әл-Фатиха» сүрәсен укыганнан соң, намаз кылучы белән бергә «әмин» дип торучы фәрештәләр бар.

Кайбер фәрештәләр иртәнге һәм ахшам намазлары укылганда һәрвакыт янда торалар.

Фәрештәләрнең бер өлеше Коръән укылганда җиргә төшеп тыңлап торалар.

Фәрештәләрнең тагын бер өлеше Аллаһны шөкер итүчеләрне эзләп табалар.

Иманлы кешеләр һәм бигрәк тә мөселман дин галимнәре өчен Аллаһтан рәхим-шәфкать сораучы фәрештәләр дә бар.

www.darul-kutub.com

Кайбер фәрештәләр хак мөселманнарга турылыклы булырга ярдәм итәләр.

Шулай ук мөселманнарны Җәннәт турындагы хәбәр белән сөендерүче, ә имансызларны Җәһәннәм турындагы хәбәр белән көендерүче фәрештәләр дә бар.

Галәм өчен җаваплы, даими рәвештә Аллаһка табынуда булган фәрештәләр бар. Алар һаман да рокугъда (билдән бөгелеп) торучыларга һәм һаман да сәҗдәдә булучыларга, шулай ук Аллаһны даими мактап торучыларга аерылалар.

Тугры юлда булган яки белем туплаучы һ. б. мөселманнар өчен Аллаһка дога кылучы фәрештәләр бар.

Фәрештәләрнең аерым вазыйфалары, ә кайберләренең хәтта галәм өчен җаваплы булуларына карамастан, Аллаһ аларның хезмәт итүләренә мохтаҗ түгел. Чөнки Аның куәте чиксез. Ул дөнья белән фәрештәләрдән башка да идарә итә ала.

Фәрештәләрнең саны бик күп, аларның исәбен бер Аллаһ гына белә.

Йа Аллаһы Тәгалә, шушы нурлы затларга биргән рухи пакьлеккә безне дә ирештерсәң иде.

## 2.3. Җеннәр

Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән һәм кеше күзенә күренмәгән тагын бер төрле җан ияләре – ул җеннәр. Коръән белән Сөннәт буенча алар уттан яратылган. Фәрештәләр Аллаһның карышусыз коллары, Аның барлык кушканнарын да үтәүчеләр булса, җеннәр асыллары һәм рәвешләре белән кешегә охшаган. Коръән белән Сөннәттә җеннәрнең барлыгына ышануның мәҗбүрилеге турында аерым искә алынмаса

www.darulkutub.com

да, Коръәндә һәм Сөннәттә әйтелгәннәрнең барысы да хакыйкать булуга ышану мәҗбүри саналганга күрә, аларга ышану да кирәк. «Җен» термины «иҗтинан» фигыленнән барлыкка килгән. Ул «яшеренгән, күзгә күренми торган» дигәнне аңлата. Җеннәргә бу исем кешеләргә күренмәгәнлекләре аркасында бирелгән. Шуның белән алар исеме «анаса» («сизәргә, күрергә, тоемларга») фигыленнән барлыкка килгән кешегә – «инсан»га каршы куела.

## 2.3.1. Җеннәрнең сыйфатлары

Җеннәр дә, кешеләр кебек үк, Аллаһка табыну өчен генә барлыкка китерелгәннәр. Аятьләрнең берсендә бу хакта болай диелгән:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِي

«Җеннәрне һәм кешеләрне Миңа табынсыннар өчен генә барлыкка китердем» (51:56).

Дин галимнәре Коръән белән Шәригать җеннәр өчен дә җибәрелгән, дип саныйлар. Шуңа күрә алар да, кешеләр кебек үк, Аллаһка табынырга тиеш.

Кыямәт көнендә җеннәр дә гамәлләре өчен Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачак. Коръәндә Аллаһ кешеләргә һәм җеннәргә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итәр диелә:

يَامَعْشَرَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ أَلَمْ يَأْتِكُمْ رُسُلٌ مِنْكُمْ يَقُصُّونَ عَلَيْكُمْ آيَاتِي وَيُنذِرُونَكُمْ لِقَاءَ يَوْمِكُمْ هَذَا

«Әй, кешеләр һәм җеннәр көтүе! Яныгызга сезнең [туганнарыгыздан] [Аллаһ] илчеләре килеп, Минем аятьләремне



www.darul-kutub.com

сөйләп, сезне Кыямәт көне җитү турында кисәтмәдемени?» (6:130) Аларның җавабы:

قَالُوا شَهِدْنَا عَلَى أَنفُسِنَا

«Без үз-үзебезгә каршы шаһитлык кылабыз» (6:130). Нәтиҗәдә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

وَغَرَّتْهُمُ الْحَيَاةُ الدُّنْيَا وَشَهِدُوا عَلَى أَنفُسِهِمْ أَنَّهُمْ كَانُوا كَافِرِينَ

«Бу дөнья тормышы аларны кызыктырган һәм алар үзләренең гөнаһлы булуларын таныганнар» (6:130).

Җеннәр иманлы һәм имансызларга аерылалар. Имансызлары шайтаннар[1] дип атала һәм Иблис гаскәрен тәшкил итәләр. Бу хакта Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең төрле хәдисләрендә дә әйтелә. Аларда ул, иманлы җеннәргә зыян китермәү максатыннан, теге яки бу гамәлләрдән тыелып калырга өнди.

Җеннәр кешеләргә кадәр үк барлыкка китерелгәннәр. Бу хакта Коръәннең бер аятендә әйтелгән:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ (26) وَالْجَانَّ خَلَقْنَاهُ مِنْ قَبْلُ مِنْ نَارِ السَّمُومِ (27) وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي خَالِقٌ بَشَرًا مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ

«Чыннан да Без кешене коры балчыктан һәм ләмнән билгеле бер калыпта барлыкка китердек. Аннан алда без янган уттан җеннәрне [барлыкка китердек]» (15:26-27). Җеннәр цивилизациясе җирдә беренче кеше Адәм барлыкка китерелгәнгә кадәр ике мең ел элек хөкем сөргән инде. Ләкин алар, кан ко-

[1] «Шайтан» бүлекчәсендә җентекләбрәк язылган.

юлары һәм гөнаһларга батканлыклары сәбәпле, фәрештәләр гаскәре тарафыннан юк ителгәннәр[1].

Җеннәргә физиологик ихтыяҗлар хас. Шуңа күрә дә алар үз яшәешләрендә кешеләргә охшаган: ашыйлар да, эчәләр дә, балалар да тудыралар һ. б. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, җеннәр сөякләр һәм тирес белән тукланалар[2]. Икенче бер риваятьтә Катаданың «җеннәрнең балалары кеше баласы кебек үк туалар, тик аларның саны гына күбрәк була», дигән фикере бирелә[3].

Шул ук вакытта җеннәр кеше күзенә күренмәүләре белән фәрештәләргә охшыйлар. Ә алар кешеләрне күрә. Хәдисләрдә язылганча, Кыямәт көнендә бу хәл үзгәрәчәк, ягъни кешеләр җеннәргә күренмәс булып, җеннәр кеше күзенә күренә башлаячаклар.

Коръәндә һәм хәдисләрдә җеннәрнең үзенчәлекле сәләтләре барлыгы турында әйтелә.

Беренчедән, алар төрле кыяфәтләргә керергә мөмкин. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Сөннәтендә Бәдер сугышы көнендә шайтан, мәҗүсиләргә Суракә ибн Мәлик рәвешендә килеп, аларга ярдәм итәчәген вәгъдә иткән, дип белдерелә[4]. Шулай ук, казнаны саклаганда Әбу Хурайраның кеше рәвешендәге шайтан белән сөйләшүе турындагы риваять тә бар.

[1] Малик Ибрахим. Параллельный мир или многое, но не все о джиннах. – Казань: Идел-Пресс, 2004. – С. 47.

[2] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-джинни ва аш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – С. 25.

[3] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-джинни ва аш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – С. 27

[4] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-джинни ва аш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – С. 37–40.



www.darul-kutub.com

Икенчедән, алар зур тизлек белән хәрәкәт итә алалар. Бу хакта Бәлкыйс патшабикәнең көрсиенә кагылышлы риваять бар. Пәйгамбәр Сөләйман галәйһиссәлам үзенә буйсынучылардан сараена Бәлкыйснең көрсиен китерергә таләп иткәч, аларның берсе болай дип җавап кайтарган:

قَالَ عِفْرِيتٌ مِنْ الْجِنِّ أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَنْ تَقُومَ مِنْ مَقَامِكَ وَإِنِّي عَلَيْهِ لَقَوِيٌّ أَمِينٌ

«Син үз урыныңнан торып басканчы, мин аны китереп бирәчәкмен» (27:39), ә икенчесе әйткән:

قَالَ الَّذِي عِنْدَهُ عِلْمٌ مِنَ الْكِتَابِ أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَنْ يَرْتَدَّ إِلَيْكَ طَرْفُكَ

«Мин аны, күз ачып йомганчы, алып килеп бирәм» (27:40) [1].

Өченчедән, җеннәр күкләргә күтәрелә алалар. Коръәндә бу хакта җеннәр сүзләре китерелгән:

وَأَنَّا لَمَسْنَا السَّمَاءَ فَوَجَدْنَاهَا مُلِئَتْ حَرَسًا شَدِيدًا وَشُهُبًا

«Без күкләргә күтәрелергә омтылдык, тик анда безне көчле сакчылар һәм нур ияләре каршы алды» (72:8).

## 2.3.2. Шайтан

«Шайтан» сүзе гарәп телендә «каршы күтәрелгән, дошманлашкан» дигән мәгънәне белдерә. Аның Иблис дигән исеме дә бар. Ул гарәпчә «габләса» («өметсез, рухы төшкән») дигән фигыльдән ясалган. Аның мәгънәсе – «Аллаһның ра-

[1] Беренчесе – җен, ә икенчесе үзенчәлекле белемле кеше булган. Ягъни кешеләр арасында үзләренең мөмкинлекләре белән җеннәрне дә уздырган тәкъвалар була ала. Тик бу гадәттән тыш күренеш.



www.darul-kutub.com

химлегенә өмет өзгән». Шайтан иләмсез-ямьсез һәм куркыныч кыяфәтле, ике мөгезле җан иясе[1]. Риваятьләрнең берсендә сөйләнелгәнчә, фәрештәләр җирдә кешеләргә кадәр яшәгән җеннәр цивилизациясен тар-мар иткәннән соң, бер исән калган җенне тапканнар һәм аны үзләре белән күккә алып менеп киткәннәр. Анда алар аңа белем бирә башлаганнар һәм ул, үзенең тырышлыгы нәтиҗәсендә, фәрештәләрне дә уздырып җибәргән. Аңа Газазил исеме бирелгән.

Аллаһы Тәгалә, Адәмне барлыкка китергәннән соң, фәрештәләргә аның каршында сәҗдә кылырга кушкан. Газазилдән башкалар барысы да буйсынганнар. Шул мизгелдән соң ул Иблис дип йөртелә башлаган. Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр язылган:

وَإِذْ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا إِلَّا إِبْلِيسَ أَبَى وَاسْتَكْبَرَ وَكَانَ مِنْ الْكَافِرِينَ

«Шулвакыт Без фәрештәләргә: “Адәм каршында сәҗдә кылыгыз”, – дидек. Иблистән башкалар сәҗдә кылды. Ә ул [сәҗдә кылудан] баш тартты, тәкәбберләнде һәм имансызга әверелде» (2:34).

Аллаһы Тәгалә Иблистән ни өчен Адәм каршында сәҗдә кылмавы турында сорагач, ул болай дип җавап биргән:

أَنَا خَيْرٌ مِنْهُ خَلَقْتَنِي مِنْ نَارٍ وَخَلَقْتَهُ مِنْ طِينٍ

«Мин аннан яхшырак: Син мине уттан яраттың, ә ул балчыктан ясалган» (7:12). Нәтиҗәдә, ул Аллаһның рәхмәтеннән мәхрүм ителгән.

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-джинни ва аш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – С. 23.

Шушы вакыйгадан соң Иблис Аллаһка үзенең үлемен һәм җәзасын Кыямәт көненә кадәр кичектерү турында үтенгән. Үтенече кире кагылмагач, ул кешене төрле ысуллар һәм чаралар белән аздырырга вәгъдә биргән. Коръәндә бу хакта болай әйтелгән:

ثُمَّ لَآتِيَنَّهُمْ مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَنْ شَمَائِلِهِمْ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ

«Мин алар янына алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да һичшиксез килеп караячакмын һәм Син алардан күбесенең [Сиңа] шөкер итмәүләренә инанырсың» (7:17).

Соңрак, Адәм белән Һава[1], Җәннәттә яши башлаганнан соң, Иблис аларны Җәннәттән кудырту өчен бик нык тырышкан. Ләкин, Иблистән аермалы буларак, Адәм белән һава үзләренең хаталарын аңлаганнар һәм ярлыкау сораганнар. Шуңа да карамастан, алар җирдә яшәргә сөрелгәннәр. Иблис тә шунда җибәрелгән. Бу хакта Коръәндә Аллаһның сүзләре бар:

فَأَزَلَّهُمَا الشَّيْطَانُ عَنْهَا فَأَخْرَجَهُمَا مِمَّا كَانَا فِيهِ وَقُلْنَا اهْبِطُوا بَعْضُكُمْ لِبَعْضٍ عَدُوٌّ وَلَكُمْ فِي الْأَرْضِ مُسْتَقَرٌّ وَمَتَاعٌ إِلَى حِينٍ

«Әмма алар шайтан коткысы белән Җәннәттә гөнаһ кылдылар һәм аннан сөрелделәр. Шулвакыт Без әйттек: сезнең арада һәм [нәселләрегез арасында] дошманлык булсын!» (2:36). Шуңа күрә кеше белән шайтан арасындагы каршылык Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк.

[1] Библиядә Ева дип бирелгән.

«Шайтанны барлыкка китерү ни өчен кирәк булган соң?» дигән сорау туа. Әлбәттә, хакыйкать бары Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм, ләкин без дә фараз кылып карый алабыз: 1. Шайтанны барлыкка китерү – ул Илаһи Кодрәт һәм Гыйлемнең чагылышы. 2. Иманлы кеше өчен Шайтан яхшылык белән яманлык критерие булып тора. 3. Шайтан – иманлы кеше Җәннәткә керү өчен узарга тиешле сынау да әле ул[1].

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

3. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

4. ‘Али ат-Тантави. Та‘риф ‘ам би дин аль-Ислам. – Джидда: Дар аль-Манар, 1989.

5. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-джинни ва аш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – 208 с.

6. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алам аль-мала’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – 103 с.

7. Адыгамов Р. К. Мусульманское вероубеждение (акыда). – Казань: Иман, 2003. – 79 с.

8. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

[1] Кара: Малик Ибрахим. Параллельный мир или многое, но не все о джиннах. – Казань: Идел-Пресс, 2004. – С. 220–228.

www.darul-kutub.com

9. Валиуллин К. Гакыйда. – Казань: Иман, 1999. – 87 с.

10. Крачковский И. Ю. Коран (перевод). – Минск, 1990.

11. Малик Ибрахим. Параллельный мир или многое, но не все о джиннах. – Казань: Идел-Пресс, 2004. – 432 с.

12. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (аль-Хикма аль-балига), предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: ТКИ, 2008. – 479 с.

13. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 3, 356 с.

## ? Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. «Мәләʼикә» термины кайсы тамырдан килеп чыккан һәм ул нинди мәгънәне белдерә?

2. Коръәннән фәрештәләргә ышану турындагы аятьне әйтеп күрсәтегез.

3. Фәрештәләр кемнәр ул? Алар нәрсәдән яратылган?

4. Фәрештәләрнең кешедән алда барлыкка китерелүенә дәлил китерегез.

5. Фәрештәләр гөнаһ кыламы? Ни өчен?

6. Сөннәттән фәрештәләрнең канатлары булуга дәлил китерегез.

7. Фәрештәләрнең җиде сыйфатын атап бирегез.

8. Җәбраил, Микаил, Исрафил, Газраил фәрештәләрнең вазыйфаларын санап чыгыгыз.

9. Җәһәннәмне саклаучы фәрештәләрне һәм аларның башлыгын ничек атыйлар?



www.darul-kutub.com

10. Кирамән катибин кемнәр ул? Алар нинди вазыйфа башкара?

11. Мөнкир һәм Нәнкир кемнәр ул? Алар нинди вазыйфа башкара?

12. Сез тагын кайсы фәрештәләрне беләсез?

13. «Җен» сүзе кайсы тамырдан килеп чыккан һәм ул нинди мәгънә белдерә?

14. Җеннәрнең җиде сыйфатын атап чыгыгыз.

15. Җеннәр Кыямәт көнендә үзләренең гамәлләре өчен җавап тотачакмы? Раслап күрсәтегез.

16. Җеннәрнең кыяфәтләрен үзгәртеп, төрле рәвешләргә керүләренә мисаллар китерегез.

17. «Иблис» исеме гарәп телендәге кайсы фигыльдән ясалган?

18. Адәмгә баш имәвен шайтан ничек дәлилләде?

19. Шайтанны барлыкка китерү ни өчен кирәк булган?

20. Җеннәр кеше тормышына ничек тәэсир итә алалар?

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 3 БҮЛЕК

# ИЛАҺИ КИТАПЛАРГА ЫШАНУ

Аллаһы Тәгалә дөньяны һәм кешеләрне барлыкка китергән. Һәм шушы дөньяда кешеләрне яшәргә өйрәтү өчен Ул кешеләр арасыннан илчеләр сайлый торган булган. Аларга Аллаһ Җәбраил фәрештә аша Илаһи Китапларга теркәлгән вәхиләр җибәргән. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

كَانَ النَّاسُ أُمَّةً وَاحِدَةً فَبَعَثَ اللَّهُ النَّبِيِّينَ مُبَشِّرِينَ وَمُنذِرِينَ وَأَنزَلَ مَعَهُمُ الْكِتَابَ بِالْحَقِّ لِيَحْكُمَ بَيْنَ النَّاسِ فِيمَا اخْتَلَفُوا فِيهِ

«Кешеләр бер дини җәмгыятьне тәшкил иткәннәр. Аллаһы Тәгалә, кешеләргә фикер аермалыкларын бетерү өчен, илчеләр һәм алар белән бергә хакыйкый Китап җибәргән» (2:213). Иң танылган Илаһи Китапларның исемнәре Коръәндә искә алына. Аз танылганнары һәм исемсезләре турында Сөннәттә әйтелә. Әлеге Илаһи Китапларның кайберләре язма рәвештә сакланып калган. Еш кына Илаһи Китапларның берсе икенчесен тулыландыра торган булган. Бу Тәурат, Забур һәм Инҗилгә кагыла. Бары Коръән генә ан-

www.darulkutub.com

нан алдагы барлык Илаһи Китапларны кире какты һәм «әр-Рисалә әл-халидә» («Мәңгелек юллама») дип аталды. Илаһи Китапларда Аллаһы Тәгалә дин тәгълиматының нигезләрен, аерым кешенең һәм җәмгыятьнең тормышын җайга салучы нормалар һәм тыюлар, боерыклар кушылмасыннан гыйбарәт гамәли кануннарны аңлатып биргән. Коръәнгә кадәр булган Илаһи Китапларның текстларына монахлар һәм руханилар тарафыннан төзәтмәләр, ялгышлар һәм кеше сүзләре кертелгән. Бу хакта Коръәндә дә әйтелгән:

أَفَتَطْمَعُونَ أَنْ يُؤْمِنُوا لَكُمْ وَقَدْ كَانَ فَرِيقٌ مِنْهُمْ يَسْمَعُونَ كَلَامَ اللَّهِ ثُمَّ
يُحَرِّفُونَهُ مِنْ بَعْدِ مَا عَقَلُوهُ وَهُمْ يَعْلَمُونَ

«Алар арасында Аллаһның әйткәннәрен ишетүчеләр дә булган, ләкин соңрак, аның мәгънәсен аңлагач, алар аны белә торып үзгәрткәннәр» (2:75). Шул рәвешле алар яшәү өчен кулланма була алмыйлар. Әмма без, мөселманнар, әлеге Илаһи Китапларның Аллаһ тарафыннан кешеләргә яшәеш кулланмасы буларак җибәрелүен һичшиксез танырга тиеш. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

وَالَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا أُنْزِلَ إِلَيْكَ وَمَا أُنْزِلَ مِنْ قَبْلِكَ وَبِالْآخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ

«Сиңа тапшырылганнар һәм сиңа кадәр тапшырылганнарга ышанучыларны» (2:4). Әлеге Китапларның Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелүен кире кагу ышанмауга тиңләштерелә һәм кешене Исламнан чыгара.

www.darul-kutub.com

## 3.1. Вәхи: Илаһи Китапларны тапшыру ысулы

Вәхи – ул Аллаһы Тәгалә белән Аның пәйгамбәрләре арасындагы үзенчәлекле элемтә. Аның максаты: Аллаһның кануннарын кешеләргә тапшыру. Вәхи сүзенең лексик мәгънәсе «пышылдарга, сер итеп әйтергә, мөрәҗәгать итәргә, сөйләшергә, хатлар язарга» дигәнне аңлата.

«Вәхи» төшенчәсенә түбәндәгеләрне кертеп карарга мөмкин:

• Аллаһ белән турыдан-туры аралашу. Бу хәл Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам белән Мигъраҗ кичәсендә булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам бу кичәдә Аллаһы Тәгалә белән күрешкән һәм сөйләшкән. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, шушы күрешүдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә биш вакыт намаз уку кушылган.

• Хәбәр бирүче төшләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам күргән төшләр чынбарлыкта тормышка аша торган булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хатыны Гаишә[1] бу хакта түбәндәгеләрне әйтеп калдырган: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам күргән төшләр чынбарлыкта барлык нечкәлекләре белән чынга ашты. Алар иртәнге таң кебек ап-ачык була иде». Хәдисләрдә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең сахабалары бу хакта белгәнгә, үзе йокысыннан торганчыга кадәр аны уятмаганнар.

• Илһам. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам уяу чагында Җәбраил фәрештә Аллаһның кушканнарын Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи

[1] Һиҗри буенча 58 нче елда (б.э. 678 нче елында) үлгән.



www.darul-kutub.com

вәсәлламнең калебенә сеңдерә торган булган. Бу төрдәге вәхиләр турында Коръәндә болай диелгән:

نَزَلَ بِهِ الرُّوحُ الْأَمِينُ(193)عَلَى قَلْبِكَ لِتَكُونَ مِنَ الْمُنذِرِينَ(194)بِلِسَانٍ عَرَبِيٍّ مُبِينٍ(195)

«Чыннан да, Коръән – Дөньялар Хуҗасының хәбәре. Үгетләүчеләрнең берсе булсын өчен, аны синең калебеңә саф гарәп телендә Тугрылыклы Рух (Җәбраил) сеңдерде» (26:193-195). Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләренең берсендә бу төр вәхи турында әйтелгән: «Изге Рух (Җәбраил фәрештә) насыйп ризыгы бетмичә берәү дә үлмәячәк дигән хәбәрне минем калебемә сеңдерде. Аллаһка буйсынмаудан сакланыгыз. Насыйп ризыгыгызны эзләгәндә тугры юлдан язмагыз».

• Җәбраил фәрештә аша тапшырылган вәхиләр. Бу төр вәхине тагы да өч төркемгә бүлеп карыйлар:

✓ Кыңгырау чыңы. Бу очракта Җәбраил фәрештә күзгә күренмәгән. Ләкин ул килер алдыннан Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам кыңгырау чыңы ишетә торган булган. Харис ибн Хишам[1] исемле бер сахаба Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнән: «Әй, Аллаһның Илчесе, вәхиләр ничек иңә сиңа?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам аңа: «Кайвакыт алар кыңгырау чыңы кебек ишетелә. Бу минем өчен иң авыры. Бу халәттән чыгарга өлгергәнче, фәрештә миңа сөйләгән сүзләрне мин инде хәтердә калдырган булам», – дип җавап биргән.

[1] Һиҗри буенча 18 нче елда (б.э. 639 нчы елында) үлгән.



www.darul-kutub.com

✓ Фәрештәнең кеше кыяфәтендә килүе. Вәхи иңүнең иң җайлы юлы санала ул. Җәбраил фәрештә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам янына еш кына Духья әл-Калби исемле сахаба кыяфәтендә килә торган булган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бу хакта әйткән: «Кайвакыт фәрештә минем каршыма кеше рәвешендә килә, минем белән сөйләшә һәм мин аның әйткәннәрен хәтергә сеңдереп барам».

✓ Фәрештәнең чын кыяфәтендә күренүе. Бу рәвештә вәхиләр ике тапкыр тапшырылган. Беренче тапкыр Коръәннең беренче аятьләре иңгән көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам Хира[1] тау куышында чакта булганда. Икенче тапкыры Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам күкләргә менгән вакытта була.

## 3.2. Коръәнгә кадәр иңдерелгән Илаһи Китаплар

**Сухуф (Төргәкләр)**

Бу төр Илаһи Язмалар башкалардан үз исемнәре булмау һәм аз күләмлелекләре белән аерылып тора. «Сухуф» «сәхифә» («бит, төргәк») сүзенең күплек сандагы формасы. Алар Аллаһы Тәгалә тарафыннан аерым халыкларга аларның ихтыяҗларына карата тапшырылган төргәк яки берничә бит рәвешендә булган. Коръәндә бу төр Илаһи Язмалар турында түбәндәгеләр язылган:

أَمْ لَمْ يُنَبَّأْ بِمَا فِي صُحُفِ مُوسَى(36) وَإِبْرَاهِيمَ الَّذِي وَفَّى(37)

[1] Вәхи иңү алдыннан Пәйгамбәребез саләллаһу галәйһи вәссәлам шушы тау куышында аулак калып, Аллаһыга табына торган булган. Нәкъ менә шушы тау куышында аңа беренче вәхи иңгән. Хәзерге вакытта әлеге тау куышы Мәккә җирлегендә урнашкан һәм хаҗ кылучылар аны карап узалар.

www.darul-kutub.com

«Муса һәм дини кануннарга тугрылыклы булган Ибраһим Төргәкләрендә язылганнар турында аңа әйтмәделәрмени? (53:36-37).

قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكَّى(14) وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى (15) بَلْ تُؤْثِرُونَ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا (16) وَالْآخِرَةُ خَيْرٌ وَأَبْقَى(17)إِنَّ هَذَا لَفِي الصُّحُفِ الْأُولَى (18) صُحُفِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَى (19)

«[Дин ярдәмендә] пакьләнгән, Раббысының исемен зекер иткән (искә алган) һәм гыйбадәт кылганнар уңышка ирешкәннәр. Юк шул! Сез мондагы тормышны якын күрәсез. әмма киләсе тормышыгыз хәзергесеннән күпкә яхшырак һәм мәңгелек. Чынлыкта бу сүзләр элеккеге халыкларның Төргәкләрендә, ягъни Ибраһим белән Муса төргәкләрендә язылган» (87:14-19).

Тапшыру чылбыры зәгыйфь булган һәм Әбу Зарр[1] тапшырган хәдисләрнең берсендә Аллаһы Тәгалә йөз төргәк иңдергән, диелә. Аларның иллесе – пәйгамбәр Шис галәйһиссәламгә, утызы – пәйгамбәр Идрис галәйһиссәламгә, унысы – пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәламгә һәм тагын унысы пәйгамбәр Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән була. Соңгы унысы Муса галәйһиссәламгә Тәүрат иңдерелгәнчегә кадәр тапшырылган.

**Тәурат**

«Тора» белән тәңгәлләштерелгән Тәурат пәйгамбәр Муса галәйһиссәламгә иңдерелгән. Ул Китапта Муса галәйһиссәламгә иярүчеләргә кушылган Илаһи канун-

[1] Сахабаларның берсе һиҗри буенча 32 нче елда (б.э. 652 нче елында) үлгән.

нар язылган була. Коръәндә бу Илаһи Китап турында әйтелгән:

إِنَّا أَنزَلْنَا التَّوْرَاةَ فِيهَا هُدًى وَنُورٌ يَحْكُمُ بِهَا النَّبِيُّونَ الَّذِينَ أَسْلَمُوا لِلَّذِينَ هَادُوا وَالرَّبَّانِيُّونَ وَالْأَحْبَارُ بِمَا اسْتُحْفِظُوا مِنْ كِتَابِ اللَّهِ وَكَانُوا عَلَيْهِ شُهَدَاءَ فَلَا تَخْشَوُا النَّاسَ وَاخْشَوْنِي وَلَا تَشْتَرُوا بِآيَاتِي ثَمَنًا قَلِيلًا وَمَنْ لَمْ يَحْكُمْ بِمَا أَنزَلَ اللَّهُ فَأُولَئِكَ هُمُ الْكَافِرُونَ

«Һичшиксез, Без тугры юлга өндәүче һәм иман нуры белән яктыртучы кулланма булган Тәуратны иңдердек. Аллаһка буйсынган пәйгамбәрләр шуңа нигезләнеп яһүдиләр арасында карар кылганнар. Аллаһка тапшырылган тәкъвалар һәм галимнәр Аллаһы Тәгалә Китапта кушканнарны үтәгәннәр һәм алар моңа шаһит» (5:44).

Тәурат безгә беренчел рәвешендә килеп җитмәгән: аңа үзгәрешләр кертелгән. Бүгенге «Тора» (аны тагын Пятикнижие дип тә атыйлар) биш өлештән тора.

**Зәбур**

Псалтырь белән тәңгәлләштерелгән Зәбур Пәйгамбәр Дауд галәйһиссәламгә иңдерелгән. Коръәндә бу хакта болай диелгән:

وَآتَيْنَا دَاوُودَ زَبُورًا

«…һәм Без Даудка Зәбур тапшырдык» (17:55). Зәбур Тәуратка өстәмә булган, дип исәпләнә. Ул иң аз күләмле Илаһи Китап. Аңа яңа дини күрсәтмәләр кертелмәгән. Пәйгамбәр Дауд галәйһиссәламгә иңдерелгән Зәбурның эчтәлеге мәгълүм түгел.



www.darulkutub.com

Бүгенге Псалтырьгә псаломнар – дини-лирик эчтәлекле гимннар тупланган. Псалтырь христиан дине таралганчыга кадәр дә, христиан дине яңа гына тарала башлаган чорда да киң кулланылган була. Псалтырь грек теленә тәрҗемә ителеп, христианча гыйбадәт кылуның нигезен тәшкил итә.

**Инҗил**

Евангелие белән тәңгәлләштерелгән Инҗил пәйгамбәр Гайсә галәйһиссәламгә иңдерелгән. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

وَقَفَّيْنَا عَلَى آثَارِهِمْ بِعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ مُصَدِّقًا لِمَا بَيْنَ يَدَيْهِ مِنْ التَّوْرَاةِ وَآتَيْنَاهُ الْإِنجِيلَ فِيهِ هُدًى وَنُورٌ وَمُصَدِّقًا لِمَا بَيْنَ يَدَيْهِ مِنَ التَّوْرَاةِ وَهُدًى وَمَوْعِظَةً لِلْمُتَّقِينَ

«Пәйгамбәрләрдән соң Без, элегрәк Тәуратта язылганнарның хакыйкыйлыгын раслату өчен, Мәрьямнең улы Гайсәне җибәрдек. Аңа Без Инҗилне бирдек. Ул Китапта тугры юлдан язмау турында кулланма һәм иман нуры бар иде. Ул элегрәк Тәуратта язылганнарны раслап, тәкъва кешеләр өчен кулланма һәм нәсихәт булып торды» (5:46).

Хәзерге заманда бүгенге Евангелиедән аерылып торган Инҗилнең төп нөсхәсе юк. Христиан дине тарала башлаган чорда эчтәлекләре берсеннән-берсе нык аерылган йөзләгән Евангелиеләр булган. Шул сәбәпле христианнар арасында еш кына каршылыклар, чуалышлар һәм фетнәләр купкалаган. Нәтиҗәдә, Византия императоры Константин христиан ел исәбе белән 325 нче елда христиан дине өйрәтмәләрен

www.darul-kutub.com

тәртипкә салу өчен духовный собор җыйган. Әлеге җыенда катнашкан меңнән артык христиан кешеләре дүрт Евангелиене канунлаштырганнар һәм аларга «Яңа Завет» дигән исем кушканнар.

## 3.3. Коръән

Коръән – Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә[1] иңдергән сүзгә-сүз Сөйләме. Кодси хәдисләреннән аны, беренчедән, Коръәннең барлык өлешләренең дә чын хакыйкый булуы, икенчедән, Коръәннең Аллаһы Тәгалә Сөйләме булуы аерып тора, ә хәдисләр бары тик аның мәгънәсен генә белдерә.

Коръән һәркайсы җүз дип аталган утыз өлешкә бүленә. һәр җүз хизб дип аталган дүрт өлешкә бүленә.

Моннан тыш, Коръән сүрә дип аталган йөз дә ундүрт бүлеккә бүленгән. Һәр сүрә аять дип аталучы өлешләргә бүленә. Коръәндә барлыгы якынча 6236 [2] аять бар. Иң озын сүрә – «әл-Бәкара» («Сыер сүрәсе»): 286 аятьтән гыйбарәт. Ә иң кыска сүрә – «әл-Кәүсәр» («Муллык») сүрәсендә 3 кенә аять бар. Коръәннең иң озын аяте – «әл-Бәкара» сүрәсенең 282 нче аятендә 172 сүз һәм 579 хәреф бар. Иң кыска аятьләрдә берничә хәреф кенә язылган. Коръәндә 77 437 сүз һәм 323 015 хәреф бар.

Коръәннең «әт-Тәүбә» (Гафу үтенү) сүрәсеннән башка һәр сүрәсе «БисмиЛләхи-р-Рахмәни-р-Рахим» сүзләре белән башлана. Ә «ән-Нәмл» (Кырмыскалар) сүрәсендә әлеге сүзләр ике тапкыр: сүрә башында һәм 30 нчы аятьтә кабатлана.

---

[1] Кара: Маджд Макки. Аль-Байан фи аркан аль-иман. – Джидда: Дар нур аль-матабат, 1999. – С. 160.

[2] Башка төрле саннар да бар. Коръән аятьләренең саны хакындагы каршылыклы фикерләр кайбер галимнәрнең аерым урыннарда ике аятьне бер итеп, ә икенчеләренең ике аятьне ике аять буларак карауларына бәйле.

Эчтәлегенә килгәндә, Коръәндә төрле пәйгамбәрләр, илчеләр, тәкъвалар һәм аларның замандашлары тормышыннан гыйбрәтле хикәяләр бирелгән. Аллаһы Тәгаләнең төрле мәхлуклары барлыкка китерелүенең камиллеге турында фикерләргә өндәү белән искә алына. Аллаһның төрле боерыклары һәм тыюлары санап кителә һәм аңлатыла. Дөнья яратылышы, дөнья корылышы һәм дин тәгълиматы мәсьәләләре карала.

Коръәннең аның үзенчәлекләрен тасвирлаучы илледән артык исеме бар: «Китаб» (Китап), «Фуркан» (Хакыйкатьне ялганнан аеручы), «Тәнзил» (Аллаһ тарафыннан иңдерелгән), «Зекер» (Аллаһы Тәгаләне искә алучы (зекер итүче) китап), «Хакк» (Хакыйкать), «Нур» (Иман нуры), «Каләмуллаһ» (Аллаһ Сүзе), «Хаблүллаһ» (Аллаһка илтүче җеп) һ. б.

Коръән Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә егерме өч ел дәвамында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам һәм аның сахабалары тормышындагы төрле вакыйгаларга мөнәсәбәтле рәвештә иңдерелгән. Шуны да искәртергә кирәк: Коръән дип аның бары гарәп телендәге нөсхәсе генә атала. Башкалар я тәрҗемә, яисә аңлатма (тәфсир) дип йөртелә. Шуңа күрә тәһарәтсез гарәп телендәге аятьләр булмаган тәфсирләргә һәм Коръән тәрҗемәләренә генә кагылырга рөхсәт ителә. Гарәп телендәге төп нөсхәне кулга алуы өчен мөселманның goселле һәм тәһарәтле булуы шарт.

Без Коръәннең, чыннан да, Илаһи Китап булуына ышанырга тиеш. Моны раслаучы берничә дәлил китерәбез.

Беренчедән, Аллаһы Тәгалә кешеләрне һәм җеннәрне чакырып, аларга Коръәнгә охшаш әсәр иҗат итәргә кушкан. Ләкин, әдәби гарәп телен искиткеч яхшы белүләренә дә карамастан, алар кушканны башкара алмаганнар.

Икенчедән, Коръән тәвәтүр ысулы белән тапшырылып килгән, ягъни Коръәнне тапшыручылар чылбырының һәр буынында тапшыручылар саны бик күп һәм аларның үзара килешеп Коръәнне үзгәртә алуларына шик туа.

Өченчедән, Коръәндә фәнни мәгълүмат бирелгән. Ул мәгълүматка галимнәр фәнни тикшеренүләр юлы белән бүгенге көндә төшенәләр. XIV гасыр элек андый тикшеренүләрне алып бару өчен гыйлемнәр дә җитәрлек булмаган, әсбап-җиһазлар да.

Коръән кешелек өчен соңгы Илаһи ачыш булып тора. Анда язылганнар Кыямәт көненә кадәр гамәлдә булачак. Моны Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнән соң бүтән пәйгамбәр булмаячагы турындагы хәдис раслый.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: Коръән үзгәртелмәгән бердәнбер Илаһи Китап ул. Аллаһы Тәгалә аны Үзе сакларга вәгъдә биргән:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

«Без искәртү иңдердек һәм Без аны саклыйбыз» (15:9).

Башка Илаһи Китаплардан аермалы буларак, Коръән беренчел чыганак телендә сакланган.

Шулай ук Коръәнне тапшыручылар чылбырының төзелү тәртибе турында да әйтеп узарга кирәк. Бүгенге көндә Коръәннең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламгә барып тоташкан күпсанлы тапшыручылар чылбырлары бар. Һәм Коръәнне белүчеләр (хафизлар) яттан тулысынча Коръән текстын гына түгел, хәтта аны тапшыручылар чылбырларын да беләләр.

www.darul-kutub.com

Коръән Аллаһы Тәгаләнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам пәйгамбәрлегенең дөреслеген раслаучы могҗизасы. Бер хәдистә бу хакта әйтелгән: «Үзенең замандашларына алар ышанмаслык могҗиза бүләк итмәгән бер генә пәйгамбәр дә юк. Миңа могҗиза буларак Аллаһның кушканнары бирелде». Билгеле булганча, Коръән гарәп әдәбиятының[1] чәчәк аткан чорында, аның иң югары дәрәҗәдә булган чагында иңдерелгән. Әмма Коръәннең теле ул чорның сүз осталарын шактый аптырашта калдырган. Чөнки моңа кадәр аларның аңа охшаш берни дә ишеткәннәре булмаган. Коръәндә бу хакта болай диелгән:

قُلْ لَئِنِ اجْتَمَعَتِ الْإِنسُ وَالْجِنُّ عَلَى أَنْ يَأْتُوا بِمِثْلِ هَذَا الْقُرْآنِ لَا يَأْتُونَ بِمِثْلِهِ وَلَوْ كَانَ بَعْضُهُمْ لِبَعْضٍ ظَهِيرًا

«Әйт, [Мөхәммәд]: "Кешеләр һәм җеннәр Коръәнгә охшаш берәр әсәр иҗат итү өчен сәләт-мөмкинлекләрен бергә туплаган һәм бер-берләренә ярдәмләшкән булсалар да, алар моны башкара алмаслар иде"» (17:88).

Йа, Аллаһы Тәгалә, безнең һәркайсыбызга Коръәнне уку мөмкинлеге бир һәм аны дөрес аңларга насыйп ит. Ул безнең һәркайсыбыз өчен дә рухи камилләшү юлында якты нур белән балкысын иде.

[1] Бигрәк тә шигърияте.

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавийййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгийййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘ийййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафийййа». Перевод с арабского языка. – Казань: Изд-во «Иман», 2006. – 232 с.

3. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

4. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

5. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – 268 с.

6. Аль-Бухари. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

7. Ахмад ибн Ханбал. Муснад. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

8. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

9. Ибн-Касир И. Тафсир аль-Кур’ан аль-‘азим. – Дамаск: Изд-во Дар аль-файха’, 1994. – Т.3, 769 с.

10. Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

www.darulkutub.com

## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Кешеләргә Илаһи Китапларны иңдерүнең хикмәте нидә?

2. Кайсы Илаһи Китаплар язма рәвештә сакланып калган?

3. Вәхигә билгеләмә бирегез.

4. Вәхинең төрләрен әйтеп чыгыгыз.

5. Фәрештә кеше кыяфәтендә китергән вәхиләргә мисаллар китерегез.

6. «Сухуф» дип аталган Илаһи язмалар турында сөйләгез.

7. Пәйгамбәрләрнең исемнәрен аларга иңдерелгән Илаһи Китапларның исемнәре белән уклар ярдәмендә тоташтырыгыз:

| | |
|---|---|
| Тәурат | Мөхәммәд |
| Зәбур | Муса |
| Инҗил | Дауд |
| Коръән | Гайсә |

8. Коръәнгә билгеләмә бирегез. Аның хәдисләрдән аермасы нидә?

9. Коръән сүрәләренең һәм Коръәндәге сүзләрнең исәбен әйтеп бирегез.

10. Коръәннең биш исемен әйтеп чыгыгыз.

11. Тәһарәтсез килеш Коръәнгә кагылырга рөхсәт ителәме? Ни өчен?

12. Коръәннең үзенчәлекләрен санап чыгыгыз.

13. Коръәннең могҗизалылыгы нидә?

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 4 БҮЛЕК

# ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ҺӘМ ИЛЧЕЛӘРГӘ ЫШАНУ

Пәйгамбәр гарәпчә «набаъ» («хәбәр») сүзеннән ясалган «нәбий» диелә. «’набаа» тамырдаш фигыленең мәгънәсе – «хәбәр итү», шуңа күрә «нәбий» кемгәдер нәрсәдер хакында хәбәр итүче була. Гакыйдәдә «нәбий» дип, билгеле бер кешеләр төркеменә (пәйгамбәрнең кабиләдәшләренә) Раббыбызның хәбәрләрен җиткерү өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан сайланган кеше атала[1].

Гарәп телендәге «рәсүл» («илче») сүзе «ирсәл» («җибәрү») нигезеннән килеп чыккан. «Гарсәлә» тамырдаш фигыле «җибәрде» мәгънәсен белдерә. Димәк, «рәсүл» – илче, вәкил була. Гакыйдәдә «рәсүл» дип Аллаһы Тәгаләдән билгеле бер максат белән җибәрелгән кешегә әйтәләр[2].

Белгәнебезчә, Аллаһы Тәгалә дөньядагы барлык нәрсәне дә яраткан. Димәк, Ул барлык нәрсәләр турында хәбәрдар. Ул галәмне, күк җисемнәрен, кешене, хайваннарны, җан-

---

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русуль ва ар-рисалят. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 13.

[2] Шунда ук кара. – Б. 13–14.

www.darulkutub.com

сыз әйберләрне, шулай ук әлеге мәхлуклар буйсынып яши һәм эшли торган кануннарны барлыкка китергән. Әлеге кануннарның бер өлешен кеше төпле фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә танып белергә мөмкин. Алар физика, химия, биология һәм башка төрле табигать, гуманитар һәм бүтән фәннәрнең кануннарыннан гыйбарәт. Кайбер кануннарга кеше төшенә алмый. Боларга җәмгыять, дини гамәлләр, теге дөньяга һ. б. кагылышлы аерым кануннар керә. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә вакыты-вакыты белән кешелек цивилизациясенең үсеше дәрәҗәсенә бәйле рәвештә кеше гадәтләрен төзәтүгә юнәлтелгән теге яки бу кануннарны җибәрә торган булган. Кешеләргә кануннарны җиткерү өчен Ул теге яки бу халык яки кабиләдән иң яхшы вәкилне сайлап алган һәм Җәбраил фәрештә аша аңа дини кануннарны иңдергән. Әлеге сайланган кешеләр пәйгамбәр яки илче дип атала. Алар кешеләр арасында иң яхшылары һәм үзләренең сыйфатлары белән хәтта фәрештәләрдән дә өстен булырга мөмкин. Ләкин сайланып алынганлыклары һәм үрнәк сыйфатларга ия булуларына да карамастан, Коръәндә аларның гади, үлемгә дучар ителгән кешеләр икәнлеге ассызыклана. Пәйгамбәрлекләре дә, илчелекләре дә аларның казанышы түгел. Ул Аллаһның Үзе теләгән кешесенә насыйп итә торган рәхим-шәфкате. Шулай да Аллаһы Тәгалә аларны аеруча хөрмәт итәргә куша.

Үзләренең вазыйфаларын пәйгамбәрләр кешеләргә Җәннәт вәгъдә итеп яки Җәһәннәм белән куркытып үтәргә тиеш булганнар. Коръәндә бу хакта болай диелә: «Без илчеләрне яхшы хәбәр китерүче һәм үгет-нәсыйхәт бирүче буларак кына җибәрәбез» (6:48). Шушы кешеләрнең пәйгамбәрлекләрен раслату өчен, Аллаһ аларның вәгазьләрен төрле могҗизалар белән дәлилли.

Барлык пәйгамбәр һәм илчеләргә дә бер үк төрле вазыйфа – үзләре яшәгән җәмгыятьтәге кешеләрне Бераллалыкка өндәү йөкләнелгән була. Шуңа күрә дә барлык пәйгамбәрләрнең дин тәгълиматлары һәм әдәп-әхлак нормалары тәңгәл булган. Аермалар бары тик гыйбадәт кылуда һәм кайбер хокукый нормаларда чагылыш тапкан.

Иң беренче пәйгамбәр – Адәм галәйһиссәлам, ә соңгысы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам булган. Гадәттә, пәйгамбәр итеп алардан алда булган пәйгамбәрләрнең нәсел дәвамчылары сайланган. Пәйгамбәрләрнең шәҗәрәләре дә бар хәтта[1].

Пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә ышану диннең төп баганаларыннан берсен тәшкил итә һәм һәр мөселманның бурычы була. Коръәндә бу хакта болай диелә:

آمَنَ الرَّسُولُ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْهِ مِنْ رَبِّهِ وَالْمُؤْمِنُونَ كُلٌّ آمَنَ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ
وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ لَا نُفَرِّقُ بَيْنَ أَحَدٍ مِنْ رُسُلِهِ

«Илче һәм иманлы бәндәләр аңа Аллаһтан иңдерелгәннәргә ышандылар. Барысы да Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, араларында бернинди дә аерма күрмичә, Аның илчеләренә ышандылар» (2:285).

Дин галимнәре Коръәндә атап кителгән түбәндәге егерме биш кешене пәйгамбәр дип таныйлар: 1) Адәм галәйһиссәлам, 2) Идрис галәйһиссәлам, 3) Нух галәйһиссәлам (Ной), 4) Худ галәйһиссәлам, 5) Салих галәйһиссәлам, 6) Ибраһим галәйһиссәлам (Авраам), 7) Лут галәйһиссәлам (Лот), 8) Исмәгыйль галәйһиссәлам (Измаил), 9) Исхак галәйһиссәлам (Исаак), 10) Ягъкуб галәйһиссәлам (Иаков), 11) Йосыф

[1] Кара: 2-нче кушымта.

www.darul-kutub.com

галәйһиссәлам (Иосиф), 12) Әйүб галәйһиссәлам (Иова), 13) Шүгаиб галәйһиссәлам, 14) Муса галәйһиссәлам (Моисей), 15) Харун галәйһиссәлам (Аарон), 16) Юныс галәйһиссәлам (Енох), 17) Дауд галәйһиссәлам (Давид), 18) Сөләйман галәйһиссәлам (Соломон), 19) Ильяс галәйһиссәлам (Илия), 20) Әл-Ясагъ галәйһиссәлам (Елисей), 21) Зәкәрийә галәйһиссәлам (Захария), 22) Яхья галәйһиссәлам (Иоанн), 23) Зөл-Кифел галәйһиссәлам (Иезекииль), 24) Гайсә галәйһиссәлам (Иисус), 25) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам.

Пәйгамбәрлекләре Коръәндә яки Сөннәттә искә алынмаган башка танылган кешеләрне пәйгамбәр дип тану һич ярамый[1]. Шулай да Аллаһы Тәгаләнең Коръәндә һәм Сөннәттә аталмаган башка күптөрле пәйгамбәрләрне җибәрүе хакында Коръәндә әйтелә. Аятьләрнең берсендә бу турыда әйтелгән:

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا رُسُلًا مِنْ قَبْلِكَ مِنْهُمْ مَنْ قَصَصْنَا عَلَيْكَ وَمِنْهُمْ مَنْ لَمْ نَقْصُصْ عَلَيْكَ

«Без сиңа кадәр дә илчеләр җибәрдек, әмма аларның кайберләре турында сиңа сөйләдек, ә кайберләре хакында – юк» (40:78). Икенче бер аятьтә болай диелә:

وَلِكُلِّ أُمَّةٍ رَسُولٌ

«Һәр халыкка – үзенең илчесе» (10:47). Бу Илаһи Гаделлекнең чагылышы дип санала.

---

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 26.

Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр арасыннан дин галимнәре бишесен аерып алып, аларны «улүл-газыйм» («бөеклек ияләре» яки «бөекләр») термины белән атыйлар. Болар: Мөхәммәд, Ибраһим, Муса, Нух, Гайсә. Коръәндә алар турында әйтелгән:

وَإِذْ أَخَذْنَا مِنْ النَّبِيِّينَ مِيثَاقَهُمْ وَمِنْكَ وَمِنْ نُوحٍ وَ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَى وَعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ وَأَخَذْنَا مِنْهُمْ مِيثَاقًا غَلِيظًا

«Без пәйгамбәрләрдән вәгъдә алдык: синнән дә, Нухтан да, Ибраһимнан да, Мусадан да, Мәрьямнең улы Гайсәдән дә катгый вәгъдә алдык» (33:7).

## 4.1. Пәйгамбәр белән илче нәрсә белән аерылалар?

Пәйгамбәр – вәхи иңдерү өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан сайлап алынган кеше. Раббыбыз аңа аннан алдагы пәйгамбәрләргә җибәрелгән кануннарны иңдерә һәм шуларны кешеләр арасында таратырга куша. Илче шул ук пәйгамбәр ул, тик Аллаһ аңа яңа Илаһи Кануннарны иңдерә.

Шулай итеп, пәйгамбәр белән илче арасындагы аерма – илчегә яңа Илаһи Кануннар һәм Китаплар иңдерелүдән, ә пәйгамбәрнең аннан алдагы пәйгамбәр һәм илчеләргә тапшырылганнарны өйрәтүдән гыйбарәт. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып нәтиҗә ясарга мөмкин: һәр илче пәйгамбәр була, әмма һәр пәйгамбәр дә илче була алмый.

## 4.2. Пәйгамбәрләр һәм илчеләрнең вазыйфалары

Югарыда әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә кешеләр арасыннан пәйгамбәрләр һәм илчеләрне сайлап алган һәм алар-

www.darul-kutub.com

га вәхи иңү, аны башка кешеләргә тапшыру, сахабаларны өйрәтүгә h. б. бәйле аерым вазыйфаларны йөкләгән. Аларны тәфсилләбрәк карап узыйк:

1. Пәйгамбәрләр Аллаһ иңдергән мәгълүматны кабул итәләр. Муса галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп сайлагач, Аллаһы Тәгалә аңа әйткән:

وَأَنَا اخْتَرْتُكَ فَاسْتَمِعْ لِمَا يُوحَى

«Мин сине [башка кешеләр] арасыннан сайлап алдым, инде сиңа вәхи буларак әйтелгәннәрне ишет» (20:13). Ягъни пәйгамбәр вәхине кабул итәргә һәм аңа иңдерелгән хәбәрне төшенергә тиеш булган.

2. Аллаһның хәбәрләрен кешеләргә тапшыралар. Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр әйтелгән:

يَاأَيُّهَا الرَّسُولُ بَلِّغْ مَا أُنزِلَ إِلَيْكَ مِنْ رَبِّكَ وَإِنْ لَمْ تَفْعَلْ فَمَا بَلَّغْتَ رِسَالَتَهُ

«Әй, Илче! Сиңа Раббыбыз җиткергәннәрне [кешеләргә] ирештер. Әгәр син моны үтәмәсәң, [шуның белән] син [кешеләргә] Аның кушканнарын җиткермәгән буласың» (5:67). Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын кешеләргә җиткерү пәйгамбәр һәм илчеләрнең төп вазыйфаларыннан берсе санала. Шуңа күрә дә хушлашу хаҗы вакытында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам үзенең «Хушлашу хаҗы вәгазе»ндә: «Мин сезгә динне тапшырмадыммени?» – дип сорагач, сахабалары аңа: «Әлбәттә, тапшырдың», – дип җавап кайтарганнар. Шуннан соң ул: «Йә, Раббым, шаһит бул»[1], – дигән.

[1] Бикбулат С. Хәзрәт Мөхәммәд. – Чистополь, 1999. – Б. 217.

3. Вәхиләрнең мәгънәләрен кешеләргә аңлаталар. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

يَاأَهْلَ الْكِتَابِ قَدْ جَاءَكُمْ رَسُولُنَا يُبَيِّنُ لَكُمْ كَثِيرًا مِمَّا كُنْتُمْ تُخْفُونَ مِنَ الْكِتَابِ وَيَعْفُو عَنْ كَثِيرٍ

«Әй, Китап әһелләре! Сезгә Китаптагы сез яшереп калдырган күп нәрсәләрне аңлату өчен, [гөнаһларыгызның] күбесен гафу итү өчен Безнең илчебез килде» (5:15). Коръәннең кайбер аятьләре Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең сахабаларына аңлашылмаган очракта, алар сораулар белән аның янына килгәч, ул мәгънәләрен аңлата торган булган. Мәсәлән: түбәндәге аять иңдерелгәннән соң:

كُلُوا وَاشْرَبُوا حَتَّى يَتَبَيَّنَ لَكُمْ الْخَيْطُ الْأَبْيَضُ مِنْ الْخَيْطِ الْأَسْوَدِ مِنْ الْفَجْرِ ثُمَّ أَتِمُّوا الصِّيَامَ إِلَى اللَّيْلِ

«Ак җептән карасын аерып булмаганга кадәр, ягъни таң атканчыга кадәр ашагыз һәм эчегез. Аннан соң төн җиткәнчегә кадәр тагын ураза тотыгыз» (2:187), – сахабаларның бер өлеше аны үзләренчә аңлаган, ә икенче өлеше бөтенләй дә аңламаган һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә ураза аенда таң җитүне ничек билгеләргә дигән сорау белән мөрәҗәгать иткәннәр.

4. Аллаһы Тәгаләнең Китапларда кушканнарын үтиләр. Пәйгамбәр яки илче Аллаһның кушканнарын үтәмәсә, аның дәвамчылары да моны башкармаячак: бу табигый. Шуңа күрә Раббыбызның кушканнары иң беренче чиратта нәкъ менә пәйгамбәр яки илчегә юнәлдерелгән. Мөхәммәд салләллаһу

www.darul-kutub.com

галәйһи вәсәллам һәм аның сахабаларының гыйбадәт кылуларын тасвирлап, Аллаһ Коръәндә әйткән:

إِنَّ رَبَّكَ يَعْلَمُ أَنَّكَ تَقُومُ أَدْنَى مِنْ ثُلُثَيِ اللَّيْلِ وَنِصْفَهُ وَثُلُثَهُ

«Чыннан да, Аллаһың синең һәм кайбер сахабаларыңның төннең икедән өч өлешеннән азрак вакытын яки аның яртысын, яки өчтән бер өлешен гыйбадәттә уздыруыгызны белә» (73:20).

5. Аллаһка ышанырга һәм табынырга үгетлиләр (өндиләр). Коръәндә бу хакта болай диелгән:

وَمَا أَرْسَلْنَا مِنْ قَبْلِكَ مِنْ رَسُولٍ إِلَّا نُوحِي إِلَيْهِ أَنَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا أَنَا فَاعْبُدُونِي

«Синнән алда җибәрелгән илчеләрнең барысы да “Миннән башка илаһ юк, шулай булгач Миңа гына табыныгыз”, дигәнне калебенә сеңдерде» (21:25). Бер Аллаһка ышану һәм Аңа гына табынуга өндәү барлык пәйгамбәр һәм илчеләр тәгълиматларының нигезен тәшкил итә.

6. Үзенең сахабаларын өйрәтә (тәрбияли). Коръәндә бу вазыйфа хакында әйтелгән:

هُوَ الَّذِي بَعَثَ فِي الْأُمِّيِّينَ رَسُولًا مِنْهُمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِهِ وَيُزَكِّيهِمْ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ

«Ул, белемсезләр арасыннан сайлап алып, аларга илче Җибәрүче. Илче аларга Аның аятьләрен ирештерә, аларның күңелләрен сафландыра, аларны Китапта язылганнарга өйрәтә» (62:2).

www.darul-kutub.com

7. Җәннәт рәхәтлекләре белән кызыктыралар һәм җәһәннәм җәзаларыннан тыелырга үгетлиләр. Коръәндә бу турыда түбәндәгечә сөйләнелә:

كَانَ النَّاسُ أُمَّةً وَاحِدَةً فَبَعَثَ اللَّهُ النَّبِيِّينَ مُبَشِّرِينَ وَمُنذِرِينَ

«Халык бер дини җәмгыять булып оешкан иде һәм Аллаһ аларга хәбәр китерүче һәм үгетләүче буларак пәйгамбәрләрне җибәрде» (2:213). Әлеге аятьнең гарәп телендәге вариантында «хәбәр китерүчеләр» сүзе «мөбәшширин» («сөендерүчеләр») сүзе белән, ә «үгетләүчеләр» сүзе – «мүнзирин» («кисәтүче, искәртүче») сүзе белән бирелгән.

8. Үз халыклары белән идарә итәләр һәм казый (хөкемдар) вазыйфаларын башкаралар. Коръәндә Аллаһның Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә бу хакта кушканнары язылган:

فَاحْكُمْ بَيْنَهُمْ بِمَا أَنزَلَ اللَّهُ

«Аллаһ кушканча хөкем ит аларны» (5:48). Тик пәйгамбәр һәм илчеләрнең барысы да дәүләт башлыклары булмаган, күбесе бары үзләренең сахабалары белән генә җитәкчелек иткән.

9. Кыямәт көнендә үзләренең халыкларын яклап яки каршы шаһитлык кылырга тиешләр. Бу вакыйгалар хакында Коръәндә болай диелгән:

وَيَوْمَ نَبْعَثُ فِي كُلِّ أُمَّةٍ شَهِيدًا عَلَيْهِمْ مِنْ أَنفُسِهِمْ وَجِئْنَا بِكَ شَهِيدًا عَلَى هَؤُلَاء



www.darul-kutub.com

«Һәр җәмгыятьнең кешеләренә каршы алар арасыннан шаһитны билгеләгән көнне Без сине дә [Мәккә мәҗүсиләренә] каршы шаһит итеп бастырдык» (16:89). Аллаһ пәйгамбәр һәм илчеләргә Үзенең боерыкларын кешеләргә тапшырырга кушкан һәм алар моны намус белән башкардылар. Кешеләр шул Китапларда кушканнар буенча яшәргә тиеш. Кыямәт көнендә пәйгамбәр һәм илчеләр кешеләрнең Аллаһы Тәгалә кушканнарны ничек үтәүләренә шаһит булачаклар.

## 4.3. Пәйгамбәрләрнең сыйфатлары

1. Барлык пәйгамбәрләр дә гади кешеләрдән булган (әлбәшәрийә). Коръәндә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә болай дип әйтергә кушылган:

قُلْ إِنَّمَا أَنَا بَشَرٌ مِثْلُكُمْ

«Әйт: “Чыннан да, мин сезнең кебек үк кеше”» (18:110). Аллаһның кушканнарын кешеләргә бары тик кеше генә тапшырырга, аңлатырга мөмкин, үзенең яшәеше белән башкаларга Илаһи Китап буенча ничек яшәргә тиешлекне үрнәк итә ала. Пәйгамбәр яки илче итеп башка җан ияләре сайланган булса, бу хәл кешеләргә Аллаһның Кануннарын үтәүдән баш тартырга сылтау булыр иде. Бу турыда Коръәндә әйтелгән:

وَلَوْ جَعَلْنَاهُ مَلَكًا لَجَعَلْنَاهُ رَجُلًا

«Әгәр Без [илче буларак] фәрештәне җибәргән булсак та, Без аны кеше кыяфәтендә җибәрер идек» (6:9)[1]. Әлбәттә, җеннәрнең үзләренә генә алар арасыннан сайланган пәйгамбәр һәм илчеләр җибәрелгән булырга мөмкин.

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 69–70.

www.darul-kutub.com

Тик бу хәлнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам пәйгамбәрлегенә кадәр генә булуы ихтимал.

2. Барлык пәйгамбәрләр дә ир-атлар булган (әз-зукура). Хатын-кызлар йорт-хуҗалык эшләре, балалар тәрбияләү өчен кулай булганга, ир кешеләрнең пәйгамбәрлек вазыйфаларын башкаруга мөмкинлекләре күбрәк. Чөнки аларга вәгазь сөйләргә, дәүләт белән идарә итәргә, кайвакыт хәтта сугышларда гаскәр башлыгы да булырга туры килгән. Коръәндә бу хакта болай диелгән:

وَمَا أَرْسَلْنَا قَبْلَكَ إِلَّا رِجَالًا

«Без [Әй, Мөхәммәд] сиңа кадәр дә илче итеп ир-атларны гына җибәрдек…» (21:7).

3. Пәйгамбәрләр һәм илчеләрнең тышкы кыяфәтләре күркәм һәм чибәр булырга тиеш булган.

4. Кабиләдәшләрен һәм сахабаларын өйрәтергә тиеш булганга күрә, пәйгамбәр һәм илчеләр үрнәк әхлакка ия булганнар. Аерым алганда, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам турында Коръәндә әйтелгән:

وَإِنَّكَ لَعَلى خُلُقٍ عَظِيمٍ

«Син, чыннан да, искиткеч күркәм холыклы (әхлаклы) кеше» (68:4).

5. Тугрылык (сидк) Исламда күркәм холыкның иң мөһим өлеше санала. Шул рәвешле барлык пәйгамбәр һәм илчеләр дә тугрылыклы булган. Киресенчә булган очракта аларның пәйгамбәрлекләре ялганнары аркасында кабул ителмәс иде[1].

[1] Кайбер дин галимнәре «амана» («ышанычлылык») кебек сыйфатны да өстиләр. Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 119.

6. Барлык пәйгамбәрләр аек акыллы булганнар (сәламәт әл-гакл)[1] һәм берниндидә психик авырулар белән авырмаганнар.

7. Югарыда атап узылган сыйфатлар белән беррәттән пәйгамбәр һәм илчеләрнең тагын берничә сыйфаты аерып карала: хәерле нәсел җебе (хайр ән-нәсәб), коллыктан азат булу (әл-хөррийәт), тумыштан аерым осталыклары булу.

8. Бары тик пәйгамбәр һәм илчеләргә генә хас сыйфатларны аерым төркемгә кертеп карарга кирәк. Алар арасында түбәндәгеләр бар:

а) Пәйгамбәр һәм илчеләр гөнаһсыз булганнар. Әлеге сыйфат «гыйсмә» («саклanган, гарантияләнгән») термины белән белдерелә.

б) Барлык пәйгамбәр һәм илчеләргә дә Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңдерелгән.

в) Пәйгамбәр һәм илчеләр йоклаганда, аларның йөрәкләре уяу, Аллаһны зекер итә һәм Аңа табыналар. Бер хәдистә бу хакта әйтелгән: «Пәйгамбәрнең күзләре йоклый, ә йөрәге уяу. Башка пәйгамбәрләрнеке дә шулай ук: күзләре йоклаганда, йөрәкләре уяу була»[2].

г) Үләр алдыннан пәйгамбәр һәм илчеләргә бу дөньяда муллыкта яшәү яисә җәннәт рәхәтлекләрен сайлау мөмкинлеге бирелә. Хәдисләрнең берсендә әйтелгән: «Пәйгамбәрләрнең теләсә кайсы авырый башлауга аңа шушы дөнья яки мәңгелек дөньяны сайлау мөмкинлеге бирелә[3]»[4].

---

[1] Кайбер дин галимнәре әлеге сыйфатка тагын «фатана» («зирәклек») кебек сыйфатны да өстәп карыйлар. Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – С. 120.

[2] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 90.

[3] Ягъни шушы дөньяда яшәп калырга телиме ул, яисә, үлеп, бакый дөнья рәхәтлекләре белән ләззәтләнергә телиме.

[4] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 91.

www.darulkutub.com

д) Барлык пәйгамбәр һәм илчеләр үлгән җирләрендә үк күмелгән. Бер хәдистә әйтелгән: «Пәйгамбәрләрне нәкъ менә үлгән җирләрендә күмәләр»[1].

е) Пәйгамбәр һәм илчеләрнең мәетләре каберләрендә череп таркалмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Аллаһы Тәгалә җиргә пәйгамбәрләрнең тәннәрен ашауны тыйган»[2].

ж) Пәйгамбәр һәм илчеләр үлгәннән соң да Аллаһка табынуларын каберләрендә дәвам итәләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бу хакта әйтеп калдырган: «Пәйгамбәрләр исән, алар каберләрендә дә гыйбадәт кылалар»[3].

з) Пәйгамбәр һәм илчеләр төрле могҗизалар күрсәткәннәр һәм моны алар Аллаһның Кодрәте белән аңлатканнар.

## 4.4. Могҗизалар

Коръәндә һәм хәдисләрдә могҗиза, карамәт, мәгунә, истидраҗ кебек могҗизалар атап кителә.

Могҗиза[4] – пәйгамбәр башкара торган, күнегелгән хәлләр кысаларына сыешмаган гадәттән тыш гамәл. Ул пәйгамбәрнең бер генә замандашы да аны кабатлап күрсәтә алмый. Могҗиза әлеге пәйгамбәрнең хакыйкый булуын раслый.

[1] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 91.

[2] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 92.

[3] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – С. 93.

[4] «Әгҗәза» («сәләтсез, көчсез, куәтсез итү») фигыленнән ясалган. Әлеге гамәлне берәүнең дә кабатлап күрсәтә алмавы күздә тотыла.



www.darul-kutub.com

Нинди дә булса гамәлне могҗиза дип тану өчен, ул түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

1. Пәйгамбәр яки илче әлеге могҗизаның аның кулы белән түгел, ә Аллаһ тарафыннан башкарылуын белдерергә тиеш.

2. Күнегелгән, гадәти хәлләр яки билгеле кануннарга туры килмәгән ниндидер табигый булмаган вакыйга булырга тиеш.

3. Ул вакыйганы үзен пәйгамбәр дип атаган кеше башкарырга тиеш.

4. Могҗиза күрсәткән пәйгамбәр яки илченең кешеләргә таратасы, өйрәтәсе тәгълиматы булырга тиеш.

5. Таләп ителгән нәрсәләр булырга тиеш, киресенчә түгел.

6. Могҗизаның максаты – могҗиза күрсәтүченең шәхси амбицияләрен канәгатьләндерүе түгел, ә пәйгамбәрлекнең хакыйкыйлыгын раслау.

7. Пәйгамбәрнең замандашларыннан берсе дә әлеге могҗизаны кабатлап күрсәтә алмаска тиеш.

Коръәндә һәм хәдисләрдә пәйгамбәрләр тарафыннан күрсәтелгән күп төрле могҗизаларга мисаллар китерелгән. Түбәндә аларның кайсыберләре тасвирлана.

Пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәлам мәҗүсиләрнең потларын җимергәч, мәҗүсиләр Немруд исемле хөкемдарлары җитәкчелегендә аны учакта яндырырга булганнар. Әмма учак аны яндырмаган[1]. Коръәндә бу хакта болай язылган:

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَاهِيمَ

[1] Кара: Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа "Сад"», 2006. – Ч. 1, с. 219–224.

«Без әмер бирдек: “Әй, учак! Ибраһим өчен суык бул һәм коткар аны”» (21:69). Риваятьләрнең берсе буенча учак җәннәт бакчасына әверелгән.

Пәйгамбәр Салих галәйһиссәлам кавеменең мәҗүсиләре аңа кыядан кызыл[1] ана дөя белән баласын чыгаруын сорап мөрәҗәгать иткәннәр. Ул Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап дога кылган һәм шуннан соң кыядан ана дөя белән баласы килеп чыкканнар[2]. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

إِنَّا مُرْسِلُو النَّاقَةِ فِتْنَةً لَهُمْ فَارْتَقِبْهُمْ وَاصْطَبِرْ

«Чыннан да, Без сынау өчен ана дөя җибәрербез, ә син, [Салих], аларны сабыр гына күзәтеп тор» (54:27).

Фиргавеннең тылсымчылары белән пәйгамбәр Муса галәйһиссәлам арасындагы ярыш барышында Муса галәйһиссәламнең таягы, еланга әверелеп, тылсымчыларның таякларын һәм бауларын кабып йоткан[3]. Коръәндә бу вакыйга түбәндәгечә тасвирланган:

فَأَلْقَى مُوسَى عَصَاهُ فَإِذَا هِيَ تَلْقَفُ مَا يَأْفِكُونَ

«Шулвакыт Муса үзенең таягын ташлаган да ул таяк тегеләр сихерләгән нәрсәләрнең барысын да кабып йоткан» (26:45). Муса галәйһиссәлам үз халкы белән Фиргавеннән качып китеп барганда, диңгез алар алдында юл биреп чигенгән һәм Исраил угыллары шул рәвешле коткарылганнар[4]. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

---

[1] Дөяләрнең бу токымы сирәк очравы аркасында гарәпләрдә бик кыйммәт бәяләнә.

[2] Кара: Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 1, с. 188–190.

[3] Кара: Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 2, с. 176–180.

[4] Кара: Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 2, с. 198–201.



www.darul-kutub.com

فَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ اضْرِبْ بِعَصَاكَ الْبَحْرَ فَانفَلَقَ فَكَانَ كُلُّ فِرْقٍ كَالطَّوْدِ
الْعَظِيمِ(63)وَأَزْلَفْنَا ثَمَّ الْآخَرِينَ(64)وَأَنْجَيْنَا مُوسَى وَمَنْ مَعَهُ أَجْمَعِينَ(65)

«Шулвакыт Без Мусага вәхи иңдердек: “Таягың белән диңгезгә сук. [Ул сукты] һәм диңгез икегә аерылды, аның һәр өлеше тау кадәрле күтәрелде. Шуннан соң без Фиргавен гаскәрен [икегә аерылган диңгезгә] якынайттык, ә Мусаны һәм аның белән булган кешеләрне коткардык”» (26:63-65).

Пәйгамбәр Гайсә[1] галәйһиссәлам могҗизалары турында Коръәндә болай әйтелгән:

وَرَسُولًا إِلَى بَنِي إِسْرَائِيلَ أَنِّي قَدْ جِئْتُكُمْ بِآيَةٍ مِنْ رَبِّكُمْ أَنِّي أَخْلُقُ لَكُمْ
مِنَ الطِّينِ كَهَيْئَةِ الطَّيْرِ فَأَنفُخُ فِيهِ فَيَكُونُ طَيْرًا بِإِذْنِ اللَّهِ وَأُبْرِئُ الْأَكْمَهَ
وَالْأَبْرَصَ وَأُحْيِي الْمَوْتَى بِإِذْنِ اللَّهِ وَأُنَبِّئُكُمْ بِمَا تَأْكُلُونَ وَمَا تَدَّخِرُونَ فِي
بُيُوتِكُمْ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَةً لَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ

«...Исраил улларына илче итеп [җибәрде аны] [һәм ул әйтер аларга]: “Мин сезгә Раббыгыздан хәбәр алып килдем. Мин сезгә балчыктан кош әвәләп күрсәтәм дә, аңа өргәч, Аллаһның рөхсәте белән ул кошка әверелеп очып китәчәк. Мин сукырны һәм проказалы авыруларны сәламәтләндерермен, Аллаһның рөхсәте белән мәетләрне терелтермен. Мин сезнең нәрсә тукланып яшәгәнегезне һәм өйләрегездә нинди маллар барын әйтеп бирә алам. Чыннан да, боларның барысы да, әгәр сез иманлы булсагыз, сезнең өчен хикмәт”» (3:49).

[1] Кара: Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 3, с. 296–298.

www.darulkutub.com

Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең иң күренекле могҗизаларыннан түбәндәгеләр санала:

1. Айның ярылуы (иншикак әл-камәр).

2. Күкләргә күтәрелүе (әл-исрагъ вәл-мигъраҗ).

Болардан тыш төрле хәдисләрдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең күп санлы башка могҗизалары турында да сөйләнелә. Әмма могҗизаларының иң бөеге – Коръән.

Карамәт – изгеләр һәм тәкъвалар (әүлиялар) кылган гайре табигый гамәлләр. Тышкы яктан бу гамәл пәйгамбәр тарафыннан башкарыла торган могҗизадан берни белән дә аерылмый. Әмма асылы белән пәйгамбәрнең могҗизасыннан аермасы шунда: карамәтнең максаты әүлиянең тәкъвалыгын раслау түгел. Мәсәлән, пәйгамбәр Гайсә галәйһиссәламнең анасы Мәрьямне Аллаһы Тәгалә җәен кышкы җиләк-җимешләр белән, ә кышын – җәйгеләре белән туклandыра торган булган. Коръәндә бу хакта болай әйтелә:

فَتَقَبَّلَهَا رَبُّهَا بِقَبُولٍ حَسَنٍ وَأَنْبَتَهَا نَبَاتًا حَسَنًا وَكَفَّلَهَا زَكَرِيَّا كُلَّمَا دَخَلَ
عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِنْدَهَا رِزْقًا قَالَ يَامَرْيَمُ أَنَّى لَكِ هَذَا قَالَتْ
هُوَ مِنْ عِنْدِ اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَنْ يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ

«Раббыбыз аны кабул итте һәм күркәм итеп үстерде һәм Зәкәриягә тапшырды. Зәкәрия Мәрьямнең бүлмәсенә кергәндә аның янында һаман да ризыклар күреп аптыраган. [Берзаманны] ул сораган: “Әй, Мәрьям! Бу ризыклар сиңа кайдан килә?” – дип. Мәрьям: “Болар – Аллаһның нигъмәтләре”, – дип җавап биргән. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә Үзе теләгәннәрне чиксез ризыкландыра» (3:37).

www.darul-kutub.com

Әүлияләрнең иң бөек карамәте – «әл-истикамәт» (гомерләре буе Ислам кануннарына буйсынып яшәүләре).

Мәгунә – Аллаһның Тәгаләнең гап-гади мөселманга күрсәткән могҗизалы ярдәме яки коткаруы.

Истидраҗ – гөнаһлы кешеләр яки имансызлар тарафыннан кылынган гадәттән тыш гамәлләр. Моңа мисал итеп ялган пәйгамбәр Мүсайләм әл-Каззабәнең могҗизаларын китерергә була.

## 4.5. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам башка пәйгамбәр һәм илчеләрдән түбәндәгеләр белән аерылып тора:

1. Аннан алдагы пәйгамбәрләр бары тик үз халыкларына гына җибәрелгән була, ә Мөхәммәд – бөтен кешелек өчен. Үз хәдисләренең берсендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бу хакта болай ди: «[Миңа кадәрге] пәйгамбәрләр үз халкына гына җибәрелде, мине барлык халыкларга да җибәрделәр»[1].

2. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам пәйгамбәрләрнең соңгысы, ягъни аннан соң бүтән пәйгамбәрләр булмаячак. Коръәндә әйтелгән:

مَا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِنْ رِجَالِكُمْ وَلَكِنْ رَسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ وَكَانَ اللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمًا

[1] Маджд Макки. Аль-Байан фи аркан аль-иман. – Джидда: Дар нур альматабат, 1999. – С. 242.



www.darulkutub.com

«Мөхәммәд – сезнең ирләрегездән берәрсенең атасы түгел, ул Аллаһның Илчесе һәм пәйгамбәрләрнең тамгасы (мөһере)» (33:40)[1].

3. Аның дошманнары шактый була торып та аннан курыкканнар. Хәдисләрнең берсендә әйтелгән: «…миңа дошманнарымны бер айлык юл ераклыгында да куркуга салып тоту рәвешендә ярдәм күрсәтелде…»[2]

4. Аллаһ Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламгә рәхим-шәфкатен күрсәтеп, җирне, пакьләнү һәм гыйбадәт кылу өчен, чиста дип белдерде. Хәдисләрнең берсендә бу хакта әйтелгән: «…җир минем өчен гыйбадәт кылу һәм чистарыну (пакьләнү) урыны булды…»[3]

5. Аллаһы Тәгалә ганимәтләрдән файдалануны рөхсәт итте. Алдагы хәдистә: «…миңа ганимәтләр рөхсәт ителде…» – диелгән [4].

6. Аллаһы Тәгалә аңа Кыямәт көнне кешеләрне берничә тапкыр яклап чыгу (шәфәгать) мөмкинлеге бирде[5]. Бер хәдистә әйтелгән: «…миңа яклау мөмкинлеге бирелде»[6].

---

[1] Хәдисләрнең берсендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһивәссәлам шулай ук: «Мин һәм миннән алда килгән пәйгамбәрләрнең үрнәге искиткеч гүзәл бина төзеп тә аның бер почмагында кирпеч куймый калдырган кеше үрнәгенә тиң. Бу бина яныннан узган кешеләр моны күрәләр дә сорыйлар икән: “Ничек бер генә кирпечне куймый калдырганнар инде?” – дип. “Мин менә шушы [соңгы] кирпеч инде. Мин пәйгамбәрләрнең мөһере (тамгасы)”, – дип тә әйткән». Кара: Маджд Макки. Аль-Байан фи аркан аль-иман. – Джидда: Дар нур аль-матабат, 1999. – С. 243.

[2] Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис ашшариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 810.

[3] Шунда ук. – Хәдис № 812.

[4] Шунда ук. – Хәдис № 812.

[5] Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламнең яклавы турында «Кыямәт көне» бүлегеннән укыгыз.

[6] Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 810.



www.darulkutub.com

7. Ул барлык пәйгамбәрләр арасыннан иң ихтирам ителә торганы.

Сира буенча китапларда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам Фил елында (Григориан календаре белән 570 нче елга туры килә) Рабигул-Әүвәл аеның уникенче көнендә (дүшәмбе) туган диелә. Аның атасы ул туганчы ук үлгән, ә анасы Мөхәммәдкә алты яшь чагында вафат булган. Шуннан соң ул ике ел дәвамында бабайсында яшәгән. Бабайсының үлеменнән соң ул агасы Әбу Талиб карамагына күчә. Агасы белән ул сәүдә эшләре белән Шамга (Сүриягә) баргач, Бәхира исемле монах (дәрвиш) агасына Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең соңгы пәйгамбәр булачагын хәбәр иткән. Тиздән булачак Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вәсәллам үзе дә сәүдә белән шөгыльләнә башлый, кәрваннар белән Сүриягә йөри. Егерме биш яшендә ул Хадичә исемле хатынга өйләнә. Кырык яшендә аның янына Җәбраил фәрештә килеп, Коръәннең беренче юлларын җиткерә һәм пәйгамбәр итеп сайлануы хакында хәбәр итә. Шушы вакыйгадан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам унөч ел дәвамында Мәккәдә һәм якын тирәдәге авыл-шәһәрләрдә вәгазьләр сөйли. Шушы унөч ел буена ул һәм аның сахабалары куылып яшиләр һәм, нәтиҗәдә, Мәдинәгә күченеп китәргә мәҗбүр булалар. Мәдинәдә бу вакытка мөселманнарның шактый нык һәм зур җәмгыяте тупланып өлгерә. Мәккә мөселманнарының һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Мәдинәгә күченүләре бүгенге көн Ислам цивилизациясенең тарихы башланган иң әһәмиятле вакыйгага әверелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Мәдинәгә күченүеннән соң мөселман җәмәгатьчелеге тагы да ныгый. Сигез ел узгач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи

вәсәллам ун меңлек гаскәр белән Мәккәгә кире кайта. Шәһәрне кан коюсыз гына алалар, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам үзенең барлык дошманнарын да гафу итә. Мәккәдә яшәгән корайш кабиләсе халкы Исламны кабул итә. Шушы вакыйгадан соң Ислам дине бөтен Гарәп ярымутравына тарала. Һижри ел исәбе белән 10 нчы елда (632 нче ел) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам хушлашу хаҗына бара һәм анда ул хушлашу вәгазе дип аталган вәгазь сөйли. Әлеге вәгазьдә ул пәйгамбәрлек эшчәнлегенә йомгак ясап, Исламның төп кагыйдәләрен аңлата һәм безгә Коръән белән Сөннәтне катгый рәвештә үтәргә васыять әйтеп калдыра. Шушы ук елның Рабигул-Әүвәл аенда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам бу дөньядан китеп бара. Аннан соң ислам дәүләте (хәлифәт) белән кырык ел дәвамында тугрылыклы хәлифләр Әбу Бәкер, Гомәр, Госман, Гали[1] идарә итәләр. Йә, Аллаһы Тәгалә, безнең һәркайсыбызны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам өммәтеннән итсәң иде, безгә аның яклавын насыйп ит, аның белән җәннәттә янәшә булырга һәм Сине күрергә насыйп ит. Йә, Аллаһы Тәгалә, ул безнең һәркайсыбыз өчен рухи атабыз булсын иде. Аңа иминлек һәм Синең рәхмәтең ирешсә иде.

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавийййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

[1] Кайбер галимнәр алар исәбенә тагын Хәсән ибн Галине дә кертеп карыйлар, чөнки нәкъ менә аның берничә ай идарә итүе белән югарыда искә алынган шәхесләрнең житәкчелек вакыты 40 елга тула.

www.darulkutub.com

2. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

3. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

4. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русул ва ар-рисалат. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – 268 с.

5. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

6. Валиуллин К. Гакыйда. – Казань: Иман, 1999 – 87 с.

7. Ибн-Касир И. Тафсир аль-Кур’ан аль-‘азим. – Дамаск: Изд-во Дар аль-файха’, 1994. – Т.3, 769 с.

8. Крачковский И. Ю. Коран (перевод). – Минск, 1990.

9. Курсави Г. Тафсир байан. – Казань: Типография Домбровского, 1915. – 192 с.

10. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (аль-Хикма аль-балига), предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: ТКИ, 2008. – 479 с.

11. Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

12. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 1, 296 с.

13. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 2, 272 с.

14. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 3, 356 с.

www.darul-kutub.com

## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Пәйгамбәр һәм илчеләргә ышануга билгеләмә бирегез.

2. Пәйгамбәр һәм илчеләр кешелек өчен нигә кирәк? Дәлилләп күрсәтегез.

3. Барлык егерме биш пәйгамбәрнең исемнәрен атап чыгыгыз.

4. Биш бөек пәйгамбәрнең исемен атагыз. Җавабыгызны Коръәннән өзекләр китереп раслагыз.

5. Пәйгамбәрләрнең нинди төп вазыйфалары булган?

6. Пәйгамбәр һәм илчеләр нинди сыйфатларга ия булганнар? Җавабыгызны Коръәннән һәм Сөннәттән өзекләр китереп дәлилләгез.

7. Пәйгамбәр һәм илче арасындагы аерманы аңлатыгыз.

8. Пәйгамбәр могҗизасының шартларын санап чыгыгыз.

9. Могҗиза, карамәт, истидраҗ, мәгунә терминнарына билгеләмә бирегез.

10. Пәйгамбәрләр Мөхәммәд салләллаһу галәйһивәсәллам, Муса галәйһиссәлам, Ибраһим галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам, Салих галәйһиссәламнәр күрсәткән могҗизалардан берәр мисал китерегез.

11. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең башка пәйгамбәрләрдән җиде төрле аермасын әйтеп бирегез.

12. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам ничәнче елда туган?

13. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам Мәккәдә һәм Мәдинәдә ничәшәр ел вәгазьләр сөйләгән?

14. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Мәдинәгә күченеп китүе Ислам өчен нинди әһәмияткә ия?

15. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең мөселманнарга Коръән белән Сөннәтне катгый рәвештә үтәргә кушкан васыятенең мәгънәсен аңлатып бирегез. Ул мөселманнар тарихына, фәненә һәм мөселманнарның тормышына ничек тәэсир итте?

* * *

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 5 БҮЛЕК

# КЫЯМӘТ КӨНЕНӘ ЫШАНУ

Коръәндә һәм Сөннәттә кешенең ике гомере бар: беренчесенә – вакытлы, билгеле бер срок белән чикләнгән фани дөнья тормышы, икенчесенә – мәңгелек, бакый дөнья тормышы, үлгәннән соң яки Кыямәт көненнән соңгы яшәеш, диелә. Беренчесе Аллаһы Тәгалә биргән сынаулардан гыйбарәт, имтихан була, икенчесе – кешенең беренче тормышындагы шушы сынауларны ничек узуына карап хисап тоту. Ягъни сынаулар уңышлы узылган булса – кешене рәхәтлекләр, ә гөнаһлар кылынган икән – җәзалау көтә. Исламда «кыямәт әс-сугра» («кече Кыямәт көне») һәм «кыямәт әл-кубра» («бөек Кыямәт көне») дигән төшенчәләр бар. Кече Кыямәт көне дип кешенең үлүе һәм кабердә булуына, ә бөек Кыямәт көне дип түбәндәге вакыйгаларның кушылмасына әйтәләр: башта Кыямәт көненең кечкенә һәм зур билгеләре күренә башлый, соңрак үлгәннәр каберләреннән кубарылып чыга, кылган гамәлләре өчен исәп-хисап тоталар, гамәл үлчәвендә эш-гамәлләре үлчәнелә, әс-Сират күпереннән узалар һәм, ниһаять, Җәннәттә рәхәтлекләргә ирешәләр яки Җәһәннәмдә җәзалануга дучар булалар.

www.darulkutub.com

Һәркайсыбыз Кыямәт көненең җитүенә ышанырга тиеш. Дөньядагы барлык тере нәрсәләр үлеп бетәчәк һәм яңадан тереләчәк, Аллаһ һәрбереннән гомере буена кылган гамәлләре хакында сорау алачак, ахырдан иманлы бәндәләрне һәм тәкъваларны Җәннәт рәхәтлекләре белән бүләкләячәк, ә имансызларны һәм гөнаһлыларны Җәһәннәмдә җәзалаячак. Коръәндә һәм Сөннәттә Кыямәт көне турында хәбәр ителгән барлык мәгълүматка да ышанырга кирәк. Коръәндә Кыямәт көненә ышану турында түбәндәгеләр әйтелгән:

إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَالَّذِينَ هَادُوا وَالنَّصَارَى وَالصَّابِئِينَ مَنْ آمَنَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَعَمِلَ صَالِحًا فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِنْدَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ

«Чыннан да, соңгы көнне дә игелекләр кылган диндар кешеләр һәм яһүдилеккә күчкәннәр, христианнар һәм Аллаһка ышанган сабигыйларга әҗерләрен Аллаһы Тәгалә насыйп итәчәк, шуңа күрә дә алар бернидән дә курыкмыйлар һәм хафаланмыйлар да» (2:62). Шулай ук Коръәндә болай дип тә әйтелгән:

وَمَنْ يَكْفُرْ بِاللهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا بَعِيدًا

«Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның илчеләренә һәм Кыямәт көненә ышанмаучылар бик нык ялгышалар» (4:136). Шуңа күрә Кыямәт көненә ышанмаган кеше мөселман була алмый.

Кыямәт көне җитүенең мөмкинлеген дәлилләү максатыннан Коръәндә бер риваять китерелгән. Бер мәҗүси иске сөякне тузан рәвешенә килгәнче уа да тузанын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең йөзенә өреп очыра һәм сорый: «Тузанга әверелгән шушы сөякне кем терелтсен, ди?» Аллаһ Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламгә әлеге сорауга түбәндәгечә җавап бирергә кушкан:

قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ

«Әйт: "Аларны тәүге тапкыр барлыкка китерүче терелтәчәк һәм Ул барлыкка китерелгән һәр нәрсә хакында белә"» (36:79). Күргәнебезчә, бу дәлил Аллаһның барлыгына ышанган кешеләр өчен бирелгән. Аның мәгънәсе Аллаһы Тәгаләнең Көч-Кодрәтен раслау, ягъни Ул бу дөньяны бер тапкыр барлыкка китергән икән, икенче тапкыр да барлыкка китерергә һәм терелтергә мөмкин.

Кыямәт көне җитүнең мөмкинлеген нигезле дәлилләүгә килгәндә, дин галимнәре, гадәттә, «абсолют (чикләнмәгән) гаделлек дәлиле» дип аталган дәлилне китерәләр. Аның асылы кешеләрнең төрле тормыш белән яшәүләренә бәйле. Берәүләр гадел яшәсәләр, җәмгатьчелеккә файда китерсәләр, үз милекләрен мохтаҗларга ярдәм рәвешендә сарыф итсәләр, яманлык белән көрәшсәләр, икенчеләр шул ук вакытта боларга капма-каршы рәвештәге тормышта яшиләр. Кайбер кешеләрнең гаебе белән йөз меңләгән һәм хәтта миллионлаган кешеләр үлә. Нәтиҗәдә, беренчеләре – рәхәт күрмичә, ә икенчеләре җәзаланмыйча үлеп китәләр. Сәламәт кеше психикасы гаделлекне таләп итә. Ягъни явызларның җәзалануын, ә юньле, инсафлы кешеләрнең игелекләргә ирешүләрен сорый. Димәк, Аллаһы Тәгаләнең диндә Кыямәт көне дип

аталган абсолют (чикләнмәгән) гаделлек мизгеле җитәргә тиеш[1]. Шушы дәлилне дин галимнәре ике төркемгә бүлеп карыйлар: беренчесенең асылы – Барлыкка Китерүченең гаделлеге Кыямәт көнендә күренәчәк, икенчесенеке – кешенең гаделлеккә сусавы аның барлыгына ишарәли (суга сусау суның барлыгына ишарәләгән кебек).

Исламда Кыямәт көне «гыйлем әл-гайб»[2] категориясенә кертеп каралганга күрә, аның башлануына ышану аеруча зур бәяләнә. Коръән һәм Сөннәттә Аллаһка ышану белән беррәттән искә алына.

Ислам тәгълиматы Кыямәт көненең һичшиксез җитәчәге турында өйрәтә. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

إِنَّ السَّاعَةَ لَآتِيَةٌ لَا رَيْبَ فِيهَا وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يُؤْمِنُونَ

«Чыннан да, [Кыямәт] сәгате котылгысыз рәвештә җитәчәк, шик юк. Әмма, [шуңа да карамастан], кешеләрнең күбесе моңа ышанмый» (40:59). Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләреннән билгеле булганча, Кыямәт көне бик тиздән җитәчәк. Бервакыт сахабаларына вәгазь сөйләгәндә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Аның якынлыгы шушы ике бармак кебек кенә», – һәм имән бармак белән урта бармакны бергә кушып күрсәтә. Әмма шул ук вакытта хәтта Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә дә Кыямәт көненең кайчан башлануы тәгаен мәгълүм түгел. Коръәндә бу хакта болай әйтелгән:

[1] Кара: Маджд Макки. Аль-Байан фи аркан аль-иман. – Джидда: Дар нур аль-матабат, 1999. – С 302.

[2] Яшерен, серле, күзгә күренми торган нәрсәләр турында гыйлем.



www.darul-kutub.com

قُلْ هُوَ الَّذِي ذَرَأَكُمْ فِي الْأَرْضِ وَإِلَيْهِ تُحْشَرُونَ(24)وَيَقُولُونَ مَتَى هَذَا الْوَعْدُ إِنْ كُنتُمْ صَادِقِينَ(25)قُلْ إِنَّمَا الْعِلْمُ عِنْدَ اللَّهِ وَإِنَّمَا أَنَا نَذِيرٌ مُبِينٌ(26)

«Әйт: "Ул сезне шушы җирдә таратып яшәтүче һәм сез Аның каршына җыелачаксыз". Алар сорарлар: "Сез дөресен сөйлисез икән, вәгъдәгез кайчан [тормышка ашырылачак соң]"? Җавап бир: "Бу хакта бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә, мин Аның хөкемнәрен ачык итеп тапшыручы гына"» (67:24-26).

Кыямәт көненә ышануның асылы кешегә бу дөньяда вакытлыча яшәвен аңлату һәм аның бу гомерен ничек үткәрүенә игътибарын юнәлтүдән гыйбарәт. Кыямәт көненә ышану кешенең матди байлыкларга омтылышын киметергә, аны рухи кыйммәтләр эзләүгә, тыелганнардан тыелырга һәм Илаһи кануннарны намус белән үтәүгә этәрергә тиеш. Җәмәгатьчелекне исә Кыямәт көненә ышану рухи кыйммәтләргә, иҗтимагый гаделлеккә, яманлык белән көрәшкә, бер-береңә ярдәмләшүгә, социаль һәм сәяси тотрыклылыкка юнәлдерергә, җинаятьчелек белән бозыклыклардан арындырырга тиеш.

## 5.1. Үлем

Ислам буенча үлем гомернең ахыры түгел, ә башлангычы гына. Үлем – кеше гомеренең дөньяви тормышы төгәлләнеп, башка дөнья, бүтән төрле формадагы яшәеш башлана торган вакыйга. Бу хакта дин галимнәре әйткәннәр: «Үлгәннәр өчен Кыямәт көне җиткән инде», – дип. Коръәндә кеше үлеменең котылгысызлыгын раслап болай диелгән:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ

«Һәр җанны үлем көтә» (3:185), – шулай ук:

كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ(26)وَيَبْقَى وَجْهُ رَبِّكَ ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ(27)

«Җирдә яшәүче һәркем үләчәк. Бары тик шөһрәтле һәм мактаулы Аллаһы Тәгалә генә мәңгелек» (55:26-27). Күргәнебезчә, бары тик Аллаһ гына үлемсез. Шуңа бәйле рәвештә Ислам кешенең игътибарын үлемгә түгел, ә аның шушы мизгелдә нинди йөге булуына юнәлтә. Фани дөньяның күп кенә өлешләре вакытлы, шуның нәтиҗәсе буларак, алар хыялый булып тоела. Үлеменнән соң кешене чын тормыш көтә: кабердәге тормыш һәм Кыямәт көне тормышы. Өстәвенә, үлем фани дөнья хыялларыннан уяну була. Бу хакта дин галимнәре әйткәннәр: «Кешеләр йоклыйлар һәм үлгәч кенә уяналар». Иманлы кешеләргә исән чакта ук ничек уяныргa соң? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләренең берсендә мондый киңәш биргән: «Ләззәтләрне һәлак итүчене [ягъни үлемне] ешрак исегезгә төшерегез».

Кешенең асылы ике өлештән – тән һәм җаннан гыйбарәт. Тән – аерым химик элементлардан тупланган, материаль дөньяның юкка чыга торган өлеше. Җан – рухи дөньяның үлемсез өлеше һәм аның ничек тасвирлануы мәгълүм түгел. Коръәндә җан турында түбәндәгеләр әйтелгән:

وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الرُّوحِ قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي وَمَا أُوتِيتُمْ مِنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا

«Алар синнән рух турында сорарлар. Җавап бир: “Рух Раббыбыз боерыгы белән [иңә]. Ләкин сезгә [бу хакта] бик аз белергә тиешле”» (17:85). Әлеге ике субстанция кешенең гомере буена бергә, симбиозда яши. Үлем мизгелендә җан тәннән аерылып китә. Шуннан соң тәннең яшәеше туктала, ә җан яшәвен дәвам итә.

Аллаһы Тәгалә һәр кеше өчен гомер озынлыгын һәм үлем вакытын билгеләгән[1] һәм беркем дә билгеләнгәннән артык та, кимрәк тә яши алмый[2]. Ләкин бу срок бары тик Аңа гына мәгълүм[3]. Коръәндә бу хакта болай әйтелгән:

إِنَّ اللَّهَ عِنْدَهُ عِلْمُ السَّاعَةِ وَيُنَزِّلُ الْغَيْثَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْأَرْحَامِ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ مَاذَا تَكْسِبُ غَدًا وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ

«Чыннан да, Кыямәт сәгатенең кайчан җитәчәген бары Аллаһ гына белә. Ул яңгырлар яудыра, ана карынындагы [яралгының] нинди булуын белә. Бер генә кеше дә иртәгә нинди хәлләргә юлыгачагын белми; бер генә кеше дә кайсы җирдә үләчәгеннән хәбәрдар түгел. Чыннан да, Аллаһ – барысын да Белүче, барысыннан да Хәбәрдар» (31:34).

## 5.2. Кабер

Кабер («Әл-Кабр») сүзе ике төрле мәгънәгә ия. Беренчесе – җир астындагы физик яктан тоемлана торган, үлгән кешенең җәсәде

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 19.

[2] Бу хакта шулай ук «Тәкъдир» бүлегеннән дә карагыз.

[3] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 20.



www.darul-kutub.com

яткан урын. Икенчесе – үлгән кешенең җаны рәхәтлекләргә ирешә яисә җәзалауга дучар ителә торган теге дөньядагы урын.

Кешенең үлем мизгеле җиткәч, Аллаһы Тәгалә аның янына фәрештәләрен җибәрә. Коръәндә бу хакта болай диелгән:

وَهُوَ الْقَاهِرُ فَوْقَ عِبَادِهِ وَيُرْسِلُ عَلَيْكُمْ حَفَظَةً حَتَّى إِذَا جَاءَ أَحَدَكُمُ
الْمَوْتُ تَوَفَّتْهُ رُسُلُنَا وَهُمْ لَا يُفَرِّطُونَ

«Ул Үзенең колларына хуҗа һәм берәрегезнең үлем сәгате җиткәнчегә яннарыгызга саклаучы [фәрештәләрне] җибәрә. [Үлем сәгате җиткәч], ул кешене безнең илчеләребез мәңгелек йокыга талдырырлар. Алар бернәрсәне дә күз уңыннан яздырмыйлар» (6:61). Иманлы һәм тәкъва кешеләр янына әлеге фәрештәләр искиткеч гүзәл кыяфәттә киләләр, ә имансызлар һәм гөнаһлыларга алар коточкыч һәм бик куркыныч сурәттә күренәләр икән. Беренчеләре турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хәдисендә болай диелгән: «…алар ак йөзле, кояш кебек нурлы һәм үзләре белән җәннәт кәфене алып киләләр…»[1] Икенчеләре турында шушы ук хәдистә әйтелгән: «…алар көчле, кара йөзле, үзләре белән җәһәннәмнән тупас тукыма алып киләләр…»[2]

Болардан соң үлем фәрештәсе килеп, мәетнең баш очына утыра да аңа әйтә: «Әй, гүзәл җан, Аллаһның рәхмәтенә һәм ризалыгына [ирешү өчен] чык»[3]. Имансызлар һәм гөнаһлы кешеләргә исә үлем фәрештәсе башкача әйтә: «Әй,

---

[1] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 21.

[2] Шунда ук. – Б. 22.

[3] Шунда ук. – Б. 21.



www.darulkutub.com

кабахәт җан, Аллаһның ачуына [дучар булу өчен] чык»[1]. Беренчеләрнең тәненнән җан бик җиңел генә аерыла, ә менә икенчеләренекеннән бик авырлык белән, газап-җәфа чигеп кенә чыга.

Коръәндә тәннән аерылып киткән җан, гомере буе кылган хаталарын төзәтү өчен, кире үз тәненә кайту теләген белдерә, диелгән. Аятьләрнең берсендә түбәндәгечә әйтелгән:

حَتَّى إِذَا جَاءَ أَحَدَهُمُ الْمَوْتُ قَالَ رَبِّ ارْجِعُونِ (99) لَعَلِّي أَعْمَلُ صَالِحًا فِيمَا
تَرَكْتُ كَلَّا إِنَّهَا كَلِمَةٌ هُوَ قَائِلُهَا وَمِنْ وَرَائِهِمْ بَرْزَخٌ إِلَى يَوْمِ يُبْعَثُونَ (100)

«Алардан берсенә үлем килгәч, ул дога кыла башлар, ди: Йа, Раббым! [Шушы дөньяга] кире кайтар мине. Бәлки мин элегрәк игътибар бирмәгән нәрсәләргә кагылышлы игелекле гамәл кылырмын. Юк шул! Аның сөйләгәне бары тик [буш] сүзләр генә. Шушы дөньядан китүчеләрнең артында алар кубарылып чыкканчыга кадәр киртә [булачак]» (23:99-100).

Үләр алдыннан кеше янына иблис килә. Кайбер дин галимнәре, иблис, үләсе кешене station аздырып диненнән яздыру максатыннан, аның ата-анасы кыяфәтендә килә, дип уйлыйлар. Шулай ук, кайбер риваятьләр буенча, үлем хәлендәге кеше бик нык сусый икән һәм, шул вакыт аның янына иблис килеп, динен суга алыштырырга кушып су тәкъдим итә.

Тәннән аерылган җан күкләргә очып китә. Хәдисләрнең берсендә әйтелгәнчә, иманлы кешенең җаны күкнең җиденче катына ук менеп җитә, ә имансызларның җаннары күкнең беренче катыннан да ары уздырылмый. Моннан соң җаннар үзләренең тәннәре янына кире җиргә әйләнеп кайта. Бу вакытта тәннәр каберләргә җирләнгән була инде.

[1] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 22.

Хәдисләрдә әйтелгәнчә, бу хәлләрдән соң җан янына Мөнкир белән Нәнкир[1] исемле ике фәрештә килә. Алар мәеткә торып утырырга кушалар һәм: «Синең Раббың кем? Динең нинди дин? Пәйгамбәрең кем? (яки: Син бу кеше [Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам күздә тотыла] турында нәрсәләр сөйләдең?)», дигән өч сорау бирәләр. Иманлы кеше шушы сорауларга дөрес җавап бирә, ә имансызлар бөтенләй җавап бирә алмый.

Моннан соң, мәрхүмнәр, нинди җавап бирүләренә һәм гомерләре буе нинди гамәлләр кылганнарына карап, савапларга ирешә башлыйлар яисә җәзалауларга дучар булалар. Бер хәдистә бу хакта әйтелгән: «Кабер – Җәннәт бакчаларының берсе яки Җәһәннәмнең бер чокыры». Болардан тыш, кабердәге мәет Җәннәттән яки Җәһәннәмнән үзенә әзерләнеп куелган урынны күреп ятачак.

Кабердәге мәет исәннәр дөньясындагы вакыйгалар, хәлләр турында белеп ята. Бу хакта бер хәдис тә бар: үлгән кеше үзен кабергә күмеп китүче кешеләрнең аяк тавышларын ишетә икән. Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Бәдр сугышыннан соң һәлак булган мәҗүсиләр белән сөйләшүе һәм Гомәр ибн әл-Хаттабның соравына: «Алар мине синнән дә яхшырак ишетәләр, ләкин җавап кына бирә алмыйлар», – дип әйтүе турында хәбәр ителә.

Хәнәфиләр мәзһәбе өйрәтмәләре буенча, исәннәрнең мәетләргә карата игелекле гамәлләре үлгәннәрнең тәкъдирләрен җиңеләйтергә һәм хәлләрен яхшыртырга мөмкин[2].

---

[1] Алар турында шулай ук «Фәрештәләр» бүлегеннән укыгыз.

[2] Кара: Малик Ибрахим. Смерть: конец или начало? – Казань: Идел-Пресс, 2007. – С. 195–197.

Барлык үлгән кешеләр дә Кыямәт көнендә кубарылып чыкканнарына кадәр шушы халәттә булачаклар.

## 5.3. Кыямәт көне билгеләре («әшрат әс-сәгать» яки «аять әс-сәгать»)

Югарыда язылганча, Кыямәт көненең кайчан җитүен берәү дә белми. Әмма Коръәндә һәм хәдисләрдә Кыямәт көне җитүнең билгеләре турында хәбәр ителә. Билгеләр дип шушы вакыйганың якынаюына ишарәләүче аерым күренешләр, хәл-вакыйгалар күздә тотыла. Алар барысы да Кыямәт көне җиткәнче булып узарга тиеш. Кыямәт көненең билгеләре ике зур төркемгә: кечкенә билгеләр һәм зур билгеләргә бүленә.

### 5.3.1. Кыямәт көненең кечкенә билгеләре

Кыямәт көненең кечкенә билгеләре бик күп санлы. Аларның берсе – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең пәйгамбәрлеге һәм үлеме. Хәдисләрнең берсендә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам, Кыямәт көненең үз пәйгамбәрлегенә якынлыгын хәбәр итү өчен, баш һәм имән бармакларын кушып күрсәткән», диелә[1]. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам сахабаларының берсенә: «Кыямәт көне җитәр алдыннан алты [билге] булырга тиеш: минем үлемем…»[2] – дип әйткән диелә.

Инде булган тагын бер билге – айның ярылуы[3]. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 145.

[2] Шунда ук. – Б. 146.

[3] Шунда ук. – Б. 147.



www.darul-kutub.com

اقْتَرَبَتِ السَّاعَةُ وَانْشَقَّ الْقَمَرُ(1)وَإِنْ يَرَوْا آيَةً يُعْرِضُوا وَيَقُولُوا سِحْرٌ مُسْتَمِرٌّ(2)

«Кыямәт сәгате якыная, ай да ярылды. Ләкин алар (ягъни күпаллалыкка ышанучылар), нинди дә булса билгене күрсәләр дә, йөз чөереп, «Чын күз буу (сихер)» дип кенә әйтәләр» (54:1-2). Бу хакта «Пәйгамбәрләр һәм илчеләр» бүлегендәге «Могҗизалар» бүлекчәсендә тәфсилләбрәк язылган.

Тормышка ашырылган киләсе билге турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам болай хәбәр иткән: «Хиҗаздан Бусрадагы[1] дөяләрнең муеннарын яктыртачак ут чыкканчыга кадәр Кыямәт сәгате җитмәс»[2]. Танылган мөселман дин галиме һәм тарихчы Ибн Касир 654 нче елгы (1256 нчы ел) бу вакыйганы тасвирлап язган. Шаһитләр сөйләвенчә, шәкертләр әлеге утның яктылыгында дәрес әзерли алганнар икән[3].

Инде булган тагын бер билге турында хәдистә әйтелгән: «Гыйракта дирхәм[4] белән кафизлар, Шамда (Сүриядә) мудд белән динарлар, Мисырда ирдиб белән динарлар бетереләчәк. Сез башлангычыгызга кайтачаксыз. Сез башлангычыгызга кайтачаксыз»[5]. Бүгенге көн дин галимнәре фикеренчә, әлеге хәдистә сүз мөселман илләренең яулап алынулары һәм колонияләштерелүләре турында бара.

1 Ән-Нәвави фикеренчә, бу Сүриядәге Хауран шәһәре.

2 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 160.

3 Шунда ук.

4 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 160.

5 Библиядә Гог һәм Магог дип бирелә.

www.darulkutub.com

## 5.3.2. Кыямәт көненең зур билгеләре

Кыямәт көненең зур билгеләреннән әле берсе дә чынга ашмады. Әлеге билгеләрнең барысы да Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең хәдисендә искә алына: «…Ун билгесен: төтен чыгу, Дәҗҗал килү, дәббат дигән [хайванның] барлыкка килүе, кояшның көнбатыштан чыгуы, Мәрьям улы Гайсә галәйһиссәламнең күкләрдән иңүе, Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ[1] [кавемнәренең] килеп чыгуы, җирнең өч тапкыр убылуы (яки ай тотылу)[2]: берсе – көнчыгышта, икенчесе – көнбатышта, өченчесе – Гарәп ярымутравында убылачак һәм соңгысы – Йәмәннән кешеләрнең барысын бер урынга куып китерәчәк ут чыгуны сез күрмичә ул [Сәгать] башланмаячак»[3].

### Төтен чыгу

Коръәндә әлеге билге турында түбәндәгечә язылган:

فَارْتَقِبْ يَوْمَ تَأْتِي السَّمَاءُ بِدُخَانٍ مُبِينٍ(10)يَغْشَى النَّاسَ هَذَا عَذَابٌ أَلِيمٌ(11)

«Күктән, ап-ачык күренә торган төтен төшеп, кешеләрне чолгап алачак көнне көтегез. Бу газаплы җәза булачак» (44:10-11).

[1] Гарәп телендә «хасф» сүзе ике мәгънәгә ия: 1) Җир убылу; 2) Ай тотылу.

[2] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 225.

[3] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 225.

## Дәҗҗалның барлыкка килүе

Дәҗҗалның барлыкка килүе кешелек өчен бөек сынау булачак, коткы һәм фетнә чыгарачак. Дәҗҗал гадәттән тыш көчкә ия кеше булачак һәм үзен алла дип белдерәчәк. Хәдисләрнең берсендә бу хакта болай әйтелгән: «…Адәм барлыкка китерелгәннән бирле җир йөзендә Дәҗҗал кебек башка коткы булмаган…»[1]

Хәдисләрдә әлеге кешенең сыйфатлары бик тәфсилләп сурәтләнә. Мәсәлән, берсендә әйтелгән: «Тыгыз бәдәнле, тәне кызгылтрак тиреле, бөдрә чәчле, бер күзе сукыр, кипкән йөземгә охшаган…»[2] Тагын бер хәдистә ул кыска буйлы булarak тасвирлана. Ләкин аның өч сыйфаты: бер күзенең сукырлыгы (гадәттә, уң күз, диелә), күзләре арасында «кәфер» («имансыз») дип язылуы һәм үрчемсез булуы аеруча игътибарга лаеклы. Алар Дәҗҗалның илаһилыгын кире кагалар. Чөнки Аллаһы Тәгалә камил, ә Дәҗҗалның физик кимчелекләре бар.

Дәҗҗал күрсәткән һәм, кешеләрне коткыга салып, бозыклыкка илтүче могҗизалар арасында түбәндәгеләре атала:

- Бик тиз хәрәкәтләнүе: «җил кудырган яңгыр кебек…»[3]
- Җәннәт белән Җәһәннәмне гәүдәләндергән елгаларның булуы. Хәдисләрдә сулы һәм утлы ике елга турында сөйләнелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам сахабаларына хәтта утлы елгадан эчәргә тәкъдим иткән.

---

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 234.

[2] Шунда ук. – Б.241.

[3] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 247.



www.darul-kutub.com

• Шайтаннарның ярдәменнән файдалануы. Хәдисләрнең берсендә моңа мисал китерелә: «Коткыларның берсе шул булыр: ул бәдәвидән сорар ди: «Мин синең атаң белән анаңны терелтсәм, син мине аллаң, дип танырсыңмы?» Бәдәви: «Әйе», – дип җавап бирәчәк. Шулчак шайтан аның ата-анасы кыяфәтенә кереп: «Улым, ул синең аллаң, аңа табынырга кирәк», – диячәк[1]».

• Хайваннарның һәм тере булмаган әйберләр белән күренешләрнең аңа буйсынулары. Боларга мисал рәвешендә мөселманнарның дини китапларында түбәндәгеләр язылган: «Ул күкләргә кушар – алар яңгыр яудырыр, җиргә [кушар] – уңыш үсеп чыгар, хайваннарны чакырыр – алар аның артыннан кузгалып китәр, хәрабәләргә асларында күмелеп калган хәзинәләрне китереп чыгарырга кушар – алар да аның боерыгына буйсыначаклар»[2].

• Үлгәннәрне терелтүе. Хәдисләрнең берсендә әд-Дәҗҗалның бер мөселманны башта урталай ярып, аннан соң аны терелтүе хакында җентекләп сөйләнелә. Ләкин ул мөселман моңа җавап итеп: «Мин [синең ялганыңа] тагын да ныграк ышандым хәзер», – диячәк[3].

Әд-Дәҗҗалның могҗизалары истидраж[4] төркеменә кертеп каралганга күрә, әлеге зур могҗизаларның күплеге кешеләр өчен зур сынау булачак һәм араларында фетнәләр тудырачак. Шуңа бәйле рәвештә аңа иярүчеләрнең саны артачак, хәтта кайбер мөселманнар да тугры юлдан язарга мөмкин.

---

1 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 249.

2 Шунда ук. – Б. 249.

3 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 250–251.

4 «Пәйгамбәрләр» бүлегендәге «Могҗизалар» өлешен кара.



www.darul-kutub.com

Әд-Дәҗҗал җирдә кырык көн генә булачак. Ләкин ул көннәрнең берсе – бер елга, икенчесе – бер айга, өченчесе – бер атнага, башка көннәре гадәти көннәргә тиң булачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам мөселманнарга гыйбадәт вакытларын елны айларга, айларны – көннәргә, көннәрне сәгатьләргә бүлеп билгеләргә тәкъдим иткән.

## Дәҗҗалдан саклану чаралары

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам кайбер хәдисләрендә Дәҗҗалдан саклану чараларын күрсәткән:

1. Йөгереп качу. Хәдисләрдә, Әд-Дәҗҗалның могҗизаларын күреп, аның коткысына бирелмәс өчен, йөгереп качарга тәкъдим ителгән[1].

2. Ул барында «Әл-Кахф» («Мәгарә») сүрәсенең беренче ун аятен яки, башка хәдисләрдә бирелгәнчә, ахыргы ун аятьне укырга киңәш ителә[2].

3. Гыйбадәтне үтәгәннән соң дога кылу. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам түбәндәгечә дога кылырга кушкан: «Йә, Аллаһым, кабердә һәм җәһәннәмдә җәзаланудан, шушы һәм киләсе дөнья сынауларыннан, әл-Мәсих Әд-Дәҗҗалның котыртуларыннан куркып Сиңа сыенам»[3].

1 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 256.

2 Шунда ук. – Б. 257.

3 Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 258.



www.darul-kutub.com

Хәдисләрдә мөселманнарның Әд-Дәҗҗал һәм аның иярченнәре белән сугышулары турында әйтелгән. Әмма диндәшләребез аны Гайсә күктән иңгәннән соң гына җиңә алачак.

## Гайсәнең күкләрдән иңүе

Без, мөселманнар, Гайсә галәйһиссәламне тәрегә кадаклап куелып җәзаланмады, дип саныйбыз. Коръәндә аның турында түбәндәгеләр хәбәр ителә:

وَقَوْلِهِمْ إِنَّا قَتَلْنَا الْمَسِيحَ عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ رَسُولَ اللَّهِ وَمَا قَتَلُوهُ وَمَا صَلَبُوهُ وَلَكِنْ شُبِّهَ لَهُمْ وَإِنَّ الَّذِينَ اخْتَلَفُوا فِيهِ لَفِي شَكٍّ مِنْهُ مَا لَهُمْ بِهِ مِنْ عِلْمٍ إِلَّا اتِّبَاعَ الظَّنِّ وَمَا قَتَلُوهُ يَقِينًا(157)بَلْ رَفَعَهُ اللَّهُ إِلَيْهِ وَكَانَ اللَّهُ عَزِيزًا حَكِيمًا(158)وَإِنْ مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ إِلَّا لَيُؤْمِنَنَّ بِهِ قَبْلَ مَوْتِهِ وَيَوْمَ الْقِيَامَةِ يَكُونُ عَلَيْهِمْ شَهِيدًا(159)

«…алар: “Без Мессияне, Мәрьям улы Гайсәне, Аллаһның илчесен үтердек бит, дип әйтерләр. Алар аны үтермәделәр һәм тәрегә кадаклап куеп җәзаламадылар да, аларның күзләренә шулай күренгән; чыннан да, бу хакта сөйләнеп йөрүчеләр аның турында берни дә белмидәр, шикләнәләр, вәсвәсәгә биреләләр”. Бу аятьне дәвам итеп Аллаһы Тәгалә әйткән: “Алар аны үтермәделәр дә, тәрегә дә кадаклап куймадылар, алар моны күз алдына китергән генә. Аллаһ аны Үзе янына алдырган, чөнки Аллаһы Тәгалә Бөек һәм Хикмәт иясе!”» (4:157-159) Безнең дин галимнәребез исәпләвенчә, Аллаһ Гайсәнең бер шәкертен аның кыяфәтенә керткән һәм ул кешене Гайсә галәйһиссәлам урынына җәзалаганнар.

www.darulkutub.com

Гайсә күкләргә күтәрелгән һәм бүгенге көнгә кадәр ул исән, үзенең яңадан җиргә төшерелүен көтә икән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләрендә язылганча, Дәҗҗалның җирдә үткәрелергә тиешле вакыты төгәлләнгәннән соң, Аллаһ, аны һәлак итү өчен, җиргә Гайсәне төшерәчәк. Гайсә галәйһиссәлам, җиргә иңгәннән соң, Бәйт әл-Мәкдискә[1] юнәлеп, Әд-Дәҗҗалны эзәрлекли башлаячак. Куып җиткәч, аны Бәб Лүдд[2] тирәсендә үтерәчәк. Мөселманнар, Гайсә галәйһиссәламгә ияреп, әд-Дәҗҗалның гаскәрен җиңеп юк итәчәкләр.

Җиңүдән соң Гайсә галәйһиссәлам Коръән кушканча гадел идарә итәчәк һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәлламнең онытылып баручы Сөннәтен төзәтәчәк. Гайсә галәйһиссәлам идарә иткән чорда кешеләр байлыкта һәм муллыкта яшәрләр. Әмма алар шул байлыкка табыначаклар. Җир йөзендә сугышлар туктатылып, тынычлык хөкем сөрәчәк. Кешеләрнең күңелләреннән нәфрәт, көнчелек, хөсетлек һәм башка тискәре сыйфатлар юкка чыгачак. Әхлак һәм рухи байлыклар беренче урынга чыгачак.

## Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ кабиләләренең килеп чыгуы

Бу вакыйга Гайсә идарә иткән чорда булачак. Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ кабиләләре пәйгамбәр Нух галәйһиссәламнең углы Яфәснең нәсел дәвамчылары саналалар[3]. Кешелек тарихын-

[1] Иерусалим.

[2] Шамдагы (Сүрия) тау.

[3] Риваятьләрдә сөйләнелгәнчә, Нух пәйгамбәрнең дүрт углы булган. Су басканнан соң аларның өчесе генә – Хам, Сам һәм Яфәс кенә исән калган. Дин галимнәре кешелекнең нәселе алардан дәвам иткән, дип саный. Х.Габәши, мәсәлән, бу хакта болай язган: «Тарихчылар фикеренчә, бүгенге кешеләрнең нәселе Нух галәйһиссәламнең өч углы Хам, Сам һәм Яфәстән килеп чыккан.



www.darul-kutub.com

да бу халыклар элек тә булган (тасвирланган). Коръәндә алар турында түбәндәгеләр язылган:

ثُمَّ أَتْبَعَ سَبَبًا(92)حَتَّى إِذَا بَلَغَ بَيْنَ السَّدَّيْنِ وَجَدَ مِنْ دُونِهِمَا قَوْمًا لَا
يَكَادُونَ يَفْقَهُونَ قَوْلًا(93)قَالُوا يَاذَا الْقَرْنَيْنِ إِنَّ يَأْجُوجَ وَمَأْجُوجَ مُفْسِدُونَ
فِي الْأَرْضِ فَهَلْ نَجْعَلُ لَكَ خَرْجًا عَلَى أَنْ تَجْعَلَ بَيْنَنَا وَبَيْنَهُمْ سَدًّا(94)قَالَ
مَا مَكَّنَنِي فِيهِ رَبِّي خَيْرٌ فَأَعِينُونِي بِقُوَّةٍ أَجْعَلْ بَيْنَكُمْ وَبَيْنَهُمْ رَدْمًا(95)آتُونِي
زُبَرَ الْحَدِيدِ حَتَّى إِذَا سَاوَى بَيْنَ الصَّدَفَيْنِ قَالَ انفُخُوا حَتَّى إِذَا جَعَلَهُ نَارًا
قَالَ آتُونِي أُفْرِغْ عَلَيْهِ قِطْرًا(96)فَمَا اسْطَاعُوا أَنْ يَظْهَرُوهُ وَمَا اسْتَطَاعُوا لَهُ
نَقْبًا(97)قَالَ هَذَا رَحْمَةٌ مِنْ رَبِّي فَإِذَا جَاءَ وَعْدُ رَبِّي جَعَلَهُ دَكَّاءَ وَكَانَ
وَعْدُ رَبِّي حَقًّا(98)

«Шуннан соң ул юлын дәвам итте. Ике тау аралыгына килеп җиткәч, анда яшәүче халык белән очрашкан. Алар авырлык белән генә аңлашканнар. Алар әйткән: “Әй, Зөлкәрнәйн, Яҗүҗ белән Мәҗүҗләр җирдә бозыклык тараталар. Безнең

---

Африка, Һиндстан, Америка һәм кайбер утраулардагы кара тәнле кешеләр Хамның нәсел дәвамчылары саналалар. Аларны кара тәнле яки негрлар дип атыйлар. Мисырлылар, ассириялеләр, кильдониялеләр, финикиялеләр, яһүдиләр, гарәпләр, арамиялеләрнең нәсел башы – Сам, диелә. Алар семитлар дип аталалар. Яфәснең нәсел дәвамчылары ике зур төркемгә бүленә. Беренче төркемгә – арияләр, арийлар, айранийлар, иранлылар, икенчесенә тураннар, төркиләр һәм монголлар керә. Тиреләренең төсенә карап, беренчеләрен – ак тәнле, икенчеләрен сары тәнле дип йөртәләр. Арийларга, ягъни ак расага индиецлар, иранлылар, әфганнар, греклар, арнаутлар, латиннар, французлар, инглизләр, алманнар һәм славяннар керә. Туран яки сары расага индиецлар, кытайлар, японнар, финнар, төркиләр, монголлар, татарлар һәм башкалар керә». Кара: Габаши Х. Подробная история тюрков. Перев. со старотатарского. – Казань: Иман, 2006. – С. 13.

www.darul-kutub.com

белән алар арасында нинди дә булса киртә корып куйсаң, без сиңа салым түләр идек”, – дигәннәр. Ул әйткән: “Раббым миңа биргәннәр яхшырак. Сез миңа көчегездән килгәнчә ярдәм итегез. Мин сезнең белән алар арасында киртә корып куярмын, дигән. Миңа тимер кисәкләре китерегез”. Ике тау аралыгын тигезләгәннән соң, ул әйткән: “Ут кабызыгыз! Моның өстенә мин эретелгән металл коям”, – дигән. Алар моның өстенә менә дә алмаганнар, аны тишеп тә чыга алмаганнар. Ул әйткән: “Бу Раббымның мәрхәмәт-шәфкате. Ләкин Раббымның кушуы белән бу дивар (киртә) порошокка (тузанга) әйләнәчәк. Раббымның вәгъдәсе чынга ашачак”» (18:92-98). Коръәнне шәрехләүчеләр фикеренчә, әлеге аятьләрдә гадел хөкемдар Зөлкәрнәйннең хәрби походлары турында сөйләнелә. Шушы походларның берсендә әлеге хөкемдар ике тау үзәнлегендә бер халыкка тап була. Алар аңа Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ кабиләләреннән котылдырту турында ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Зөлкәрнәйн алар белән бергә шушы үзәнлектә бакыр һәм тимер эретмәсеннән плотина (буа, бөя) коеп куя. Ләкин, Коръәндә әйтелгәнчә, Аллаһ вәгъдә иткән көн җитәчәк һәм бу ике кабилә тоткынлыктан котылып чыгачак. Бу хакта Коръәндә дә әйтелгән:

حَتَّىٰ إِذَا فُتِحَتْ يَأْجُوجُ وَمَأْجُوجُ وَهُمْ مِنْ كُلِّ حَدَبٍ يَنسِلُونَ

«…Яҗүҗ белән Мәҗүҗ котылып чыкканчыга кадәр. һәм алар тау башларыннан ишелеп чыгарлар» (21:96).

Тоткынлыктан чыкканнан соң, бу халыклар үз юлларындагы барлык нәрсәләрне кырып, юк итеп барачак. Күп санлы булулары сәбәпле, аларга берәү дә каршы тора алмас. Бу вакытта Гайсә мөселманнар белән бергә Фәләстыйндагы (Палестина) Тур тавында качып торачак. Алар шушы

www.darul-kutub.com

кабиләләр белән көрәшүдә ярдәм сорап Аллаһка ялварырлар. Аллаһы Тәгалә, аларның мөрәҗәгатенә җавап итеп, шушы халыкларга аларны юк итәчәк кортларны җибәрәчәк[1].

## Дәббаның барлыкка килүе

«Дәббат» сүзе гарәп телендә гади хайванны һәм атланып йөри торган хайванны аңлата. Коръәндә бу хайван турында әйтелгән:

وَإِذَا وَقَعَ الْقَوْلُ عَلَيْهِمْ أَخْرَجْنَا لَهُمْ دَابَّةً مِنَ الْأَرْضِ تُكَلِّمُهُمْ أَنَّ النَّاسَ كَانُوا بِآيَاتِنَا لَا يُوقِنُونَ

«Аларга хәбәр иңгәч, Без аларга җир астыннан хайван чыгарып бирәчәкбез. Ул хайван алар белән сөйләшәчәк, кешеләрнең Безнең билгеләргә ышанмауларын аңлатачак» (27:82).

## Өч тапкыр җир убылу/ай тотылу

Кыямәт көненең әлеге билгесе турында мәгълүмат бик аз. Бер хәдистә бары түбәндәгеләр генә хәбәр ителгән: «…өч тапкыр җир убылачак: берсе – көнчыгышта, икенчесе – көнбатышта һәм өченчесе Гарәп ярымутравында булачак…»[2]

[1] Хәдисләрдә әлеге кортлар «Ән-нәгаф» дип аталалар. Хәдисләрне шәрехләүчеләр, бу кортларны дөя һәм сарыкларның борын куышлыкларында яши яки шуларга охшаш кортлар, дип язалар.

[2] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 225.



www.darul-kutub.com

## Кояшның көнбатыштан чыгуы

Әлеге билге турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам болай дип әйтеп калдырган: «Кояш көнбатыштан чыкмыйча, Кыямәт көне җитмәс. Бу хәлне күргәч, барлык кешеләр дә ышана башлаячак. Ләкин бу вакытта инде иман да, игелекле гамәлләр дә кешеләргә бернинди файда китермәс (берничек тә ярдәм итмәс)»[1].

## Йәмәндә ут чыгу

Кыямәт көненең зур билгеләреннән соңгысы. Хәдисләрдә сөйләнелгәнчә, ут Йәмәндә чыгып, кешеләрне Шамда җыела торган урыннарына куа барачак. Шушы билгедән соң Кыямәт көне башланачак.

## 5.4. Кыямәт көненең башлануы

Кыямәт көне, Исрафил[2] фәрештәнең Сур мөгезенә өргәненнән соң, җирдә һәм күктә барлык тереклек һәлак булып беткәч башлана. Коръәндә бу хакта язылган:

وَنُفِخَ فِي الصُّورِ فَصَعِقَ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ إِلَّا مَنْ شَاءَ اللَّهُ ثُمَّ نُفِخَ فِيهِ أُخْرَى فَإِذَا هُمْ قِيَامٌ يَنْظُرُونَ

«[Яңадан терелгән көнне] мөгезгә өрәчәкләр һәм, Аллаһ Үзе [кичерергә] теләгәннәрдән тыш башкалар: күктәгеләр дә, җирдәгеләр дә яшен белән суккан [кебек] булырлар» (39:68).

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – С. 294.

[2] Аның турында «Фәрештәләр» бүлегендә тәфсилләбрәк язылган.

www.darul-kutub.com

Мөгезгә беренче тапкыр өргәннән соң, икенче тапкыр өрерләр һәм шулвакыт җирдә кайчан да булса яшәгән барлык җан ияләре дә терелеп чыга башлаячак. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

وَنُفِخَ فِي الصُّورِ فَإِذَا هُمْ مِنَ الْأَجْدَاثِ إِلَى رَبِّهِمْ يَنسِلُونَ

«Мөгезгә өргәннән соң, алар, каберләреннән кубарылып чыгып, Раббыларына юнәләчәкләр» (36:51).

Коръәндә Кыямәт көне бөек һәм шул ук вакытта коточкыч вакыйга буларак тасвирлана. Аятьләрнең берсендә бу хакта болай сөйләнелә:

يَوْمَ تَرَوْنَهَا تَذْهَلُ كُلُّ مُرْضِعَةٍ عَمَّا أَرْضَعَتْ وَتَضَعُ كُلُّ ذَاتِ حَمْلٍ حَمْلَهَا
وَتَرَى النَّاسَ سُكَارَى وَمَا هُمْ بِسُكَارَى وَلَكِنَّ عَذَابَ اللَّهِ شَدِيدٌ

«Бу көнне, сез [һичшиксез] аны күрәчәксез, бала имезүче хатыннар балаларын калдырыр, йөкле хатыннарның карындагы сабыйлары төшәр. Күрерсең син исерек [кебек алпан-тилпән килеп] йөрүчеләрне, ләкин алар исерек булмас. Алар Аллаһы Тәгаләнең кырыс җәзаларыннан [куркып] йөрерләр» (22:2). Бу вакытта барлык туганлык һәм дуслык мөнәсәбәтләре юкка чыгачак, алар бернинди дә мәгънәгә ия булмас. Алдагы аятьләр кешеләрнең Кыямәт көнендәге халәтләрен ап-ачык сурәтли:

فَإِذَا جَاءَتِ الصَّاخَّةُ(33)يَوْمَ يَفِرُّ الْمَرْءُ مِنْ أَخِيهِ(34)وَأُمِّهِ وَأَبِيهِ(35)وَصَاحِبَتِهِ
وَبَنِيهِ(36)

«Ул көнне [икенче тапкыр] мөгезгә өргәч, бер туган үзенең икенче туганын, анасын, атасын, хатынын һәм үзенең балаларын ташлап китәчәк» (80:33-36). Ул гына да түгел, Коръәндә кешеләр үзләренең котылулары өчен туганнарын да аямаслар, диелә.

يُبَصَّرُونَهُمْ يَوَدُّ الْمُجْرِمُ لَوْ يَفْتَدِي مِنْ عَذَابِ يَوْمِئِذٍ بِبَنِيهِ(11)وَصَاحِبَتِهِ
وَأَخِيهِ(12)وَفَصِيلَتِهِ الَّتِي تُؤْوِيهِ(13)وَمَنْ فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا ثُمَّ يُنجِيهِ(14)

«Гөнаһлы кеше җәзалаудан үзенең угыллары, хатыны һәм туганы, үзен яклаган нәселдәшләре, җир йөзендәге барлык кешеләр ярдәмендә котылырга теләр» (70:11-14).

Моннан тыш, Коръәндә язылганча, Кыямәт көнендә хәтта галәмдә дә үзгәрешләр булачак. Кояшның көнбатыштан чыгуыннан һәм Исрафил фәрештәнең Сур мөгезенә беренче тапкыр өрүеннән соң, җирдә коточкыч тетрәүләр башланачак. Бу хакта Коръәндә түбәндәгеләр язылган:

إِذَا زُلْزِلَتِ الْأَرْضُ زِلْزَالَهَا(1)وَأَخْرَجَتِ الْأَرْضُ أَثْقَالَهَا(2)وَقَالَ الْإِنسَانُ مَا
لَهَا(3)

«Җир тетрәгәч һәм аның эчендәгеләр өслеккә чыккач, кеше әйтер: “Нишләде ул?” – дип» (99:1-3). Коръәнне шәрехләүчеләр фикеренчә, җир үзенең эченә яшерелгән яки күмелгән барлык нәрсәләрне, ягъни барлык хәзинәләрне, файдалы казылмаларны, кеше мәетләрен һ. б. өслеккә актарып чыгарачак. Алга таба Коръәндә тауларның тузанга әйләнүе, ә диңгезләрнең шартлавы турында язылган:

www.darul-kutub.com

وَتَكُونُ الْجِبَالُ كَالْعِهْنِ الْمَنفُوشِ

«… таулар тетелгән йон кебек калырлар…» (101:5),

وَإِذَا الْبِحَارُ فُجِّرَتْ

«…диңгезләр шартлагач…» (82:3).

Космостагы үзгәрешләр турында Коръәндә түбәндәгечә язылган:

وَتَسِيرُ الْجِبَالُ سَيْرًا

«…күкләр көчле тетрәнгән көнне…» (52:9),

إِذَا السَّمَاءُ انفَطَرَتْ(1)وَإِذَا الْكَوَاكِبُ انتَثَرَتْ(2)

«…күк йөзе тишелеп, аннан йолдызлар коелгач…» (82:1-2),

فَإِذَا انشَقَّتِ السَّمَاءُ فَكَانَتْ وَرْدَةً كَالدِّهَانِ

«…күк йөзе тишелеп, кызарган тире кебек куе кызыл төскә кергәч…» (55:37),

إِذَا الشَّمْسُ كُوِّرَتْ(1)وَإِذَا النُّجُومُ انكَدَرَتْ(2)

«…кояш кысылгач, йолдызлар сүнгәч…» (81:1-2). Аятьләрнең мәгънәсенә караганда, сүз галәмнең глобаль һәлакәте турында бара.

## Үлгәннән соң терелү[1]

Үлгәннән соң терелү дип Кыямәт көнендә кеше гәүдәләрен яңадан барлыкка китерү һәм аларга җан өрүгә әйтелә. Кешеләрдән тыш җеннәр, хайваннар, мөгезгә берен-

[1] Гарәпчә «әл-бәгъс» яки «әл-бәгъс вә ән-нушур».



www.darul-kutub.com

че тапкыр өргәннән соң үтерелгән барлык бүтән нәрсәләр дә терелтеләчәк. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, Сур мөгезенә беренче тапкыр өрү белән икенче тапкыр өргәнчегә кадәр «кырык» узачак, диелә. Ләкин ул «кырык»ның көнме, атнамы, елмы икәнлеге ачыкланылмый. Моннан соң Аллаһы Тәгалә җиргә яңгыр яудырыр һәм барысы да, җирдән үсентеләр шытып чыккан кебек, терелә башлаячак.

## Җыен[1]

Яңадан терелеп чыкканнан соң, җан ияләре Хөкем урынына җыела башлаячаклар. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

إِنْ كُلُّ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ إِلَّا آتِي الرَّحْمَانِ عَبْدًا(93)لَقَدْ أَحْصَاهُمْ وَعَدَّهُمْ عَدًّا(94)وَكُلُّهُمْ آتِيهِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ فَرْدًا(95)

«Күкләрдә һәм җирдә [яшәгән] һәркем Мәрхәмәт иясе каршысына кол буларак килеп басачак. Чөнки Ул инде барлык кешеләрнең исәбен белә һәм Кыямәт көнендә Үзенең каршысына берәм-берәм килеп басарга тиешле һәркемне барлап чыккан инде» (19:93-95). Җыен урынына хәтта хайваннар да киләчәк. Коръәндә бу хакта болай язылган:

وَإِذَا الْوُحُوشُ حُشِرَتْ

«…[барлык] кыргый хайваннар җыелгач…» (81:5).

Барлык кешеләр җыелып бетсә дә, аларны Хөкем итү тиз генә башланмаячак. Шуңа күрә Хөкемне озак көтеп сабырлыклары төкәнгән кешеләр яклау эзләп пәйгамбәрләргә мөрәҗәгать итә торырлар. Һәр пәйгамбәр аларны башка пәйгамбәргә җибәрәчәк. Шул рәвешле алар Пәйгамбәребез

[1] Гарәпчә «әл-хашр».

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә кадәр килеп җитәчәк. Ул Аллаһы Тәгаләгә Хөкемне башларга сорап мөрәҗәгать итәчәк. Аллаһ аның үтенечен кабул итеп, Хөкем итә һәм исәп-хисап ясый башлаячак.

## Исәп-хисап

Исәп-хисап дип кешенең, Аллаһ каршына килеп, үзенең дөньялыктагы тормышында кылган гамәлләре һәм сөйләгән сүзләре өчен җавап тотачак мизгелне атыйлар. Кудси[1] хәдисләрнең берсендә бу хакта түбәндәгеләр сөйләнелә: «… Әй, минем колларым! Бу чыннан да сезнең гамәлләрегез. Мин аларның барысын да исәплим һәм сезгә шуларның әҗерен насыйп итәрмен. Берәр кемсә савапларга ирешсә, Аллаһка шөкер итсен. Ә инде берәү җәзалануга дучар ителсә, үзенә үпкәләсен, үзен генә гаепләсен»[2]. Шулай ук хәдисләрдә исәп-хисап барышында кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында бернинди дә арадашчы булмаячак, дип хәбәр ителә.

Коръәндә язылганча, һәр кешегә аның гамәлләре язылган дәфтәрләр биреләчәк. Бу дәфтәрләрдә яки төргәкләрдә кешенең хәтта әһәмиятсез яхшы һәм гөнаһлы гамәлләре дә исәпкә алынган була. Коръәндә бу хакта әйтелгән:

وَوُضِعَ الْكِتَابُ فَتَرَى الْمُجْرِمِينَ مُشْفِقِينَ مِمَّا فِيهِ وَيَقُولُونَ يَاوَيْلَتَنَا مَالِ
هَذَا الْكِتَابِ لَا يُغَادِرُ صَغِيرَةً وَلَا كَبِيرَةً إِلَّا أَحْصَاهَاوَوَجَدُوا مَا عَمِلُوا

[1] Хәдисләрнең бер төре. Гади хәдисләрдән аермасы – Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламнең аларны Аллаһтан беренче зат исеменнән тапшыруында.

[2] Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 4674.

www.darul-kutub.com

حَاضِرًا وَلَا يَظْلِمُ رَبُّكَ أَحَدًا

«[Алар алдына] [гамәлләре язылган] китап (дәфтәр) куелачак һәм син күрерсең гөнаһлы кешеләрнең анда язылганнардан курыкканнарын. Алар әйтер: Хәсрәткә тарыдык! Нинди китап бу?! Анда зур гөнаһлар да язылган, кечкенәләре дә, берсе дә исәпсез калмаган. Үзләре кылганны үз күзләре белән күрәчәк алар. Әйе! Раббың берәүне дә [нахакка] үпкәләтмәс» (18:49).

Бу хакта тагын ике аятьтә сөйләнелә:

فَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَه(7)وَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَه(8)

«Кем дә булса тузан бөртеге [кадәр генә] яхшылык кылган икән, аңа шуның өчен [әҗер-савап] биреләчәк. Кем дә булса тузан бөртеге [кадәр генә] яманлык кылган икән, аңа шуның өчен [җәза] биреләчәк» (99:7-8).

Коръән һәм хәдисләрдәге текстларда, тугрылыклы мөселманнар һәм иманлы кешеләргә гамәл дәфтәрләре уң яктан бирелер һәм алар моңа бик сөенер, дип әйтелә. Коръәндә бу хакта язылган:

فَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِيَمِينِهِ فَيَقُولُ هَاؤُمُ اقْرَءُوا كِتَابِيَهْ(19)إِنِّي ظَنَنتُ أَنِّي مُلَاقٍ حِسَابِيَهْ(20)فَهُوَ فِي عِيشَةٍ رَاضِيَةٍ(21)فِي جَنَّةٍ عَالِيَةٍ(22)قُطُوفُهَا دَانِيَةٌ(23)كُلُوا وَاشْرَبُوا هَنِيئًا بِمَا أَسْلَفْتُمْ فِي الْأَيَّامِ الْخَالِيَةِ(24)

«Гамәл дәфтәре уң кулына бирелгән кеше әйтәчәк: Менә минем дәфтәремне укып карагыз! Мин үземнең исәп-хисап тотачагымны уйлап яшәдем шул. Хәзер мине биек агачларның җимешләре түбәнгә кадәр төшеп торган бакча-

www.darul-kutub.com

ларда тук мул тормыш көтә. Үзегезнең үткән тормышыгызда кылганнарыгыз өчен сөенеп, туйганчы ашагыз да, эчегез дә!» (69:19-24). Имансызлар һәм гөнаһлы кешеләргә гамәл дәфтәрләре сул якларыннан бирелер һәм алар моңа бик нык көенерләр. Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр язылган:

وَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِشِمَالِهِ فَيَقُولُ يَالَيْتَنِي لَمْ أُوتَ كِتَابِيهُ(25)وَلَمْ أَدْرِ مَا
حِسَابِيهُ(26)يَالَيْتَهَا كَانَتْ الْقَاضِيَةَ(27)مَا أَغْنَى عَنِّي مَالِيهُ(28)هَلَكَ عَنِّي
سُلْطَانِيهُ(29)خُذُوهُ فَغُلُّوهُ(30)ثُمَّ الْجَحِيمَ صَلُّوهُ(31)ثُمَّ فِي سِلْسِلَةٍ ذَرْعُهَا
سَبْعُونَ ذِرَاعًا فَاسْلُكُوهُ(32)إِنَّهُ كَانَ لَا يُؤْمِنُ بِاللَّهِ الْعَظِيمِ(33)وَلَا يَحُضُّ
عَلَى طَعَامِ الْمِسْكِينِ(34)فَلَيْسَ لَهُ الْيَوْمَ هَاهُنَا حَمِيمٌ(35)وَلَا طَعَامٌ إِلَّا مِنْ
غِسْلِينٍ(36)لَا يَأْكُلُهُ إِلَّا الْخَاطِئُونَ(37)

«Гамәл дәфтәре сул яктан бирелгән кеше әйтер: Аһ, миңа гамәл дәфтәрем бирелмәгән булса иде! Мине нинди исәп-хисап көтәчәген белмәс идем! Шушының белән генә тәмамланса иде барысы да[1]! Мал-мөлкәтем дә коткармады мине! Хакимлегем дә ярдәм итә алмый! Тотып бәйләгез аны! Аннары Җәһәннәм утында яндырыгыз! Аннары озынлыгы җитмеш терсәклек чылбырга утыртып куегыз аны! Чөнки ул Бөек Аллаһка ышанмады һәм мохтаҗларны ашатырга кушмады. Бүген аның монда дусты да юк, ашарына чүп-чардан башка нәрсә дә юк. Бу чүп-чарны гөнаһлы кешеләрдән башка берәү дә ашамый» (69:25-37).

Исәп-хисап барышында барысы да кешене яклап яки аңа каршы шаһитлек кылачаклар. Җир дә, кешенең гәүдә әгъза-

[1] «Аһ, гомерем үлем белән тәгәлләнсен иде дә аннан соң яңадан терелү булмасын иде», дип әйтү күздә тотыла.



www.darul-kutub.com

лары да, Коръән дә, пәйгамбәрләр дә, фәрештәләр дә, башка кешеләр дә – барысы да шаһит булачак.

Шулай ук Коръәннең кайбер аятьләрендә һәм хәдисләрдә кешеләрнең гамәлләре үлчәнәчәк үлчәү турында да хәбәр ителә. Мәсәлән, «Карига» сүрәсендә бу хакта әйтелгән:

فَأَمَّا مَنْ ثَقُلَتْ مَوَازِينُهُ(6)فَهُوَ فِي عِيشَةٍ رَاضِيَةٍ(7)وَأَمَّا مَنْ خَفَّتْ مَوَازِينُهُ(8)فَأُمُّهُ هَاوِيَةٌ(9)

«Үлчәүдәге [яхшы гамәлләр] тәлинкәсе авыррак булып чыккан кеше иркен, имин тормышта яшәячәк. Үлчәүдәге [яхшы гамәлләр] тәлинкәсе җиңелрәк булып чыкса, ул кешенең сыеныр урыны [Җәһәннәм] упкынында булачак» (101:6-9).

## Сират

Хәдисләрдән билгеле булганча, Сират Җәһәннәм өстеннән сузылган күпер ул. Бу күпердән иманлы бәндәләр дә, имансызлар да узачак. Коръән аятьләренең берсендә бу хакта түбәндәгечә язылган:

وَإِنْ مِنْكُمْ إِلَّا وَارِدُهَا كَانَ عَلَى رَبِّكَ حَتْمًا مَقْضِيًّا(71)ثُمَّ نُنَجِّي الَّذِينَ اتَّقَوْا وَنَذَرُ الظَّالِمِينَ فِيهَا جِثِيًّا(72)

«…арагызда анда (Җәһәннәмгә) керməячәк бер генә кеше дә юк, синең Раббың шулай карар кылган инде. Ә Без иманлы, тәкъва кешеләрне коткарырбыз, гөнаһлы бәндәләрне шунда тезләнгән килеш калдырырбыз» (19:71-72).

www.darul-kutub.com

## Буа

Хәдисләрдә язылганча, әлеге буаны Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә бүләк иткән. Буаның суы сөттән агырак, исе мускустан[1] да хушлырак, аның суын эчеп караган кеше бүтән беркайчан да сусамас.

## 5.5. Җәннәт

Җәннәт – бары тик игелекле һәм изгелекле гамәлләр кылган, гөнаһлардан читтә йөргән иманлы кешеләр генә керәчәк урын. Җәннәт бер төрле генә түгел, аның төрледән-төрле дәрәҗәләре бар. Аятьләрнең берсендә бу хакта әйтелгән:

وَمَنْ يَأْتِهِ مُؤْمِنًا قَدْ عَمِلَ الصَّالِحَاتِ فَأُوْلَئِكَ لَهُمُ الدَّرَجَاتُ الْعُلَا

«[Аның каршысына], яхшы гамәлләр генә кылып, иманлы бәндәләр булып килеп басканнарга [әҗер-савапларның] иң биекләре әзерләп куелган» (20:75). Бер хәдистә әйтелгәнчә, Җәннәтнең иң биек каты «әл-Вәсилә» дип атала һәм анда керү бары тик Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламгә генә насыйп булачак.

Коръәндә һәм хәдисләрдә Җәннәт күп тапкырлар тасвирлана. Шушы тасвирламалардан дин галимнәре түбәндәге нәтиҗәләрне ясый:

* Җәннәтнең киңлеге бары тик күкләр белән генә тиңләштерелергә мөмкин.

* Җәннәттә көйдергеч кояш та юк, өшеткеч суыклар да.

* Анда саф чиста сулы елгалар ага. Сөт елгаларының сөте беркайчан да әчеми, шәраб елгаларының шәрабы беркайчан да исертми. Шулай ук бал елгалары да ага.

[1] Хуш исле матдә.

∗ Җәннәт бакчаларында күптөрле җимеш агачлары үсә икән.

∗ Җәннәттә төрледән-төрле киекләр яши.

∗ Җәннәттә яшәүчеләр юка яшел ефәк, атлас һәм парчадан киемнәр кия.

∗ Җәннәттә яшәүчеләр өчен искитеч өйләр, урын-җирләр, хезмәтчеләр әзерләнгән.

∗ Җәннәттә яшәүчеләрнең күңелләре көнчелек, нәфрәт һәм явызлык кебек тискәре сыйфатлардан азат.

Коръәндәге бер өзектә Җәннәт түбәндәгечә тасвирланган:

فِي جَنَّاتِ النَّعِيمِ(12)ثُلَّةٌ مِنْ الْأَوَّلِينَ(13)وَقَلِيلٌ مِنَ الْآخِرِينَ(14)عَلَى سُرُرٍ
مَوْضُونَةٍ(15)مُتَّكِئِينَ عَلَيْهَا مُتَقَابِلِينَ(16)يَطُوفُ عَلَيْهِمْ وِلْدَانٌ مُخَلَّدُونَ(17
)بِأَكْوَابٍ وَأَبَارِيقَ وَكَأْسٍ مِنْ مَعِينٍ(18)لَا يُصَدَّعُونَ عَنْهَا وَلَا يُنزِفُونَ(19)
وَفَاكِهَةٍ مِمَّا يَتَخَيَّرُونَ(20)وَلَحْمِ طَيْرٍ مِمَّا يَشْتَهُونَ(21)وَحُورٌ عِينٌ(22)كَأَمْثَالِ
اللُّؤْلُؤِ الْمَكْنُونِ(23)جَزَاءً بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ(24)لَا يَسْمَعُونَ فِيهَا لَغْوًا وَلَا
تَأْثِيمًا(25)إِلَّا قِيلًا سَلَامًا سَلَامًا(26)

«Болар – рәхәтлек бакчаларында булучылар – беренче төркем, алардан калганнары азрак санда, матур бизәкле ятакларда бер-берләренә каршы ятыбрак торалар. Алар тирәсендә мәңге яшь егетләр агым чишмәдән касәләр, савытлар һәм кубоклар белән су тәкъдим итеп йөреп торалар. Ул суны эчкән кешенең башы да сызламый, башка төрле сырхаулар да борчымый икән. Үзләре теләгән җиләк-җимешләрне,

үзләре теләгән кошларның итен ашыйлар икән. Ә зур кара күзле, ялтырап торган энҗе кебек хур кызлары аларның кылган гамәлләре өчен бүләк була. Алар анда буш сүзләр дә, гөнаһлары өчен шелтәләү дә ишетмәс. Бары тик «Тынычлык, тынычлык!» дигән сүзләр генә кабатланыр» (56:12-26).

## 5.6. Җәһәннәм

Җәһәннәм – Җәннәтнең капма-каршысы, бу урында гөнаһлы һәм имансыз кешеләр булачак. Коръән аятьләре һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләрендәге Җәһәннәмне тасвирлаулардан түбәндәге нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин:

* Җәһәннәм җәзалары ут белән генә чикләнми, анда суык та, күләгә дә, су да бар. Тик боларның барысы да җәзалау өчен әзерләнгән.

* Җәһәннәм уты җирдәге утка охшамаган. Беренчедән, ул җирдәге утка караганда күп тапкырлар көчлерәк; икенчедән, җирдәге ут белән чагыштырганда, Җәһәннәм уты үтерми, юкка чыгармый, ул газаплый, җәфалый.

* Җәһәннәм утыннан үлеп котылып булмый, чөнки җәһәннәмдәгеләр үлемсез.

* Үзенә керүчеләрне Җәһәннәм үкереп, ут-очкыннар чәчеп каршы ала.

* Гөнаһлылар һәм имансызлар өчен Җәһәннәмдә төрледән-төрле җәзалаулар каралган.

* Җәһәннәмдәгеләр үзләренең Аллаһларын күрмәсләр.

* Җәһәннәм ризыгы ашыйсы килүне һәм сусауны басмый, газаплый гына.

Җәһәннәмдәгеләрнең ризыгы турында Коръәндә болай язылган:

لَآكِلُونَ مِنْ شَجَرٍ مِنْ زَقُّومٍ(52)فَمَالِئُونَ مِنْهَا الْبُطُونَ(53)فَشَارِبُونَ عَلَيْهِ مِنَ الْحَمِيمِ(54)فَشَارِبُونَ شُرْبَ الْهِيمِ(55)

«Аннан соң сез – тугры юлдан язганнар, ялганда гаепләнүчеләр – заккум агачының җимешләре белән карыннарыгызны тутырырсыз һәм кайнар сулар эчәрсез, бик нык сусаган кешеләр шикелле эчәрсез» (56:52-55).

Коръәннең икенче бер аятендә әлеге агачның җимешләре турында тәфсилләбрәк язылган:

إِنَّ شَجَرَةَ الزَّقُّومِ(43)طَعَامُ الْأَثِيمِ(44)كَالْمُهْلِ يَغْلِي فِي الْبُطُونِ(45)كَغَلْيِ الْحَمِيمِ

«Заккум агачының җимешләре – гөнаһлыларның азыгы. Ул карыннарда бакыр кебек кайнап тора, су кайнагандай кайный» (44:43-46).

Тагын бер аятьтә болай диелгән:

طَلْعُهَا كَأَنَّهُ رُءُوسُ الشَّيَاطِينِ

«Аның җимешләре шайтан башларына охшаган» (37:65).

Җәһәннәмнең җәзалары һаман яңартылып торачак. Коръәндә бу хакта болай әйтелгән:

إِنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا بِآيَاتِنَا سَوْفَ نُصْلِيهِمْ نَارًا كُلَّمَا نَضِجَتْ جُلُودُهُمْ بَدَّلْنَاهُمْ جُلُودًا غَيْرَهَا لِيَذُوقُوا الْعَذَابَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَزِيزًا حَكِيمًا

«Чыннан да, Безнең кушканнарга ышанмаучыларны Без утта яндырачакбыз! Аларның тиреләре чыдый,ияләнә генә

башлагач, Без аларның тиреләрен яңага алыштырып, җәзаларны дәвам иттерәчәкбез. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә Бөек һәм Хикмәт иясе!» (4:56).

## 5.7. Шәфәгать

Хәдисләрнең берсендә әйтелгән: «Һәр пәйгамбәрнең Аллаһы Тәгалә һичшиксез кабул итә торган догасы бар. Барлык пәйгамбәрләр дә дога кылырга ашыктылар, ә мин яклау сорап дога кылуымны Кыямәт көненә кадәр калдырып торырга булдым. Минем догам миңа ияргән булып, Аллаһка ышанган килеш үлгән һәр кешегә дә кагылачак»[1]. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең яклавы түбәндәге төрләргә бүленә:

1. Зур шәфәгать – барлык кешеләр дә, бер урынга җыелып, Хөкем башланганны көткәндә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам Аллаһка Хөкем башлауны үтенеп дога кылачак. Бу төр яклау иманлы кешеләргә дә, имансыз бәндәләргә дә кагылачак.

2. Кайбер мөселманнарның Җәннәткә керүләрен сорап дога кылу.

3. Җәннәттәгеләрнең дәрәҗәләрен арттыруны сорап дога кылу.

4. Кайбер гөнаһлы мөселманнарның Җәһәннәмгә кертелмәүләрен сорап дога кылу.

5. Җәһәннәмгә эләккән мөселманнарны аннан чыгару өчен ялварып дога кылу.

Моннан тыш, хәдисләрдә әүлияләрнең, җәфаланучыларның, сабый чакларында үлгән балаларның, Коръән, дога, уразаның һ. б. яклавы турында да сөйләнелә.

[1] Кара: ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама аль-кубра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – С. 174.



www.darul-kutub.com

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абдаль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

3. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

4. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама аль-кубра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – 287 с.

5. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кийама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – 310 с.

6. Адыгамов Р. К. Мусульманское вероубеждение (акыда). – Казань: Иман, 2003. – 79 с.

7. Аль-Бухари. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

8. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

9. Валиуллин К. Гакыйда. – Казань: Иман, 1999 – 87 с.

10. Габаши Х. Подробная история тюрков. Перев. со старотатарского. – Казань: Иман, 2006. – 180 с.

11. Крачковский И. Ю. Коран (перевод). – Минск, 1990.

12. Курсави Г. Тафсир байан. – Казань: Типография Домбровского, 1915. – 192 с.

13. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (аль-Хикма аль-балига), предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: ТКИ, 2008. – 479 с.

www.darul-kutub.com

14. Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. «Кыямәт көне» бүлеге нәрсәләрне өйрәнә?
2. Исламда дөньяви тормышка һәм мәңгелек яшәешкә нинди урыннар бирелгән?
3. Коръәннән Кыямәт көненә ышану турындагы аятьне сөйләгез.
4. Кыямәт көне җитүнең мөмкинлеген нигезле дәлилләүгә мисал китерегез.
5. Ислам тәгълиматында үлем турындагы күззаллаулар турында сөйләгез.
6. Үлгән кеше белән каберендә нинди хәлләр булуын сөйләгез.
7. Хәнәфиләр фикеренчә, исәннәрнең нинди гамәлләре мәетләргә җиңеллек китерергә (ярдәм итәргә) мөмкин?
8. Кыямәт көненең вакыты билгелеме? Җавабыгызны Коръәндә һәм Сөннәттә язылганнар белән раслагыз.
9. «Әшрат әс-сага» терминына билгеләмә бирегез.
10. Кабердә фәрештәләр нинди сораулар бирә?
11. Кабердә сорау алучы фәрештәләрнең исемнәре ничек?
12. Кыямәт көненең барлык зур билгеләрен атап чыгыгыз.
13. Дәҗҗал кем ул һәм ул кайдан килеп чыгачак?
14. Дәҗҗал нинди могҗизалар күрсәтәчәк һәм нәрсәләргә өндәячәк?
15. Дәҗҗалның үзенчәлекле сыйфатларын атагыз.

www.darulkutub.com

16. Мөселман галимнәре Дәҗҗалдан саклану өчен нинди чараларны атыйлар?

17. Гайсәнең күктән җиргә төшкәннән соң кылган гамәлләре турында сөйләгез.

18. Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ кабиләләре кемнәр һәм алар кемнән барлыкка киләләр?

19. Алар турында Коръәндә нәрсәләр язылган?

20. Бу халыклар җирдә нишләячәк һәм алар ничек һәлак ителәчәкләр?

21. Дәббатның барлыкка килүе турында сөйләгез һәм Коръәннән дәлилләр китерегез.

22. Өч тапкыр җир убылган яки ай тотылган урыннарны санап чыгыгыз.

23. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам кояшның көнбатыштан чыгуы турында нәрсә әйтеп калдырган?

24. Йәмәндә ут чыгу турында сөйләгез.

25. Кыямәт көнендә җирдә нинди үзгәрешләр күзәтеләчәк?

26. Кыямәт көнендә галәмдә нинди үзгәрешләр булачак?

27. Сур мөгезенә ничә тапкыр өреләчәк һәм өргән саен нинди хәлләр булачак?

28. Исәп-хисап нәрсә ул?

29. Сират нәрсә ул? Дин галимнәре фикеренчә, Сират турында әйтелгән аятьне сөйләгез.

30. Җәннәтне тасвирлап бирегез.

31. Җәннәтне тасвирлаучы аятьләрне сөйләгез.

32. Җәһәннәмне сурәтләп бирегез. Җәһәннәмдәге җәзаларны тасвирлаган аятьләрне сөйләгез.

33. Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең яклау төрләрен санап чыгыгыз.

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 6 БҮЛЕК

# ТӘКЪДИРГӘ ЫШАНУ

Тәкъдиргә ышану иманның алты багасыннан берсе була. Аларны тану мөселманнар өчен мәҗбүри. Шуңа күрә дә тәкъдирне кабул итмәү яки кире кагу имансызлык санала.

Тәкъдир «әл-гайбият» (яшерен белем) өлкәсенә керә, шуңа күрә тәкъдиргә ышану аеруча кыйммәтле. Тәкъдирнең асылы Аллаһы Тәгаләгә кешеләрнең үткәндәге кылган һәм киләчәктә кылачак барлык гамәлләренең һәм кешелек тарихындагы барлык вакыйгаларның мәгълүм булуыннан гыйбарәт. Аллаһ әлеге вакыйгаларны Үзенең Кануны буенча тормышка ашыра.

Безнең дин галимнәребез тәкъдиргә ышануны ике өлешкә: кадә (алдан белү) белән кадергә (тәкъдир) бүлеп карыйлар.

Кадә – Аллаһның киләчәктә булачак вакыйгалар турында белүе ул. Кадер – Аллаһның шушы кадәгә, ягъни Үзенең Белүенә карап әлеге вакыйгаларны тормышка ашыруы. Шушы бүленешкә карамастан, бу ике өлеш бербөтен булып кала. Шулай итеп, тәкъдир Аллаһы Тәгаләнең барлык булган

www.darulkutub.com

һәм буласы вакыйгаларны белүен, Үз Ихтыярын һәрвакытта да чынга ашыруын, Көч-Куәтенең чикләнмәгән булуын, Аның язганнарын берәүнең дә белә алмавын күздә тота.

Хәдисләрдән мәгълүм булганча, тәкъдирнең үз тарихы бар. Бер хәдистә Аллаһы Тәгалә беренче чиратта «каләм»не барлыкка китергән, диелә. Каләмне бар иткәч, Аллаһ аңа: «Яз!» – дип кушкан. Каләм: «Нәрсә языйм соң?» – дип сорагач, Аллаһ: «Кыямәт көненә кадәр булачак барлык нәрсәләрне дә яз»[1], – дип җавап биргән. Нәтиҗәдә, каләм Аллаһы Тәгаләнең кушуы белән «Ләүх әл-мәхфүз»гә бу дөньяның барлыкка китерелүеннән алып Кыямәт көненә кадәр булачак барлык вакыйгаларны да язып куйган. Коръәндә бу хакта болай язылган:

أَلَمْ تَعْلَمْ أَنَّ اللَّهَ يَعْلَمُ مَا فِي السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ إِنَّ ذَلِكَ فِي كِتَابٍ إِنَّ ذَلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ

«Аллаһның күктә һәм җирдәге вакыйгалардан хәбәрдар булуын син белмисеңмени? Чыннан да, болар тәкъдирдә язылган инде. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә өчен мөмкин булмаган нәрсәләр юк!» (22:70)

Күргәнебезчә, тәкъдир ике Илаһи сыйфат – Аллаһның Бар нәрсәне белүенә һәм Көч-Кодрәтенә бәйле. Югарыда искә алынганча, Аллаһның Бар нәрсәдән хәбәрдар булуы абсолют, чикләнмәгән, уникаль (бердәнбер). Аңа бар нәрсә дә керә, Ул әлеге белемнәрне өйрәнеп тә, кайдандыр эзләп тә тапмаган. Шушы сыйфатка ия булу сәбәпле, Аллаһы Тәгалә дөнья

[1] Ахмад ибн Ханбал. Муснад. – Электронный ресурс CD-диск «Маусу‘ат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 21649.

барлыкка китерелгәнчегә кадәр үк Үзе бар итәчәк нәрсәләр турында хәбәрдар булган. Ул кемне, нәрсәне һәм кайчан барлыкка китерәчәген дә, Үзе барлыкка китергәннәр белән нинди вакыйгалар буласын да алдан ук белгән инде. Шушы Белемгә бәйле рәвештә каләм боларның барысын да «Ләүх әл-мәхфүз»гә язып куйган. Икенче Илаһи сыйфат ярдәмендә Аллаһы Тәгалә, Үзенең Белеменә нигезләнеп, барлык вакыйгаларны да чынга ашыра.

### 6.1. Аллаһның Ихтыяры белән кеше ихтыярының бәйләнеше

Әлеге мәсьәләнең нигезен Коръәннең сүзгә-сүз мәгънәсе каршылыклы булган аятьләре тәшкил итә. Берничә мисал китерик. Аятьләрнең берсендә әйтелгән:

وَهَدَيْنَاهُ النَّجْدَيْنِ

«Аны [яхшылык һәм яманлык] дигән ике юлдан алып киттеләр [ме]?» (90:10) Әлеге аятьнең мәгънәсе кешенең яхшылык белән яманлык арасында сайлый алу мөмкинлеге барлыгына ишарәли. Ләкин шулай ук Коръәндә кеше ихтыярының Аллаһ Ихтыярына буйсындырылуы турында да аятьләр бар. Мәсәлән:

وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلِيمًا حَكِيمًا

«Ләкин, Аллаһы Тәгаләгә шулай кирәк булса, сез моны теләмәссез. Чыннан да, Аллаһ Барысын да Белүче, Хикмәт иясе» (76:30).

مَنْ يَهْدِ اللَّهُ فَهُوَ الْمُهْتَدِي وَمَنْ يُضْلِلْ فَلَنْ تَجِدَ لَهُ وَلِيًّا مُرْشِدًا



www.darul-kutub.com

«Аллаһы Тәгалә йөрткән кеше тугры юлдан бара; ә инде Ул ялгыштырса, яклаучыны да, [рухи] остазны да берничек тә табып булмый» (18:17).

Изге Китаптагы әлеге каршылыклар игътибарсыз калмаган. Әлбәттә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең сахабалары моңа беренче булып игътибар иткәннәр. Әт-Тирмизинең «Сахих сунан» исемле хәдисләр җыентыгында (223/2)[1] Әбү Һөрәйрә сөйләп калдырган бер хәдис китерелгән. Бу хәдистә: «Аллаһның Илчесе безнең янга без тәкъдир турында бәхәсләшеп торган вакытта килде…» диелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бәхәснең ни хакта булуын белгәч, бик нык ачуланган. Шушы ук хәдиснең икенче вариантында ул ачуланып: «Бер аятьләрне икенче аятьләргә ничек каршы куя аласыз соң сез? Шуның аркасында сезгә кадәр яшәгән халыклар хараб ителде бит», – дигән икән[2]. Әлеге хәдиснең беренче вариантында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бәхәскә карата тискәре фикер белдерсә, икенче вариантта исә ул Илаһи Китапның аерым бер кисәкләренең икенчеләренә каршы куелуын тәнкыйтьли.

Әлеге мәсьәләне сөнни галимнәре кеше гамәлләрен икегә бүлеп хәл иткәннәр.

Беренче төргә гамәлләрнең барлыкка китерелүенә кешенең бернинди дә катнашы булмаган гамәлләр кертелгән. Әлеге гамәлләр өчен мәҗбүр итү яки ихтыяр дигән төшенчәләр хас түгел. Дин галимнәре боларга яңгырлар, күк җисемнәре, үсемлекләрнең үсүе, йокы, авырулар, ярлылык, сәламәтлек, тетрәнү (мускулларның ирексездән кыскаруы), йөрәк тибе-

[1] ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Када ва аль-кадар. – Амман, 2002 – С. 50.

[2] Әхмәд нөсхәсендә – 2 т., 178–181 б. – һәм Ибн Мәҗи нөсхәсендә – № 85.



www.darul-kutub.com

ше, аш кайнату әгъзаларының эшләве, зирәклек, ахмаклыкны һ. б. кертеп карыйлар. Алар фикеренчә, әлеге гамәлләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан кеше ихтыярыннан башка гына барлыкка китерелә[1].

Икенче төргә кешенең ихтыяры белән барлыкка китерелгән гамәлләр, мәсәлән: ашау, эчү, басу, утыру, йөрү, ашарлык-яшәрлек өчен эшләү, кеше башкарырга тиешле дини гамәлләр керә. Асылы белән әлеге гамәлләр дә Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән, ә менә сыйфатлары белән – юк[2].

Теге яки бу гамәлнең сыйфатламасына килгәндә, мәсәлән, аның тугры гамәл яки гөнаһлы эш булуын карасак, бу исә кешенең ихтыярына бәйле.

Моңа мисал итеп нинди дә булса җиһазның техник документларын алып карарга мөмкин. Техник документларда уйлап табучы инженер шушы җиһазның дөрес эшләве өчен кирәкле шартларны, куркынычсызлык техникасы шартларын һ. б. санап чыга. Теге яки бу шарт бозылган очракта җиһазның ватылачагын инженер яхшы белә. Шуңа күрә дә ул шушы җиһаздан файдаланучы эшчегә искә алынган шартларны бозарга кушмый.

## 6.2. Аллаһка тапшырылу (әт-тавәккул)

Әт-тавәккул (Аллаһка тапшырылу) темасы да тәкъдир белән тыгыз бәйләнгән. Ислам безне теләсә кайсы хәлдә, очракта Аллаһы Тәгаләгә тапшырылырга, Аңа ышанырга чакыра, әмма шул ук вакытта теге яки бу максатка ирешү

---

[1] ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Исламское вероучение (Толкование акыды «Ан-Насафиййа). – Казань, 2007 – С. 87.

[2] Шунда ук.



www.darul-kutub.com

өчен, барлык мөмкин булган шартларны да үтәргә куша. Ягъни сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре канунын башкарырга куша. Мәсәлән, нинди дә булса үсемлекнең уңышын җыеп алу өчен җирне эшкәртергә, кирәкле ашламалардан файдаланырга, орлыкларны чәчәргә, вакытында сугарырга, корткыч бөҗәкләр белән көрәшергә һ. б. кирәк. Шуннан соң гына, Аллаһка тапшырылып, уңыш өлгергәнне көтәсе кала. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре Аллаһ тарафыннан билгеләнгән һәм аларны үтәргә кирәк. Ләкин шул ук вакытта бар нәрсәнең дә Аллаһы Тәгалә Ихтыяры белән барлыкка килүен дә онытмаска ти-ешле.

## Тәкъдим ителгән әдәбият

1. ʻАбдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-ʻакыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-ʻулюм аш-шарʻиййа», б. г. – 62 с.

2. ʻАбдальмалик ʻАбдаррахман ас-Саʻди. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафиййа». Перевод с арабского языка. – Казань: Изд-во «Иман», 2006. – 232 с.

3. ʻАбд аль-Малик ʻАбд ар-Рахман ас-Саʻди. Шарх ан-Насафия фи аль-ʻакыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

4. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

5. ʻУмар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Када ва аль-кадар. – Амман: Дар ан-Нафа'ис, 2002. – 117 с.

6. Абу Хамид Мухаммад ибн Мухаммад аль-Газали ат-Туси. Высочайшее из устремлений в раскрытии смыслов прекрасных имен Аллаха/ перевод с арабского Саяхова Р. Л. – Уфа, 2007. – 232 с.

www.darul-kutub.com

7. Ахмад ибн Ханбал. Муснад. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

8. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

9. Ульрих Р. Аль-Матуриди и суннитская теология в Самарканде. – Алматы: Фонд «XXI век», 1999. – 286 с.

## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Тәкъдиргә ышану нәрсәне аңлата?

2. «Кадә» белән «кадер» терминнарына билгеләмә бирегез.

3. Тәкъдиргә бәйле рәвештә «Ләүх әл-мәхфүз» турында сөйләгез.

4. Тәкъдир нинди Илаһи сыйфатларга бәйле?

5. Безнең дин галимнәре Аллаһның Ихтыяры белән кеше ихтыярының бәйләнеше проблемасын ни рәвешле чишкәннәр?

6. Сөнни дин галимнәре кешеләрнең гамәлләрен нинди ике төркемгә бүлеп карыйлар?

7. Сөнни дин галимнәре «әт-тавәккул»нең мәгънәсен ничек аңлыйлар?

www.darul-kutub.com

العقيدة

## 7 БҮЛЕК

# ӨСТӘМӘ СОРАУЛАР

Әлеге бүлектә мөселман дин гыйлеменең алдагы алты бүлегендә каралмаган, ләкин аларның барысы белән дә бәйләнгән мәсьәләләр күтәрелә. Аерым алганда, бу бүлектә иман һәм имансызлыкка билгеләмә бирелә, иманның дәрәҗәләре, аның үзгәрүчәнлеге карала, шулай ук зур гөнаһлар мәсьәләсе тикшерелә, аларга билгеләмә бирелә, аларның иман белән мөнәсәбәте тикшерелә, зур гөнаһларга мисаллар һәм гафу ителүләре өчен таләп ителә торган гамәлләр китерелә. Алдагы бүлекләр теоретик характерда бирелгән булса, әлеге бүлек гамәли характерга ия һәм мөселман дин гыйлеменең гамәли мәсьәләләренә игътибар итә.

### 7.1. Иман

Без, хәнәфиләр, иман дип Коръәндә һәм Сөннәттә язылганнарның барысын да күңелең белән кабул итү һәм аның турында телдән шаһитлек кылуга әйтәбез. Ләкин Коръәндә һәм Сөннәттә системалаштырылмаган мәгълүматның күп

www.darul-kutub.com

булуы аркасында, дин галимнәре кабул итү өчен мәҗбүри булган түбәндәге пунктларны аерып карыйлар: Аллаһы Тәгаләнең Барлыгына һәм Берлегенә ышану, фәрештәләрнең һәм пәйгамбәрләрнең барлыгына ышану, барлык Илаһи Китапларны кабул итү, Кыямәт көненә һәм тәкъдиргә ышану, шулай ук Аллаһның барлык кушканнарын үтәү өчен мәҗбүри дип, ә Аллаһ тыйганнарны тыелган дип кабул итү. Димәк, югарыда аталганнарның барысын да күңелдән кабул итүче һәр кеше Аллаһы Тәгалә каршында иманлы бәндә була. Ә инде югарыда саналганнарга ышану турында телдән шаһәдәтлек кылу шаһәдәт кәлимәсен әйткән кешегә карата Шәригать кануннарын куллану өчен кирәк.

Китерелгән билгеләмәдән дин галимнәре нәтиҗә чыгардылар: беренчедән, кем дә булса иманны күңеле белән кабул итеп, аны телдән әйтмәгән икән, ул Аллаһ каршында иманлы кеше була, ә тормышта аңа карата имансызларга кулланылган кануннар кулланыла. Икенчедән, кем дә булса иманын телдән шаһәдәтлек кылып, күңеле белән кабул итмәгән икән, ул Аллаһ каршында имансыз бәндә була, әмма тормышта аңа карата иманлы кешеләргә кулланылган кануннар кулланыла.

Дин галимнәребезнең бу карашы «иман» сүзенең лексик мәгънәсенә («ышану, нәрсәне дә булса хакыйкать, дөреслек дип кабул итү) нигезләнә. Шул ук вакытта алар түбәндәге Коръән аятен дәлил итеп китерәләр:

قَالُوا يَاأَبَانَا إِنَّا ذَهَبْنَا نَسْتَبِقُ وَتَرَكْنَا يُوسُفَ عِنْدَ مَتَاعِنَا فَأَكَلَهُ الذِّئْبُ وَمَا أَنْتَ بِمُؤْمِنٍ لَنَا وَلَوْ كُنَّا صَادِقِينَ

«Алар әйттеләр: “Әй, атабыз! Без узыша башладык, ә Йосыфны әйберләребез янында калдырдык. Аны бүре ашаган. Ләкин без *дөресен сөйләгән* булсак та, син безгә *ышанмассың”*» (12:17).

## 7.2. Иман даими буламы, әллә ул үзгәрүчәнме?

Безнең хәнәфи мәзһәбе карашынча, иман артмый да, кимеми дә. Дин галимнәре моны түбәндәгечә раслыйлар: «Кабул итү нык ышанганлык дәрәҗәсенә җиткән икән, ул артырга да, кимергә дә мөмкин түгел». Ягъни кеше нәрсәнең дә булса хакыйкыйлыгын таный яки танымый. Мәсәлән, бер кешегә китап күрсәткәндә ул шуның китап икәнен кабул итә яисә кире кага.

Аллаһы Тәгалә Коръән аятьләрендә иман һәм гамәлләрне грамматик яктан бәйлек белән берләштергән. Бу күренеш гамәлләр белән иманның төрле төшенчәләр булуына ишарәли. Мәсәлән:

إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ كَانَتْ لَهُمْ جَنَّاتُ الْفِرْدَوْسِ نُزُلًا

«Чыннан да, ышанган һәм яхшы гамәлләр кылганнар өчен» (18:107). Димәк, гамәлләр иманның бер өлеше түгел һәм аның артуы яки кимүенә берничек тә тәэсир итмиләр[1].

## 7.3. Иманның төрләре

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам хәдисләрендә иманның төрле дәрәҗәләре булуы искә алына. Хәдисләрнең берсендә бу хакта болай әйтелгән: «Иманның

[1] Алар шулай ук беренче төркемдә китерелгән аятьләргә дә тиешле аңлатма биргәннәр.

җитмеш яки алтмыштан артык тармагы бар. Шуларның иң югары дәрәҗәдәгесе – «Аллаһтан башка Илаһ юк» дигән сүзләрне әйтү[1], ә иң түбән дәрәҗәдәгесе – юлдан комачаулап яткан әйберләрне алып читкә кую. Оялчанлык та иман тармакларының берсе». Шушы хәдискә охшаш хәдисләрдән дин галимнәре иманның дәрәҗәләрен эзләп тапканнар һәм аларны өйрәнгәннәр.

Шул ук вакытта иман башкача тәкъдим ителгән хәдисләр дә бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең бер хәдисендә әйтелгән: «Һәр бала тумыштан иманлы була. Ә ата-аналары аны яһүди, христиан яки утка табынучыга әйләндерәләр…»[2] Моның ише хәдисләрдән дин галимнәре иманның түбәндәге дүрт төрен аерып чыгарганнар: әл-иман әл-фитри – һәр нарасыйга тумыштан бирелгән иман; әл-иман әт-тәкълиди – үзен нинди дә булса милләт яки дингә кертеп караган кешегә хас гадәти иман; әл-иман әл-истидләли – дәлилләргә нигезләнгән иман, ул акыл белән кабул ителгән иман; әл-иман әл-хакыйкый – рухи эзләнү нәтиҗәсендә кабул ителә торган хакыйкый, чын иман. Түбәндә китерелгән рәсемне карагыз.




[1] Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 51.

[2] Аль-Бухари. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусугат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997). – Хадис № 1270.

www.darul-kutub.com

Хакыйкый (чын) иман (әл-иман әл-хакыйкый)

Дәлилләргә нигезләнгән иман (әл-иман әл-истидләли)

Гадәти иман (әл-иман әт-тәклиди)

Тумыштан бирелгән иман (әл-иман әл-фитри)

Татар дин галиме Г. Утыз-Имәни үзенең хезмәтләренең берсендә иманның аталган дүрт дәрәҗәсеннән өчесен генә: гадәти иман, дәлилләргә нигезләнгән иман һәм хакыйкый иманны атап узган[1].

[1] «Иманның өч дәрәҗәсе бар. Аларның беренчесе ныгыган иман дип атала. Ул саналган барлык сыйфатларны да кабул итү һәм аларга чиксез ышануны күздә тота. Әлеге иманның дәрәҗәсен барлык җан ияләренең имансызлыклары да какшата алмый, аңа теләсә нинди шартларда да шикләнү хас түгел. Ул Аллаһы Тәгаләнең сөекле бәндәләрендә генә була. Иманның икенче дәрәҗәсе – дәлилләргә нигезләнгән иман. Иманлы кеше, Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән нәрсәләрнең яшәешенә дәлилләр табып, Аның Барлыгына ышана. Бу дөньяның үзеннән-үзе барлыкка китерелмәгәнлегенә һәм аның Барлыкка Китерүчесе булуына шик юк. Әлеге дөньяның тотрыклы яшәеше шулай ук Аллаһның барлыгына дәлил була. Югыйсә, бу дөнья әллә кайчан юкка чыккан булыр иде инде. Без җирдә эз күрсәк, аның кеше эзе икәнен беләбез; хайван эзе икән – аның хайванныкы булуын беләбез. Ягъни эзне кем дә булса калдырган булырга тиеш. Икенче төрле әйткәндә, без бер нәрсәнең барлыгы турында башка нәрсәнең барлыгыннан чыгып беләбез. Көн белән төннең, җәй белән кышның, яз белән көзнең даими һәм тотрыклы рәвештә алмашынып торулары шулай ук Аллаһы Тәгаләнең барлыгына дәлил булып тора. Иманның әлеге төре җирдәге барлык галимнәр дә имансызга әверелгән очракта да какшамас. Ул уртача дәрәҗәдәге тәкъвалыкка ия кешеләргә хас. Иманның өченче төре – гадәти иман. Ул ата-бабаларның иманлы (мөселманнар) булуына нигезләнә һәм аның өчен Аллаһның Барлыгына нинди дә булса дәлилләр эзләү таләп ителми. Бу төр иман бик зәгыйфь. Кеше гомере буена шушы иман белән яшәгән булса, үләр алдыннан аның янына шайтан килеп, иманын какшатырга мөмкин, дигән фикер бар. Әлеге иман теләсә кайсы шикләнүләргә бирешүчән». Иманның икенче төрен галим тагын да ике төргә бүлеп карый: төпле дәлилләргә нигезләнгән иман (гакли) һәм Коръән белән Сөннәттәге дәлилләргә нигезләнгән иман (нәкли). Кара: Утыз-Имяни Г. Избранное. – Казань: ТКИ, 2007. – С. 256–257.

## 7.4. Имансызлык[1]

Имансызлык («көфер») – Коръән белән Сөннәттәге мәгълүматны тулысынча яки өлешчә кабул итмәү. Без Коръәннең һәр хәрефе һәм сүзенең «мөтәвәтир» дип аталган күп санлы ышанычлы юллар белән тапшырылган Аллаһның сөйләме булуына ышанырга тиеш[2]. Сөннәткә килгәндә, ул хәдисләр дөреслеге яки шиклелегенең теге яки бу аспектын билгеләүче күп санлы төрләргә бүленә. Моңа бәйле рәвештә без Сөннәтнең хакыйкый өлешен генә танырга тиеш. Димәк, аның шикле өлешен кире кагу имансызлыкка керми.

«Көфер» сүзенең лексик мәгънәсе «яшерергә», «ябарга», «капларга» дигәнне аңлата. Дини терминологиядә ул сүз «хакыйкый динне яшерү» мәгънәсендә кулланыла. Бу дөньядан имансыз булып үткән кеше Җәһәннәмдә мәңгелек җәзалауларга дучар ителәчәк. Коръәндә бу хакта болай әйтелгән:

إِنَّ الْمُجْرِمِينَ فِي عَذَابِ جَهَنَّمَ خَالِدُونَ(74)لَا يُفَتَّرُ عَنْهُمْ وَهُمْ فِيهِ
مُبْلِسُونَ(75)

«Гөнаһлы кешеләр, чыннан да, мәңге Җәһәннәм җәзалауларында булачак. Аларга бернинди дә җиңеллек китерелмәс һәм алар анда өметсезлеккә, төшенкелеккә биреләчәкләр» (43:74-75).

[1] Кара: Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

[2] Әлеге термин мөселман дин гыйлемендә төп Ислам чыганакларының хакыйкыйлыгын тасвирлау өчен кулланыла. «Мөтәвәтир» төшенчәсенең төгәл билгеләмәсе түбәндәгечә: тапшыручыларның күплеге аларның сүз берләшүләренә шик тудырмаслык күп санлы чылбырлар буенча тапшырылган мәгълүмат блогы (гадәттә Коръән аятьләре һәм хәдисләр).



www.darul-kutub.com

## 7.5. Зур гөнаһлар[1]

Безнең дин галимнәребез «зур гөнаһлар» төшенчәсенә түбәндәгечә билгеләмә бирделәр: «Гамәлне кылган өчен Аллаһ тарафыннан физик җәзалау, үлем җәзасы каралган яки Ул Үзенең ачуын, каһәрен, җәһәннәм белән җәзалауны вәгъдә иткән икән, әлеге гамәл зур гөнаһ санала».

Шушы билгеләмәгә нигезләнеп, дин галимнәре зур гөнаһларга мәҗүсиләрнең ышанулары, төпле сәбәпсез кеше үтерү[2], зина кылу, исерткеч эчемлекләр эчү, караклык, ата-аналарның Аллаһ кушканнарга каршы килми торган[3] сүзләрен тыңламау, сихерчелек, ятимнәрнең милкеннән шәхси максатларда файдалану, рибачылык, нахакка кешеләрне зинада гаепләү, сугыш кырыннан качу, ялган шаһитлек кылу, ялган сөйләү, иренең Аллаһ кушканнарга каршы килмәгән[4] гамәлләренә хатынның буйсынмавы, башка кешенең ата-анасына карата әшәке (әдәпсез) сүзләр сөйләү[5], гайбәт сөйләү, яла ягу, тәкәбберлек, башкаларга күрсәтү өчен генә гыйбадәт кылу, талау, ирләргә ефәк һәм алтын әйберләр киеп яки тагып йөрү, Шәригатьнең мәҗбүри кануннарын үтәмәү, тыелганнарны ашау һәм эчү, эшчегә хезмәт хакын вакытында түләмәүне кертеп карыйлар. Болардан тыш, дин галимнәренең хезмәтләрендә шушы төр гөнаһларга тагын башка күптөрле гамәлләр дә кертелгән. Шулай ук, кечкенә

[1] Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с. и ʻАбд аль-Малик ʻАбд ар-Рахман ас-Саʻди. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафиййа». Перевод с арабского языка. – Казань: Изд-во «Иман», 2006. – 232 с.

[2] Үз-үзеңне саклау максатыннан үтерү яки хөкем карары белән җинаятьчене җәзалап үтерү төпле сәбәп булып санала һәм зур гөнаһларга кертелми.

[3] Ата-аналары балаларының иманнан язуларын яки тыелганнарны эшләүләрен таләп иткән очракта, Ислам аларның сүзләрен тыңламаска рөхсәт итә.

[4] Ата-аналарның сүзләрен тыңламаудагы кебек үк шартлар.

[5] Чөнки бу очракта ул кеше җавап итеп әдәпсез сөйләнүче кешенең ата-анасына карата да әшәке сүзләр сөйләргә мөмкин.

гөнаһ еш кылынган очракта зур гөнаһка әверелергә мөмкин, дип санала.

Зур гөнаһ кылган кеше «мөртәкиб әл-кабира» яки «фәсик» дип атала. Әгәр ул кеше, гамәленең гөнаһлы булуын танып, ниндидер сәбәпләр аркасында тәүбәгә килми икән, ул барыбер иманлы булып кала[1]. Ләкин ул кылган гөнаһы өчен җәзаланачак. Ул кеше тәүбәгә килә ала һәм Аллаһ, Үзе теләсә, киләсе мәңгелек тормышта ярлыкап (гафу итеп), аны якларга рөхсәт итәргә мөмкин. Үзе теләмәсә, кылган гөнаһлары өчен бу кешегә тиешле җәзасын бирергә мөмкин. Әмма бу кешенең күңелендә иман булганга күрә, Аллаһы Тәгалә нәтиҗәдә аңа Җәннәткә керергә рөхсәт итә ала. Шуңа бәйле рәвештә, Шәригать, зур гөнаһ кылган кеше үлгәннән соң, аңа җеназа укып, Аллаһтан аның ярлыкануын сорарга куша.

Шул ук вакытта дин галимнәре зур гөнаһлардан арынуга һәм Җәһәннәм җәзалауларыннан котылырга ярдәм итүче гамәлләрне аерып чыгаралар. Боларга ихлас күңелдән тәүбәгә килү, Аллаһка гафу, тәүбә сорап ялвару (үтенү, мөрәҗәгать итү), гөнаһлардан соң бары тик тугрылыклы гамәлләр генә кылу, бу дөньяда сынаулар һәм кайгы-хәсрәтләрне кичерү, кабердә җәзалану (Җәһәннәмдә җәзаланулардан коткарырга мөмкин), Кыямәт көненең коточкыч хәлләре, хокукы булганнарның яклавы[2], Аллаһның Рәхим-Шәфкате белән кичерүе, мөселманнарның исән чакта да, үлгәннән соң да бер-берсе өчен дога кылулары (ягъни исәннәрнең исәннәр һәм үлгәннәр өчен дога кылулары), тугрылыклы гамәлләре өчен үлгән туганнарга һәм дин кардәшләребезгә бүләкләр (саваплар) тапшыру (сәдака, Коръән уку, хаҗ кылу һәм ураза тоту) кирә.

[1] Кеше әлеге гөнаһны рөхсәт ителгән гамәл дип санамаган очракта гына.

[2] Пәйгамбәрләр, илчеләр, тәкъвалар, дин галимнәре, Коръәнне тулаем белүчеләр, Коръән үзе, укылган догалар, тоткан уразалар һ.б.

## Тәкъдим ителгән әдәбият


1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джамаа». – Палестина: Джамгиййа аль-бейт ли-т-турас ва аль-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абдальмалик ‘Абдаррахман ас-Са‘ди. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафиййа». Перевод с арабского языка. – Казань: Изд-во «Иман», 2006. – 232 с.

3. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

4. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафия фи аль-‘акыда аль-исламия. – Багдад, 1988 г.

5. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

6. Утыз-Имяни Г. Избранное. – Казань: ТКИ, 2007. – 320 с.


## Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Иманга дин гыйлеменең хәнәфиләр мәктәбенә хас билгеләмәне әйтеп бирегез һәм аңлатыгыз.

2. Иман даими буламы? Дәлилләрне санап чыгыгыз.

3. Иман фитри, иман тәклиди, иман истидләли һәм иман хакыйкый дип аталган иман дәрәҗәләрен аңлатыгыз. Татар дин галимнәреннән кайсысы шушы темага язган?

4. Имансызлыкка билгеләмә бирегез.

5. Зур гөнаһка билгеләмә бирегез.

6. Зур гөнаһларга мисал китерегез.

7. Зур гөнаһ кылган кеше иманлы буламы? Ул Җәһәннәмдә мәңгелеккә калачакмы?

8. Зур гөнаһлардан арынырга ярдәм итүче гамәлләрне санап чыгыгыз.

www.darul-kutub.com

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР һӘМ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ

1. ‘Абдалгани аль-Гунайми аль-Майдани. «Шарх аль-‘акыда ат-тахавиййа аль-мусамма «Байан ахль ас-сунна валь-джама‘а». – Палестина: Джам‘иййа аль-бейт лит-турас валь-‘улюм аш-шар‘иййа», б. г. – 62 с.

2. ‘Абд аль-Малик ‘Абд ар-Рахман ас-Са‘ди. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафиййа». Перевод с арабского языка. – Казань: Изд-во «Иман», 2006. – 232 с.

3. ‘Абдальмалик ‘Абдаррахман ас-Са‘ди. Шарх ан-Насафиййа фи аль-‘акыда аль-исламиййа. – Багдад, 1988 г.

4. Адыгамов Р. К. Исламское вероучение. – Казань: Российский исламский университет, 2011. – 236 с.

5. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алям аль-джинни ваш-шайатин. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – 208 с.

6. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. ‘Алям аль-маля’икати аль-абрар. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2001. – 103 с.

7. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кыйама аль-кубра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2002. – 287 с.

8. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Аль-Кыйама ас-сугра. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2004. – 310 с.

9. ‘Умар Сулейман аль-Ашкар. Ар-Русуль вар-рисалят. – Амман: Дар ан-Нафа’ис, 2000. – 268 с.

10. Абу Хамид Мухаммад ибн Мухаммад аль-Газали ат-Туси. Высочайшее из устремлений в раскрытии смыслов прекрасных имен Аллаха/ перевод с арабского Саяхова Р. Л. – Уфа, 2007. – 232 с.

11. Аль-Бухари. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусу‘ат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

www.darulkutub.com

12. Ахмад ибн Ханбал. Муснад. – Электронный ресурс CD-диск «Маусу‘ат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991–1997).

13. Ахмед Саим Кылавуз. Исламское вероучение (акыда). – М.: Издательская группа «Сад», 2007. – 224 с.

14. Бикбулат С. Хэзрэт Мухэммэд. – Чистополь, 1999. – 264 с.

15. Габаши Х. Подробная история тюрков. Перев. со старотатарского. – Казань: Иман, 2006. – 180 с.

16. Габдрахман Абу аль-Хасан аль-Джавзи. Борьба с сомнениями антропоморфистов. – Казань: Иман, 2006. – 72 с.

17. Габдулла аль-Кахтани. Кто они неохариджиты? / перев. с араб. – Казань: Иман, 2006. – 362 с.

18. Джаухари М. Р. Акыдатуна. Каир: Джамиат аль-Азхар, 10-е изд., 2005. – Ч.1. – 196 с.

19. Ибн-Касир И. Тафсир аль-Кур’ан аль-‘азым. – Дамаск: Изд-во Дар аль-файха’, 1994. – Т. 3, 769 с.

20. Ибрагим Т. Антропоморфные описания Бога в Коране// Минарет, №3 (006), 2005. – С. 2–9.

21. Курсави Г. Тафсир байан. – Казань: Типография Домбровского, 1915. – 192 с.

22. Малик Ибрахим. Параллельный мир или многое, но не все о джиннах. – Казань: Идел-Пресс, 2004. – 432 с.

23. Малик Ибрахим. Смерть: конец или начало? – Казань: Идел-Пресс, 2007. – 207 с.

24. Муслим. Сахих. – Электронный ресурс CD-диск «Маусу‘ат аль-хадис аш-шариф», версия 2.00, Global Islamic Software Company (1991-1997).

25. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 1, 296 с.

www.darul-kutub.com

26. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 2, 272 с.

27. Топбаш О-Н. История пророков. Перевод с тур. – М.: ООО «Издательская группа “Сад”», 2006. – Ч. 3, 356 с.

28. Ульрих Р. Аль-Матуриди и суннитская теология в Самарканде. – Алматы: Фонд «XXI век», 1999. – 286 с.

29. Утыз-Имяни Г. Избранное. – Казань: ТКИ, 2007. – 320 с.

30. Хасан ибн Гали ас-Саккаф. Наставление высоким умам о достоверных и недостоверных аспектах «Хадиса о рабыне». – Казань: Иман, 2006. – 78 с.

## РЕФЕРАТЛАРНЫҢ ЯКЫНЧА ТЕМАЛАРЫ

1. Аллаһның Барлыгы (дәлилләрнең төрләре).
2. Фәрештәләр дөньясы.
3. Җеннәр дөньясы.
4. Коръәндә Тәурат һәм Инҗил.
5. Коръән могҗизалары.
6. Православие христиан дине (Исламча анализ).
7. Католик христиан дине (Исламча анализ).
8. Индуизм (Исламча анализ).
9. Конфуций дине (Исламча анализ).
10. Буддизм (Исламча анализ).
11. Яһүди дине (Исламча анализ).
12. Америка индеецларының ышанулары (Исламча анализ).
13. Междуречьедагы күпаллалык (Исламча анализ).

www.darul-kutub.com

14. Славяннардагы күпаллалык (Исламча анализ).

15. Борынгы Греция һәм Римда күпаллалык (Исламча анализ).

16. Гарәпләрдә Исламгача чордагы күпаллалык.

17. Сихерчелек һәм тылсым (Исламча анализ).

18. Татарларда дин үсеше тарихы (Исламга кадәрге һәм Исламны кабул иткәннән соңгы чорлар).

19. Бүгенге көн сектантлыкның куркынычлылыгы.

20. Пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәламның тормышы.

21. Пәйгамбәр Муса галәйһиссәламның тормышы.

22. Пәйгамбәр Нух галәйһиссәламның тормышы.

23. Пәйгамбәр Гайсә галәйһиссәламның тормышы.

24. Пәйгамбәр Йосыф галәйһиссәламның тормышы.

25. Пәйгамбәр Сөләйман галәйһиссәламның тормышы.

26. Пәйгамбәр Салих галәйһиссәламның тормышы.

27. Мөселман дин гыйлемендә могҗиза төшенчәсе.

28. Коръән Җәннәт турында.

29. Коръән Җәһәннәм турында.

30. «Ислам дин гыйлеме» фәненең әһәмияте.

31. Исламда һәм христиан динендә Кыямәт көне һәм аның билгеләре (чагыштырмача анализ).

www.darulkutub.com

العقيدة

# КУШЫМТАЛАР

## 1 нче кушымта.

## Әл-Матуридиның «Китаб әт-Таухид» китабыннан Аллаһның барлыгына китерелгән төпле дәлилләр («Бераллалык китабы»)

*Беренче дәлил:* Аллаһы Тәгалә Үзенең барлык нәрсәләрне дә барлыкка китерүче булуын безгә Үзе (Коръәндә) ачыклады. Бу вәхи безгә ышанычлы рәвештә тапшырылган.

*Икенче дәлил:* бер генә кеше дә үзенең мәңге *(кыйдәм)* яшәгәнлеген расламады. Ләкин кешенең туып, акрынлап үсүен һәркем белә. Шулай итеп, һәркемнең үз тәҗрибәсе һәм кешеләрнең риваятьләре җан ияләренең бу дөньяда мәңгелек түгеллеген, вакытлыча яшәгәнлекләрен күрсәтә.

*Өченче дәлил:* безнең тоеп белүебез, барлык тән субстанцияләре дә мәҗбүр ителү белән *(фәрурат)* яки ихтыяҗлары белән *(хаҗәт)* ниндидер башка нәрсәләргә буйсындырылганлыкларын шаһитлек кылалар. Нәрсәгә дә булса буйсыну ул вакытлылыкның сыйфаты. Чөнки мәңгелек нәрсә үз-үзенә җитешле *(гыйнан тәганә)*, ягъни автаркия була.

www.darul-kutub.com

*Дүртенче дәлил:* тере һәм үлеләрнең барлыгы үзара бәйләнгән булуны күзәтүдән шундый ук нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Берсен икенчесеннән башка күз алдына китерү һич мөмкин түгел. Башкаларга бәйле нәрсәләр исә барлыкка китерелгән һәм вакытлыча гына булырга мөмкин.

*Бишенче дәлил:* барлык тоеп беленә торган нәрсәләр, үзенчәлекләре бер-берсеннән качу *(танәфүр)* һәм бер-берсеннән ерагаюда *(табәгуд)* булган төрледән-төрле һәм капма-каршы натураларны *(табәгыйит мүхталифә вә мүтададда)* үз эчләрендә берләштерәләр. Әгәр дә алар, шуңа да карамастан, бер әйбер эчендә калалар икән, бу хәл барлыкка китерүченең гамәле генә булырга мөмкин. Шулай итеп, әйберләр барлыкка китерелгәннәр һәм вакыт белән чикләнгәннәр.

*Алтынчы дәлил:* дөнья кисәкләрдән (өлешләрдән) *(әҗзагъ вә-абгад)* гыйбарәт. Кайбер өлешләрнең элек булмыйча, аннан соң барлыкка килгәннәрен *(хәдисүн бәгъда ән ләм якүн)* һәм аларның үсеп үзгәрүләрен беләбез. Шул ук фикер бөтен дөньяга карата да кулланылырга мөмкин, чөнки ахыргы өлешләрнең кушылуы чиксез *(гайре мүтанәхин)* була алмый.

*Җиденче дәлил:* дөньяда яхшылык белән яманлык, кечкенә һәм зур, матур һәм ямьсез, яктылык һәм караңгылык янәшә яши. Каршылыклар үзгәрешләрнең һәм юкка чыгуның билгеләре була. Юкка чыккан нәрсәләр үзеннән-үзе генә гыйбарәт була алмый.

*Сигезенче дәлил:* акылга мәгълүм булганча, тән (җ*исем)* тыныч *(сукун)* булырга яисә хәрәкәтләнергә *(хәракәт)* мөмкин. Бу ике халәт берьюлы була алмый. Димәк, алар мәңгелек түгел. Тынычлык та, хәрәкәт тә бер-берсе белән алмашынып килә. Шулай булгач, алар вакыт белән чикләнгән. әгәр дә инде тыныч булмаган яки хәрәкәтләнмәгән җисемне күз алдына китерү мөмкин түгел икән, барлык җисемнәр дә,



www.darul-kutub.com

ягъни бөтен дөнья да вакыт белән чикләнгән буларак барлыкка китерелгән.

*Тугызынчы дәлил:* өстәвенә, җансыз нәрсәләр үзләреннән-үзләре генә тыныч була яки хәрәкәтләнә алмыйлар. Аларга читтән (тыштан) тәэсир ителә һәм шул рәвешле алар башка җисемнәрнең ихтыяҗларына *(хавәгыйҗ)* хезмәт итәләр һәм шуның белән аларга файда китерәләр *(мәнәфигъ)*. Әмма башкаларга хезмәт итүче нәрсәләр мөстәкыйль була алмый. Димәк, алар барлыкка китерелгәннәр. Тере булмаган нәрсәләрдән файдаланган җан ияләре дә барлыкка китерелгән була.

*Унынчы дәлил:* матди җисемнәр дучар ителгән үзгәрешләр үзләренең һәм төрле халәтләренең вакыт кысаларында барлыкка килүен раслыйлар. Хакыйкатькә туры килмәсә дә, мисал өчен, мәңгелек материянең барлыгын күз алдына китереп карасак, бу да бернәрсәне дә үзгәртә алмас иде. Әлеге материя дөнья барлыкка китерелгән мизгелдә юкка чыккан, дигән нәтиҗәгә килер идек.

*Унберенче дәлил:* без тән субстанцияләренең *(әгъян)* даими алмашынып торучы халәтләрдә (ягъни хәрәкәттә яки тынычлыкта, кушылуда яки бүленүдә һ. б.) чиксез рәвештә яшәүләрен дәвам итүләрен фараз кылабыз дигәнгә каршы килү принципиаль рәвештә дөрес түгел. Шуның белән төшенчәләрнең бер-берсеннән аерым булырга тиешле ике дәрәҗәсе кушыла. «Вакыт белән чикләнгәнлек» *(хадас)* нәрсәнең дә булса башта булмыйча, аннан соң барлыкка китерелүен раслый *(әл-каүн бәгъда өн ләм якүн)*. Шулай итеп, «вакыт белән чикләнгәнлек» һәм «башлангычы булмау» *(кыйдәм)* билгеләмәләре буенча бер-берсен кире кагалар. Эзлекле дәвамлылык *(бәка)*, киресенчә, нәрсәнең дә булса даими яңарып торучы вакыт кысаларында *(әл-каүн фи мүстәгънәф әл-вакт)* яшәешен дәвам иттерүен аңлата. Бу хәл вакыт белән чикләнгән нәрсәләр белән генә булырга мөмкин.

*Уникенче дәлил:* барлыкка китерелгәннәрнең вакыт белән чикләнмәгән рәвештә яшәүләре турында сөйләүче риваять тә бар. Әлеге риваятькә ышанырга кирәкме, юкмы? дип сорыйсы гына кала.

*Унөченче дәлил:* без теләсә кайсы рәтнең (мәсәлән, саннар рәте яки сәбәп-нәтиҗә чылбыры) башлангычы булырга, ә ахыры булмаска тиешлекне беләбез. Югыйсә бернәрсә дә булмаган булыр иде.


*Ундүртенче дәлил:* һәр хәрәкәт – аннан алдагы хәрәкәтнең ахырын, һәр мөнәсәбәт аннан алдагысының ахырын белдерә. Шул ук хәл башка акциденцияләргә дә хас. Димәк, аларның барысына да башлану һәм төгәлләнү хас. Ягъни алар вакыт аралыгында гына барлыкка килергә мөмкин.

*Унбишенче дәлил:* җисемнең дәвамлылыгы аңа «озынлык» *(бәка)* акциденциясе хәбәр ителгәнгә күрә генә мөмкин. Ул мәңгелек булсын өчен аңа кирәкле акциденция бирелергә тиеш. Ләкин бу үзеннән-үзе каршылыклы фикер, чөнки акциденцияләр *(агърад)* билгеләмәләре буенча вакытлыча күренеш һәм хәбәр итү акты да вакытлы була.

*Уналтынчы дәлил:* безгә язучысы булмаган бер генә хат та, бүлүчесе булмаган бер генә бүленеш тә мәгълүм түгел. Шуны ук тоташу (ялгану), хәрәкәт, тынычлык һәм дөньядагы барлык башка нәрсәләр турында да әйтергә мөмкин. Димәк, һәр вакыйганың барлыкка китерүчесе бар һәм дөнья да сәбәпле, ягъни барлыкка китерелгән.

*Унҗиденче дәлил:* тоеп беленә торган матди дөньяның һәр өлеше аерым-аерым алганда фикерләүчене мәңгелек булмавына, ә вакытка бәйле рәвештә барлыкка китерелүенә төшендерә. Бу хакта уйламау дөрес булмас иде, чөнки ул чакта без фикерләү сәләтеннән мәхрүм калыр идек.

## 2 нче кушымта. Пәйгамбәрләр һәм илчеләрнең шәҗәрәләре




www.darul-kutub.com

# ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ ........................................................................ 3

1 БҮЛЕК. АЛЛАҺКА ЫШАНУ .................................. 10

1.1. Аллаһның исемнәре ................................................ 10

1.2. Аллаһның сыйфатлары (атрибутлары) ................. 16

Тәкъдим ителгән әдәбият .............................................. 33

Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .......... 34

2 БҮЛЕК. ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ ЫШАНУ ....................... 36

2.1. Фәрештәләрнең сыйфатлары .................................. 37

2.2. Фәрештәләрнең вазыйфалары ................................ 42

2.3. Җеннәр .................................................................. 46

2.3.1. Җеннәрнең сыйфатлары ....................................... 47

2.3.2. Шайтан.................................................................. 50

Тәкъдим ителгән әдәбият ............................................. 53

Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .......... 54

3 БҮЛЕК. ИЛАҺИ КИТАПЛАРГА ЫШАНУ ................ 56

3.1. Вәхи (Яңалык): Илаһи Китапларны тапшыру ысулы ................................................................................ 58

3.2. Коръәнгә кадәрге Илаһи Китаплар.......................... 60

3.3. Коръән.................................................................... 64

Тәкъдим ителгән әдәбият ............................................ 68

Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .......... 69


www.darul-kutub.com

4 БҮЛЕК. ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ҺӘМ ИЛЧЕЛӘРГӘ ЫШАНУ........................................................................ 70
4.1. Пәйгамбәр белән илче нәрсә белән аерылалар? ... 74
4.2. Пәйгамбәрләр һәм илчеләрнең вазыйфалары ....... 74
4.3. Пәйгамбәрләрнең сыйфатлары.............................. 79
4.4. Могҗизалар............................................................ 82
4.5. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам ............................................................ 87
Тәкъдим ителгән әдәбият ............................................ 90
Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр......... 92
5 БҮЛЕК. КЫЯМӘТ КӨНЕНӘ ЫШАНУ ..................... 94
5.1. Үлем ........................................................................ 98
5.2. Кабер ........................................................................ 100
5.3. Кыямәт көне билгеләре .......................................... 104
5.3.1. Кыямәт көненең кечкенә билгеләре ................... 104
5.3.2. Кыямәт көненең зур билгеләре ........................... 106
5.4. Кыямәт көненең башлануы ................................... 115
5.5. Җәннәт ...................................................................... 124
5.6. Җәһәннәм ................................................................. 126
5.7. Шәфәгать .................................................................. 128
Тәкъдим ителгән әдәбият ............................................ 129
Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ........ 130
6 БҮЛЕК. ТӘКЪДИРГӘ ЫШАНУ ................................ 132
6.1. Аллаһның Ихтыяры белән кеше ихтыярының бәйләнеше ........................................................................ 134
6.2. Аллаһка тапшырылу (әт-тавәккул) ...................... 136

www.darul-kutub.com

Тәкъдим ителгән әдәбият .............................................. 137
Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ........ 138
7 БҮЛЕК. ӨСТӘМӘ СОРАУЛАР ................................ 139
7.1. Иман ........................................................................ 139
7.2. Иман даими буламы, әллә ул үзгәрүчәнме? .......... 141
7.3. Иманның төрләре .................................................. 141
7.4. Имансызлык ............................................................ 144
7.5. Зур гөнаһлар ......................................................... 145
Тәкъдим ителгән әдәбият .............................................. 147
Үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ........ 147
ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ .............................. 148
РЕФЕРАТЛАРНЫҢ ЯКЫНЧА ТЕМАЛАРЫ ............. 150
1 нче номерлы кушымта. Әл-Матуридиның «Китаб әт-Таухид» китабыннан Аллаһның барлыгына китерелгән төпле дәлилләр («Бераллалык китабы») ... 152
2 нче номерлы кушымта. Пәйгамбәрләр һәм илчеләрнең шәҗәрәләре .................................................... 156

www.darulkutub.com

# ГАКЫЙДӘ

## (Иман нигезләре)

**Уку әсбабы**

Төзүче-автор: **Габдулла Әдһәмов**
**Корректор:** *Дәүләтҗанова Г.С.*
**Компьютерда биткә салучы:** *Сәйфетдияров Р.Г.*

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча
сатып алырга мөмкин:
Казан, Лобачевский урамы, 6.
Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы мөселманнары
Диния нәзарәте;
Казан, Газовая урамы, 19.
Россия ислам институты.

**"Хузур" нәшрият йорты.**
420111 Казан, Лобачевский урамы, 6.
**Тел./факс: +7 (843) 202-07-74.**
http://huzur.ru; электрон почта:
huzur.inform@mail.ru

Басарга кул куелды: 22.12.2014. Форматы 60*90 $^{1}/_{16}$.
Офсет басма. «Таймс» гарнитурасы.
Тиражы 1000 данә. Заказ № 192

«Зур Казан» типографиясе.
420095 Казан, Серов урамы, 4а. Тел.: 8 (843) 253-66-04
Бирелгән электрон әйләнешкә туры китерелеп бастырылды.

www.darulkutub.com